# Хади Такташ

## СОЧИНЕНИЯ

В трех томах

**Том 1**

Стихотворения и поэмы

*Издание второе, исправленное и дополненное*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2010

# ҺАДИ ТАКТАШ

## ӘСӘРЛӘР

Өч томда

**1 том**

Шигырьләр һәм поэмалар

*Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т17

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин,*
*И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Л.М.Шәехов, Ф.И.Фәтхетдинова*

Томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче
*Нажия Садыйкова*

**Такташ, Һ.Х.**

Әсәрләр : 3 томда / Һади Такташ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.
ISBN 978-5-298-01891-3
1 т. : шигырьләр һәм поэмалар / томны төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Н.Садыйкова; кереш сүз авт. Р.Гаташ. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – 2010. – 407 б.
ISBN 978-5-298-01892-0

Татар халкының классик язучысы Һади Такташ әсәрләренең бу томында әдипнең шигырьләре һәм поэмалары туплап бирелә.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01892-0 (1 т.)
ISBN 978-5-298-01891-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Садыйкова Н.И., төзү, текст., иск., аңл., 2010

## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Татар халкының классик язучысы Һади Такташ әсәрләре өчтомлык итеп беренче тапкыр 1980–1983 елларда чыгарылды. Моңа кадәр аның аерым җыентыклары һәм бертомлыклары гына басылып килде. Өчтомлык СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзер Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) тарафыннан Татарстан берләштерелгән Дәүләт музее (хәзер Татарстан Республикасы Милли музее) белән иҗади хезмәттәшлектә әзерләнде. Әсәрләр җыелмасы әдипнең моңа кадәр басылган җыентыкларына һәм бертомлыкларына нигезләнеп төзелде. Ул алдагы елларда дөнья күргән китаплардан үзенең тулылыгы һәм фәнни эшләнеше белән аерылып тора.

Томнарда Такташның укучыларга яхшы билгеле шигырьләре, поэмалары, пьесалары, хикәяләре, мәкаләләре белән бергә үз вакытында газета-журналларда гына урнаштырылган, китапларына керми килгән байтак әсәрләре урын алды. Шулай ук җыентыкта шагыйрьнең музей архивында саклана торган автограф-кульъязмалары киң файдаланылды. Нәтиҗәдә аерым әсәрләренең язылу тарихлары һәм вакытлары төгәлрәк билгеләнде. Архивта гына сакланып калган кайбер әсәрләре, әсәрләренең вариантлары, шулай ук хатлары, автобиографик материаллары укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителде.

Томнарны әзерләү барышында зур гына текстологик эш башкарылды. Кульъязмадагы нөсхәләр белән төрле басмалар чагыштырылып, аермалыклар ачыкланды. Текстларда төрле сәбәпләр аркасында киткән һәртөрле кыскартулар, төгәлсезлекләр, хаталар төзәтелде. Өчтомлыкка кергән әсәрләргә, кульязмалар һәм архив материаллары нигезендә, беренче тапкыр тәфсилле искәрмәләр һәм аңлатмалар язылды.

Җыентыкның яңа басмасына кайбер төзәтмәләр һәм өстәмә текстлар кертелде. Томнарда әсәрләрне бирү тәртибе үзгәртелде һәм түбәндәгечә бүленде:

беренче том – шигырьләр, поэмалар;

икенче том – проза әсәрләре, әдәбият-сәнгать тәнкыйте мәкаләләре, публицистика;

өченче том – сәхнә әсәрләре, көндәлекләр, хатлар һәм документлар.

## КИЛӘЧӘККӘ ТАКТАШЫБЫЗ БЕЛӘН

Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны
Еглатырга... Әйе, миндә көчле Байроннар җаны.

*Һ.Такташ*

Такташ һәм Байрон... Байрон белән Такташ дип язабыз икән, бу – укучылар өчен сәер янәшәлек түгелме? Әйе, дөнья әдәбиятының бөек шагыйре, инглиз, лорд Байрон һәм «чабаталы даһи» – татар халкының сөекле шагыйре Һади Такташ – исемнәрен бергә куеп тикшерү, күзаллау, өйрәнү әле Такташның беренче китабы – «Җир уллары трагедиясе» һәм башка шигырьләр»е басылып чыккач ук башлана. Гали Рәхимнең 1923 елда «Безнең юл» журналында (10–11 саннар) басылган «Нәләтләр шагыйре» исемле күләмле, шигъриятебезнең барышын тирән аңлап, яшь Такташ иҗатына, талантына матбугатта беренчеләрдән булып искиткеч зур бәя биргән мәкаләсен генә искә төшерик. Анда ул яшь шагыйрьнең «Җир уллары трагедиясе»н Байронның «Каин» әсәре (мистерия) белән чагыштырып анализлый; әсәрдә Такташ омтылган «мәңгелек темалар, мәңгелек проблемалар»ның яңача кызыклы чишелешен дәлилләп күрсәтә; XVIII гасыр ахырында Германиядә булып узган «Давыл һәм һөҗүм» хәрәкәте чоры шагыйрьләре, аерым алганда Шиллер, Гёте һәм соңрак язган Һейне белән охшаш яклар таба. Такташ әсәрләреннән һәм аның хакындагы истәлекләрдән дә шагыйрьнең әлеге бөекләр «гаиләсендә» үзен «иркен сизүен» тоеп була.

Биредә бер кызыклы фактны китерү дә урынлы булыр: Байронның моннан егерме еллар элек Мәскәүдә чыккан күптомлыкларының берсендә татар галимәсе Д.Усманованың кереш мәкаләсе басылган иде; әйтүенчә, аның бу эшкә алынуына кереш сүздә Һади Такташ исемен телгә алу, безнең әлеге язмабыз алдыннан китерелгән шигъри юлларны бирү мөмкинлеге туу сәбәпче булган. Такташка мәхәббәт-хөрмәтнең бер чагылышы бит бу.

Ә хәзер бер сорауга җавап бирик әле: кем ул бүген Такташ? Кирәкме бүген безгә узган гасыр башында ук туып, нибары утыз ел яшәгән, әмма татар рухи дәрьясында, башка төрки халыклар күңел күгендә яшендәй эз сызып үткән, Фәүзия Бәйрәмова язганча, «атылган йолдыз» булып та, яктысы күп еллар бетмәгән һәм бетмәячәк кабатланмас шагыйребез Һади Такташ? Такташ ул – бер шагыйрь әйткәнчә, татар шигырендә халыклар аңында өч тулпар ат белән «җигелгән» – тройка булып җилгән милли бөек Сүзнең – шигъри Моңның Тукай, Такташ, Туфан дип, [т] авазлары белән дә татарлыгын чатнатып, тупырдатып әйтеп торган иң олы талантларның берсе!

Такташка тугрылык мәктәбенең зур тарихы бар: ул Н.Исәнбәт, Х.Туфан, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Ф.Кәрим, Ш.Маннур, С.Хәким исемнәре белән бәйле. Олуг прозаик әдипләребезнең бөек шагыйрьгә мәхәббәте дә безнең күз алдында булды. Ф.Хөсни, Ә.Еники кебек сүз осталары, җае чыккан саен: «Такташ бит ул, җаным, Такташ!» – диләр иде. Ә яшьрәкләр – И.Юзеев, Ә.Баян, Ш.Галиев, Роберт

Әхмәтҗанов, Г.Рәхим, Зөлфәт, Р.Вәлиев, Л.Шагыйрьҗан, Р.Миңнуллин, З.Мансуров, Р.Зәйдулла, Г.Моратлар?!

Ышанып әйтәм: бүген әдәбиятка килгән егерме яшьлекләр күңелендә дә биеккә әйдәп торган Такташ йолдызы яна. Ә мин аны алтын чорыбыз – XX гасыр башы Ренессансы корифейлары, яңа чор әдәбиятыбыз баганалары: Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, М.Гафури, Ш.Бабичлар йолдызлыгында күрәм. Ул – аларның иң лаек энесе, хаклы варисы, дәвамчысы; шул бөекләрдән соңгы чорны, фаҗигале, авыр заманны җыр итә алган бөек Сүз остасы. Үз чорының бөтен сынау-мәктәпләрен узып та, ялган пәйгамбәрләргә табынып та, шигырьдә үзе булып кала алган, үз чорының иң көчле яңгырашлы, яңа тонлы, яңа үлчәү-ритмлы формасын тудырган, әмма искиткеч халыкчан булып, сурәт-сүздә иң үтемле чаралар табып, миллион йөрәкләргә Яңа Шигъри сүз булып кергән илаһи талант иясе ул Такташ! Һәм менә ничә дистә еллар инде ул халыкны Шигырь, Сүз могҗизасы белән тәрбияли, нәкъ менә рухи остаз булып, шигъри әдәп, шигъри аң, зәвык, матурлыкны тою эталоны булып кала. (Киләчәктә дә шулай булачак дип ышанмасам, бүген бу юлларны мин, Такташның мәңгелек гашыйгы Гаташ, язар идеммени?!) Бу үзе үк – Милли сүзнең, нәкъ Тукай шикелле үк, халык бәгъренә әйләнүе, Моңның җиңүе.

Бүген дә шагыйрь Һади Такташ безне кабатланмас Матурлык, Хис, Йөрәк, Акыл синтезы булган бөек Шигърият иленә чакыра, мәңгелек Мәхәббәт фәне укытучысы булып кала бирә. «Җир уллары трагедиясе», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Урман кызы» да, яңа декларацияләр, үзгәрешләр чоры әсәрләре «Алсу» да, «Мокамай» да, «Киләчәккә хатлар» да безнең белән. Проза әсәрләре, драмалары, публицистикасы, хатлары да. Һәм, Такташ шигыренең тиңсез сүз тылсымына таянып, мин шуны әйтә алам: киләчәктә дә моң дәвамы, Такташ авазы дәвамы булыр. Такташ калыр. Без Такташларны дәвам итү, аларның васыятьләрен, традицияләрен киләчәккә алып бару өчен дә яшибез. Әдипнең безнең күңелләрдә торкан урынын раслау өчен, иң авыр чорларда да аңа эндәшеп, аның белән киңәшләшеп, аны сагынып яшәгән Хәсән Туфан шигырен искә алу да җитә:

Әй, талантлы, олы бөек халкым!
Кабул итче тик бер сорауны.
Бирсәнә син безнең сафка тагын,
Бирсәнә бер Такташ сыманны.

***Рәдиф Гаташ,***
*Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт,*
*Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм*
*Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге*
*премияләре лауреаты*

# Шигырьләр һәм поэмалар

## *1916*

### ГАЗРАИЛЛӘР

*(1914 елгы Европа сугышына каршы)*

Тау өстендә утырган ул, уйга баткан;
Канатлары талган килеш, җиргә яткан;
Маңлаенда – нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күрнеп тора ерак илләр;
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
– Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт,
Монда үлем, монда патша – газраилләр!

Ул фәрештә моннан бик күп еллар элек

Бу йолдызга күктән очып килгән иде.
Төзер өчен мәңге рәхәт – бәхет багын,
Кызыл гөлләр чәчеп, сулар сипкән иде.
Сипкән иде...
Җырлый-җырлый мәхәббәт һәм күк көйләрен,
Җир йолдызын тезеп, җәннәт иткән иде;
Безләр өчен җәннәтен ул, гөлләр өчен
Тагын очып кире күккә киткән иде.
Киткән иде...
Күчеп тиз-тиз бер йолдыздан бер йолдызга,
Бик күп еллар матур гөлләр җыеп йөрде...
Кайтса кире җир өстенә: нинди дәһшәт!
Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде.
Котырган ил... Болгый-болгый кулларында
Ялтырата сөңгеләрен. Юлларында
Үлгән ирләр өелеп кала, аунап шунда;
Җәһәннәмдәй утлар уйный уңда-сулда.
Хәят иле – матур йолдыз – янып сүнгән;
Тапталып гөл баглары көлгә дүнгән;
Матур кырлар, бәхет-җәннәт урманнары
Гакылсызлар йорты булып әверелгән.
– Кемнәр алар, җәннәтемә кемнәр килгән?
Нинди явыз ерткыч җаннар?
Кайсы илдән?
Җавап бирми берәү дә... Тик, үкреп-үкреп,
Туплар оча фәрештәнең баш өстеннән.

Тау өстендә утырган да уйга баткан;
Канатлары талган килеш, җиргә яткан;
Маңлаенда – нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күрнеп тора ерак илләр,
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
– Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт!
Монда үлем! Монда патша – газраилләр...

## КАРАҢГЫ ТӨННӘРДӘ

Уем зәкъкум булып агыла
Коры, кансыз тамырлардан;
Хыялым – бер тирән сахра, –
Суык җилләр исә анда.

Йөрәгем мәңгегә сүнде
Кылыч, уклар ярасыннан;
Үләм мин дә – китәм инде
Явыз «җеннәр» арасыннан.

Калыгыз инде иркендә...
Китәм мин, ташлыймын җирне.
Фахиш җир! Куеныңа шомлы
Еланнар ояласын инде!

Очам күккә – кайда пакьлек,
Керәм анда, җуеп эзне.
Йөрермен анда мин ялгыз,
Ләгънәтләп мәңгегә сезне.

Китәм, юк, төшми калмас бу
Минем каргыш, сагышларым,
Тыныч бирмәс, ерактан
Иштелер ямьсез тавышларым.

# *1917*

## ТӨРКСТАН САХРАЛАРЫНДА

Таң атамы? Яктырамы?
Нишли дөнья, нишли ул?
Ник күренми якты көннәр?
Ник томанлы алгы юл?

Әл дә, золмәтләргә йотылып,
Монда ил-ислам тора.
Һәр ягы – золмәт учагы,
Куркыныч төн кап-кара...

Кайда соң ул нурлы таңнар,
Ай, кояшлар балкыйлар?
Кайсы илләрне матурлый,
Бизиләр һәм аңкыйлар?!

Кайда хөрлек, инкыйлаблар,
Кайда таңнар сыздыра?
Рухлы тормышлар ясарга
Дөньяны пыр туздыра?!

Кайда рухлы, ямьле дөнья,
Шат тәбәссемле хәят?..
Бармы? Йә юк... ул хәят,
Йә ул хәят безләргә ят?!

Юк төсле ак күңелгә...
Монда михнәт, монда төн,
Монда сахра, моңлы сахра...
Барчасы тоткын бүген!..

## *1918*

### КҮКТӘН СӨРЕЛГӘННӘР

Таш-тауларны эретердәй шәфкать нуры
Балкый төпсез күзләренең карашында,
Фәрештә ул; сөйгән өчен адәм халкын,
Ята шунда дүрт диварның арасында.
Кара болыт чәчкәйләре тәнен япкан,
Озаеп, дулкынланып, җиргә яткан;
Ак тәннәре зифа аның, зур күзләре
Текәлеп бер ноктага уйга баткан.
Тулган айның, ак нурлары бары бергә
Җыелып, төшкән шәүләсе ак йөзләренә.
Тәрәзәсе ачык аның, күк дөньясы
Онытылып карый серле күзләренә.

Ул да шулай кайчандыр бер күк кызы иде,
Янып торган күкнең шәфкать йолдызы иде.
Түзалмагач җир өстендә аккан канга,
Килеп күкнең патшасына башын иде.
Иде дә ул, сорады күк Алласыннан:
«Бетсен, – диеп, – җирдә коллык, күз яшь һәм кан!»
Нәрсә диде аңар каршы күк Алласы?
«Хаинә син! Синең урның – суык зиндан!»
Әйе, ул бер сөрелгән; шунда күптән инде
Онытылган. Сөрелеп ул күктән, иңде
Газапланыр өчен җиргә, тар зинданга.
Үтә еллар... Хәятыннан бизгән инде...

Чү, Газраил канатларын селкеп алды,
Таратты бар болытларны офыкларга;
Киң күк йөзе шыр ялангач булып калды;
Мәһабәт ул килеп басты биек «дар»га,
Канатының очларыннан каннар тама;
Канга баткан зур күзләре уттай яна.
«Әҗәл житте бу кызга!» дип, Тәңре хөкмен
Укыды ул галибанә бар дөньяга.
Барып, зиндан ишекләрен ачып керде.
Нәрсә күрде?! – Зәһре бетте йөзләрендә,
Иң беренче, канатлары хәлсез калып,
Рәхим, шәфкать ишетелде сүзләрендә.
Иң беренче, таш йөрәге каннар сыгып,
Күз яшьләрдән битләрендә күренде юл.
Онытты да Тәңре хөкмен, белештерми,
Күк кызының аягына ташланды ул.
Ташланды, ах! Мискинәнең ак йөзләре
Агарды; куркудан йомылды күзләре.
Күп тә үтми Газраилнең колагына
Ишетелде күк кызының шул сүзләре:

«Килмә якын, зәһәрләнеп, өсләремә!
Ерткычлык чыккан синең йөзләреңә!
Канатларың канлы синең, килмә! Куркам.
Кан йөгергән, агу, зәһәр күзләреңә.
Кай җирләрдән кан агызып килдең, әйтче,
Нинди шомлы сер сөйләргә минем янга?
Кем син үзең?
Юл кисүче?
Иблис мәллә?
Буялган, әйт, канатларың нинди канга?»
«Адәм каны тама канат очларымнан –
Җан алучы фәрештә мин!»

Кинәт нәрсә?
Шәфкать кызы, бер селкенеп, шул минуттук
Керфекләрен йомды, мәңге күтәрмәскә...
Ак тәннәре кара ташка әүрелделәр
Газраилнең каты тимер кулларында.
«Ант бозучы бөек хаин – Газраил!» дип,
Уттан сүзләр язылды күк юлларында.

Чү, Газраил ачу белән сикереп торып,
Зур кылычын кара җиргә ташлады ул;
Ташлады да, канлы кулын күккә сузып,
Дәһшәт, ачу белән сөйли башлады ул:
«Оҗмахларың минем өчен булсын хәрам;
Кайтмыйм, явыз, хаин Алла, күкләреңә!
Үкенәмен, моңа кадәр алданып күп,
Хаксызга адәм каны түккәнемә!
Кимсенәмен, басмыйм аяк моннан ары
Мәлганәтләр тулган фахирле гаршеңә!
Куйма юкка хур кызларың, җәннәтләрең,
Зур сәнгатең белән нәкышләп, каршыма!
Мин беләмен: бар күкләрең, гаршең синең
Энҗеләнгән җирдәге күз яшь, кан белән!
Хәзер белдем: бар фәрманың, хөкмең синең
Тулган алдау, канлы үлем, ялган белән!
Моңа кадәр алданып, күп каннар түктем;
Шуның өчен, белдем, урным күкләр иттең,
Бер минутлык шәфкатемә түзалмадың;
Бар биргәнең тартып алдың да кимсеттең.
Китәм хәзер канлы үлем кырларына!
Сөйлим хаклык мәзлум адәм улларына!
Биреп канлы кызыл байрак кулларына,
Ачам сугыш, салам киртә юлларыңа!

## ҮТЕРЕЛГӘН ПӘЙГАМБӘР

*(Октябрь революциясенә кадәр үлгән берәүнең авызыннан)*

## I

Каргамагыз мине, гөл-чәчәкләр!
Йокыгыздан сезне уятып,
Яланаяк шунда һәр көн йөрим,
Җырлый-җырлый урман буйлатып.
Нигә йөрим?
Яшь чәчәкләр! Сез әйтегез!
Сез сөйләгез! Нигә йөрим?
Ах! Юк! Сөйләмәгез, мин сорыйм,
Тик торыгыз! Иштәсезме? Тик торыгыз!
Мин дә, шунда башым түбән иеп,
Тавыш-тынсыз гына тик торыйм...

Мин бит һәр көн шулай таң алдында
Күл янында ялгыз утырам;
Әкрен генә җырлыйм, тагын тынам,
Тагын җырлыйм, тагын тик торам.
Нигә җырлыйм?!

Карт агачлар, хәтерлимсез, мин яшь чакта
Азмы сезнең янда йокладым?
Мин яшь идем шул ул чакларда;
Ә хәзердә, күрегез,
Ничек арган, ничек хәлдән тайган
Карт бер юлчы булып туктадым!
Ник туктадым? – Монда илем, халкым.
Алар – ачлар, мине көткәннәр;
«Тимер килер, безгә ярдәм итәр», –
Диеп, миннән өмит иткәннәр.
Ә мин?..
Әнкәй – ул хәзер дә шул ук әнкәй;
Ләкин кайчак шулай карый күземә,
Мин оялам, башым түбән иям,
Каннар йөгрә минем йөземә.
Мискин әнкәй...

## II

Сөйлә, әнкәй! Сөйлә, мин туганда,
Кем булсын дип дога кылдың син?
Нинди дога белән, үкрә-үкрә,
Канлы җиргә йөзең ордың син?
Әллә: «Углым минем тарих углы булсын!» –
Диеп дога кылдыңмы?
Әллә... Сөйлә, әнкәй! Юат чит илләрдән
Сиңа кайткан тиле улыңны!

Кояш – шаһит: илем, иркем өчен
Сугшып йөрдем, әнкәй, ул күрде!
Зобанилар, явыз зобанилар,
Алар... Алар мине үтерде.

### III

Хәнҗәр очлыйм, әнкәй, кискен хәнҗәр,
Синең кунагыңны суярга!
Мин кан телим, әнкәй, мин кан телим!
Канга исреп, телим хәсрәтемне җуярга!
Гаҗәпләнмә минем сүзләремә,
Ниләр сөйлим, белмим үзем дә;
Нинди хәсрәт уты йөземдә,
Аңлыйсың бит? Аңлыйсың үзең дә...

### IV

Төн уртасы. Әнкәй, мин дар ясыйм:
Әмер булган мине асарга.
Мин дар ясыйм яшь бер пәйгамбәргә,
Дарга басып, күккә ашарга...
Кил, асраган анам! Үп улыңны!
Гайса киткән җиргә китәм мин,
Соңгы сулышым, сынган кылычым белән
Дарга басып антлар итәм мин:
Алар килер күктән болыт булып;
Уклар булып җиргә яварлар;
Таш-тауларны ишеп, каннар белән,
Гәүдә белән җирне ябарлар!
Кылычлары булыр утлы яшен;
Кадап җиргә үлем байрагын,
Басып залимнәрнең күкрәгенә,
Итәр алар үлем бәйрәмен...
Түкмә күз яшь, әнкәй! Елама син,
Аерылам дип миннән – balаңнан!
Әнием! Әнием, сорыйм, мин үлгәчтен,
Яшь көрәшче тудыр яңадан...

### V

Гөлләр чәчтем, әнкәй, матур гөлләр,
Алар үсәр, әйе, үсәр бит?
Гөлләремне сөеп, таң җилләре
Һаман исәр, әйе, исәр бит?
Алар үскәч, алар гөлләнгәч тә,
Әнием, беркөн чыгып өзәрсез,
Янып торган кызыл чәчәкләрдән,
Үрә-үрә, һәйкәл төзәрсез.
Ул һәйкәлгә мәңге, мәңге көлеп торган
Охрави бер авыз уярсыз!
Күкрәгенә
«Яшьләй үтерелгән пәйгамбәр»
Дип язып куярсыз.
Менә хәнҗәр, әнкәй, кискен хәнҗәр!
Бөек теләк белән, баладан,
Үтер мине, минем аккан каннан

Яшь көрәшче тудыр яңадан!
Мин киң хәят теләп илгә чыктым;
Албастылар кисте юлымны.
Мин: «Азатлык!» – дидем.
Алар көчләп
Бәйләп куйды ике кулымны.
Мин, сандугач булып, талга кунып
Сайрамакчы булган чагымда,
«Алар» аучы булды тагын да.
Мин, сайрамак теләп ил багында,
Канат кактым; шунда тагын да
Канечкече, ерткыч каракошлар
Шаулап торды тирә-ягымда.
Кайда хәят, әнкәй? Кайда һава
Ауру күкрәгемә суларга?
Яки бушлык кайда, төпсез бушлык,
Оятымнан качып еларга?..

Кояш – шаһит: илем, иркем өчен
Сугшып йөрдем, әнкәй, ул күрде!
Зобанилар, явыз зобанилар,
Алар... Алар мине үтерде!
Юк, юк! Мин үлмәдем! Әле мин үлмәдем!
Бирегез хәнҗәр миңа, мин сорыйм!
Соңгы кабат үлем таушы белән
Ил өстенә карап кычкырыйм!
Юлбасарлар! Угры! Фахишәләр!
Коллар! Толлар! Ачлар! Эшчеләр!
Килегез монда! Килегез монда, читлекләрдә
Үлем көтеп яткан көчлеләр!
Сөйлим сезгә сарай фахишлеген,
Килер көнне, туфан-ташкынны!
Ишетәсезме?! –
Ах, юк, алар килми.
Ишетмиләр минем таушымны.
Алар – ачлар. Әле килалмыйлар –
Кулларында тимер богаулар.
Алар – анда, түбән чокырларда.
Чыгалмыйлар. Ауру-сырхаулар!..

## *1920*

### АЧЛЫК ПАТША

Уйганам... дәһшәтле бушлык...
Ташландык бер җирнең өстендә.
Тирә-ягым караңгы төн. Авыр, җансыз...
Кычкырам... Юк, юк беркем дә.
Беркем дә...
Исә җил – авыр, кайгылы,
Куркыныч көйләрне көйли ул,
Дәһшәтле серләрен, тарихын,
Бу җирнең кайгысын сөйли ул.
Тыңлыйлар йолдызлар, болытлар...
Ач үлем, коточкыч күзләрен
Юнәлтеп сөякләр өстенә,
Тик тора; кан алган йөзләрен;
Чәчләре таралган; агарган
Сакалы җир белән тиң аның.
Килмешәк баһадир, ялгыз ул –
Патшасы ташландык дөньяның.
Кулында бар золым, җәбернең
Шаһиты – коточкыч, куркыныч,
Кан белән бизәлгән, тутыккан,
Мәһабәт, ялангач зур кылыч.
Хөр илнең баһадир уллары
Аягы астына егылган:
«Нан!» диеп тилмереп, калтырап,
Куллары асманга сузылган.

## АНТЫМ

Кычкырам:
Килегез, әй, адашкан,
Канга баткан мәзлум ил халкым!
Түзә алмый канга, вәхшәткә,
Мәхәббәт байрагын алдым.
(Алып каннан, сәгадәткә
Чыгарырмын эшчеләр халкын!)
Язып куегыз, кирамән
Кятибиннәр, бер бөек антым –
Хакыйкать мин басам; баскан
Эземдә тетриләр таулар!..
Өзелә бер генә кул селтәвемнән
Мәңгелек баулар...
Еланнар! Сезгә юк тормыш,
Куып юлдан, буып сезне,
Ачам юллар сәгадәткә!
Җуям җирдән фахиш эзне...
Күрәмсез бу байракны: бар мәзлумнең
Яшен җыйган...
Ул байрак күз яшь белән
Каннан койган...

## АЙНЫҢ НУРЛАРЫ АРАСЫНДА

Күңелем дә, җаным да, иманым да, бергә
Кушылып айның нурлары белән,
Дулкынлы караңгылык өстеннән
Очтылар офык буйлап, ераклашып җиргә...
Очтылар сахралар, урманнар өстеннән,
Куе калын томаннар эченнән
Кызыл гаскәрләр өстенә –
Мактарга каһарманлыклары белән.
Менә, канатларын җәеп,
Кундылар кызыл байрак өстенә.
Сәламләделәр аны
Ялкынлы сәламнәре белән,
Яңгыратып тынлыкта яткан гаскәр илен,
Мактап көйләделәр аңа хөрлек көен...
Башларын иеп, кабер ташларын үбеп,
Шәһит каһарманнарның рухларына
Илнең сәламен ирештереп
Кайттылар аларның барына.

## *1921*

*** * ***

Җил сөйли, үкрә миңа, син ят тудың, ди, дөньяга...
Ил сөйли... шомлы көлә, син, ди, явыз, динсез бала.
Кем яраткан? Ник яраткан? Нинди сергә баглы мин?..
Кем дә белми, кем дә әйтми... Аh! Үләм мин кайгудин...

Бар да – шәфкатьсез, аяусыз, таш йөрәкле бәндәләр,
Чорнап алган да көләләр ыржаеп «ул» гәүдәләр...
Үтте еллар... Эзләдем мин, эзләдем бер тугры дин,
Тапмадым, әмма югалттым бар иман, «алла»мны мин...

Бирмәде нур ай, кояшлар, тугры юлга салмады,
Сахирә нурлар, бөек уйлар бары да алдады...
Барча шатлык, бар матурлык үзгә төс алган миңа,
Бар кануннар – бер фахиш уй, канлы эз, – ялган миңа.

Мин караңгылыкта мәңге-мәңге, ялгыз мин генә...
Кем белә, әйтсен иде, аh! Ник ялдым мин менә?!

**юану:**

Мин ялдым серле моңнарым белән бар дөньяны
Еглатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны.
Көн килер, күз яшьләрем тормыш күгендә ялтырар...
Дәртле җырларым моңыннан ил елар...
Әйе, минем көчле рухымнан җир вә күкләр калтырар.

**ҖИР УЛЛАРЫ ТРАГЕДИЯСЕ**

**Алты күренештә**

*(Вакыйга хыялый яһүд тарихыннан)*

ФАҖИГАДӘ КАТНАШУЧЫЛАР:

Адәм.
Хава.
Кабил
Һабил } Адәмнең уллары.
Әкълимә – Адәмнең Кабил белән игез кызы.
Идея - Газазил.
Канун - Җәбраил.
Газраил.
Микаил.
Беренче Адәм баласы.
Икенче Адәм баласы.
Ике яшь бала.
Күп Адәм балалары, фәрештәләр.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

### Пролог

Кара урман. Караңгы төн. Сәхнәнең арт ягында ишелеп-ишелеп күкләргә озайган түбәләр, янар таулар күренә. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә берәү дә юк. Тирә-
якта дәһшәтле тынлык.

*(Хор)*

*(Бөтен табигатьтән өстен көч җырлый.)*

Төн. Ерак күкләр караңгы.
Йоклый тынлыкта җиһан,
Йоклый җир, йоклый акыл,
Йоклый мәхәббәт һәм иман...
Йоклый Алла, йоклый җир-күк,
Бар табигать йоклаган,
Йоклаган ай да – бүген төн
Каф тавыннан чыкмаган.
Чыкмаган...
Тик янар таулар бүген, төн
Туктамыйча, ут ата, –
Ут ата, аксыл төтеннәр,
Болганып утлар белән,
Нәкъ томан җиргә ята...

Хор әкренләп туктала. Сирәк-сирәк кенә юлбарыс тавышлары ишетелә. Кинәт, ерак та түгел, йөрәк өзгеч тавыш. Тагын тынлык. Сәхнәгә Идея-Газазил
килеп чыга. Ул нур эчендә.

Идея

Нинди өн? Чү! Кайда иштелде
Йөрәк өзгеч аваз?
Кем елый бу шомлы төндә?

Пауза.

Нинди бу хәсрәтле саз?!
Төнге золмәттән адашкан

Юлчы, бер җенме елый?
Кем соң ул күк Алласыннан
Кан елап ярдәм сорый?..

(*Бер якка кычкырып.*)

Сузма кул, хәсрәтле җан, әй!
Син, аңа ярдәм сорап,
Кимсенеп, алдында торма
Ул хаиннең, кан елап!
Мәңге ул шәфкатькә дошман,
Ул залим, ут Алласы,
Дәргяһе – ут; җәннәте,
Гарше – кызыл кан дәрьясы...

Ашыгып, сәхнәдән югала. Тирә-якта коточкыч юлбарыс, аю, бүре тавышлары. Сәхнәгә Кабил килеп керә. Ул талган. Әкрен генә сәхнә уртасына атлый. Озак пауза.

Кабил

Төнге золмәттән адаштым,
Мин бу тауларга кереп;
Тапмадым бер җир кунарга,
Төн буе шунда йөреп.
Һәр тарафта коточыргыч
Юлбарыслар ыжгыра,
Баскан эз дә куркыныч, –
Уклы еланнар сызгыра...

(*Кулларын күккә күтәреп.*)

Соңгы кат кулларны суздым,
Әй, Ходай, мин иркеңә!
Сакла син, калдырма ташлап
Юлбарыслар иркенә!..
Суз кулыңны, ал төнеңне!
Күктә сызлып таң атып,
Нурланып чыксын кояш, бу
Төнге золмәтне ватып!..

(*Кулларын түбән төшерә.*)

Тынлык.

Ул ачулы; канлы яшьле
Күзләремне күрми ул,
Үч ала миннән, мине ул
Мәңге хәсрәткә салып,
Язмышым белән нигәдер
Залиманә уйный ул...

Тынлык.

Мин тудым. Тудым – тугандук
Ят идем. Үз әнкәем
Үпмәде шатлык белән:

«Тугдың, балам! – дип, – бәбкәем!..»
Үпмәде ул, какты читкә,
Күз яшемне сөртмәде.
Калды яшьләр; канлы яшьләр
Мәңге күздән кипмәде...

Килеп, әкрен генә ярга сөялә. Пауза. Сәхнә яктырып, таулар өстендә Идея заһир була.

Идея
(*Кабилгә таба кулын сузып*)

Кызганыч, мескен җир углы!
Кул сузасың Аллага,
Белмисең: ул күктә сиңа
Зур тәмуг, утлар яга...

Язмышыңнан тетри җан, –
Рухлар елый, җир селкенә;
Сизмисең: алда сиңа
Нинди кара көннәр килә...

Кабил
(*үз-үзенә*)

Анда ачлыктан сөекле
Әкълимәм әрнеп ята,
Тар, кара, салкын мәгарәдә
Суык җилләр белән
Тартыша, мескенкәем,
Елап чыга ул төн ката.
Анда ачлыктан, суыклыктан
Туганнарым минем,
Бер-беренә сарлышып, ярдәм көтәләр.
Соң мин нишлием?
Төн буе тауларда йөрдем,
Нинди аулар салмадым,
Тукланырлык бер генә хайван да
Мин тота алмадым.
Гаиләмнең язмышында
Мәңгелек михнәт күрәм,
Кайдадыр очмак булам да –
Юл табалмыйм, тилмерәм...
Кемгә сузсам да кулымны,
Мәрхәмәт, шәфкать теләп,
Кулларым буш кайтарылды,
Сүнде рухта бар теләк...
Бар да дошман!

Идея
(*тауларга ышыкланып*)

Юк. Ялгышасың, барсы да
Дошман түгел,
Бар синең дустың, бар ул,
Ул гали, ул ак күңел...

Кабил
(*эзләнеп*)

Булса, ул сузсын кулын,
Дуслык белән бәгърен ачып,
Мин явыз, вәхши түгел, ул
Тормасын миннән качып!..

Идея
(*кинәт аның алдына чыгып*)

Ул – менә мин!

*(Кабил чигенә, кинәт тезләнә.)*

Бир кулыңны! Әйдә, моннан
Кач ерак!
Монда аллалар, залимнәр, –
Кимсенеп торма елап...
Әйдә бу илдән еракка,
Нурга әйдә, әйдә син
Якты илгә – кайсы илдә
Сахралар иркен вә киң!..

Кабил

Белмәсәм дә кемлегеңне,
Һәрвакыт шәүләң синең
Нур булып күрнә ерактан,
Яктыртып бәхтем күген...
Һәрвакытта төшләремдә
Мин сине шатлык белән
Гөл-чәчәкләр уртасында,
Якты бер илдә күрәм...
Кем син, әй, рух, барлыгымны
Мәфтүн иткән утлы гөл?
Кем җибәрде монда сине?

Идея

Мин сиңа дошман түгел...

Кабил

Яшренеп һәрбер кара төндә,
Минем янга килеп
Сөйлисең:
«Мәңге газап, хәсрәткә син
Мәхкүм!» – диеп...
Сөйлисең мин аңламас сүзләр.
Тагын куллар сузып,
Күргәзәсең әллә кайда,
Нурлы ак юллар сызып.
  «Кил, – дисең син, – якты, ак
  Шатлык, бәхетләр эстәсәң,
  Ташла җирне, монда иркен илгә
  Кил! – дип. – Монда ямь.
  Монда юк Алла, Канун һәм

Эч пошу, хәсрәт», – дисең.
Кайда ул ил?

Идея

Идея кулы белән бер якка күрсәтә, еракта матур сарайлар, гөл-чәчәкләргә күмелгән урманнар, күм-күк күген яктыртып торган нурлы ай һәм ниһаясез күләгәләр күренә.

Анда күрәмсең,
Нинди киң, иркен сарай?!
Уртасында бриллиантлардан
Төзелгән нурлы ай.
Ай нурыннан зур сарайга
Тамчы-тамчы нур тама, –
Нур тама һәм якты нур
Тамган җирендә ут яна.
Ут яна... Утлар тирәсендә
Җыелган күп халык
Мәңге рәхәттә яшиләр!

Кабил
(*сокланып*)

Нинди иркенлек ул илдә,
Анда нинди яктылык,
Нинди ак нурлар сибелгәннәр,
Сарайны яктыртып!
Кемнәр анда?

Идея

Ул сарайда мәңге шатлык
Һәм ирек шаһлык сөрә,
Ул сарайда хөр йөрәк,
Көчле, батыр ирләр тора.

Кабил
(*әкрен-әкрен кыза бара*)

Анда шатлык, анда нур,
Анда бәхетле бәндәләр.
Күз камаштыргыч сибелгән
Анда нурлар, шәүләләр.
Әмма монда... Монда ачлык,
Монда михнәт, монда төн.
Каплаган җирне җәһәннәм,
Куркыныч, канлы төтен...

(*Кызу.*)

Ник, алайса, ул сарайда
Әллә кемнәр шатланып
Көн күрәләр дә? –
Нигә без соң, монда золмәттә калып,
Бер кабым ашка моңаеп,
Канлы күз яшьләр белән
Мәңге михнәттә, газапта?!

Әйт, бөек рух! Мин көтәм.

Идея

Чөнки сез – коллар,
Рәхимсезләр кулында кан сыгып
Көн күрәсез, мәлганәт
Вәхши Ходайга буйсынып.
Уйный ул күктән торып,
Сезнең газаплардан көлә,
Калдырып ерткыч, котырган
Юлбарыслар иркенә...

Кабил

Нәрсә? Бу ят сүзләрең...
Ах! Күңлемә утлар яга,
Яндырып кан юлларымны,
Нәкъ зәкъкум утлар ага...
Бармы соң бер юл
Бу золмәттән сәгадәткә таба?

Идея

Бар, ләкин ул бик ерак.
Юллар озын, һәм юлларын
Каплаган гүрләр-каберлекләр,
Диюләр кулларын
Ыржайтып саклыйлар...

Булса синдә көчле җан,
Булса рәхимсез кулларың,
Әйдә оч! Бергә ачарбыз
Без сәгадәт юлларын...

Идея сәхнәдән югала. Еракта күренеп торган матур сарайлар караңгылык эчендә юк булалар. Кабил, тезләнгән көенчә, кулларын алга таба сузып кала.

Пәрдә.

Ике күренеш арасында алты сәгать вакыт үтә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын, шул ук янар таулар. Кабил зур кара таш өстенә утырган. Әкълимә аның янында. Ул башын түбән иеп утыра. Кояш чыгар вакытлар.

Пауза.

Әкълимә

Якты төн булган чагында,
Әллә нинди сер белән
Уйганам, син юк янымда...
Юк янымда, төн белән
Ялгызым...
Ник мине син һәрвакытта
Төндә ялгыз калдырып,
Берүзең шунда киләсең
Дә иягең талдырып

Уйлыйсың төннәр буенча,
Әйт, сөеклем, әллә бармы
Алда бер-бер куркыныч?

Кабил
(*шомлы*)

Бул тыныч!

Әкълимә
(*торып*)

Әллә инде син мине
Сөймисеңме?

(*Бик тиз.*)

Юк, сөясең, соң нигә
Син сөйләмисең? –
Әллә күңлең мәңгегә
Туңдымы?

(*Тезләнә.*)

Кабил!
Мин синең алдыңда тезләнгән көйгә –
Сүз көтәм.

Пауза.

Син сөйләмисең?!

Кабил
(*Әкълимәне кочаклап*)

Төнге салкын зәмһәрирдән
Туңды күңлем, алтыным!
Мин туңам... юк күкрәгемдә
Бер янар ут – ялкыным...
Талды рух, сынды канатлар,
Мин бетәм...
Як рухыма, әй, фәрештәм,
Син тереклек ялкынын.

Әкълимә
(*тиз-тиз*)

Ник синең таушың карылган?
Ник иягең калтырый?
Күзләрең, ах, күзләреңдә
Нинди утлар ялтырый?!
Әллә ни бер куркыныч сер
Сөйләгән төсле алар:
Төртелеп, яшрен карыйлар да
Йөрәккә, нәкъ янар утлар
Йөрәкне яндыралар...
Әйт, сөеклем, нәрсә бар?!

Кабил

(*зарланып*)

Әкълимәм! Мин йоклый алмыйм,
Төн йокымнан уйганам, –
Уйганам да, нәкъ юләр-шашкан кеше, –
Кан елыйм, беркем дә белми, –
Мин тәмугларда янам!
Куркыныч, һәр як караңгы,
Ниндидер өннәр килә
Дә, улап, төннәр буенча
Як-ягымда иштелә...
Гүя миңа бар ләгыйнь көчләр
Ерактан кулларын
Өстемә төртеп сузалар да
Укыйлар кычкырып
Язмышымның мәлганәтле,
Куркынычлы юлларын...
Укыйлар... – иштеп торам мин –
Бар бөтен рухлар; тагын
Иштелә көлгән тавышлар.
Шунда чорнап дүрт ягым,
Газраилләр кулларымнан
Әллә кайда тарталар...

(*Саташып.*)

Тарталар...
Коткар, сөеклем! Зур тәмугларга алар...

(*Әкълимәнең күкрәгенә сыена.*)

Әкълимә
(*Кабилне күкрәгенә кысып*)

Син шашасың!
Ах! Син шашасың!

Кабил

Нәрсә? Мин шашам?!

(*Уйлый.*)

Әкълимәм, шаштыра мине уй, кайгылар...
Мин, тилергән юлбарыстай,
Алда ит, каннар күрәм.
Канга манчылган кәфеннәрдә
Үлек җаннар күрәм.
Ул үлек җаннар күмәкләп
Ниндидер көй көйлиләр.
Кул сузалар да миңа:
«Кил, без – синең дустың», – диләр.
Үзләре, бер канлы гәүдәне
Кочаклап, еглашып,
Зур адымнар белән атлап,

Әллә кая илтәләр...
Мин барам ул гәүдә артыннан –
Елап. Туктыйм кинәт...
...Ишелеп-ишелеп, бер коточкыч
Аждаһа күктән иңә
Дә мине ул, чорнап алып,
Җил белән тиз-тиз генә
Ташлый илтеп зур, котырган,
Көчле диңгез өстенә...
Әкълимә, Әкълимә!
Ник газаплыйлар болай
Күкләр мине гомрем буе?

Әкълимә

Күз нурым, түз! Монда бар бер
Тәңренең яшрен уе.

(*Кулларын күккә күтәреп.*)

Әй, минем бәгърем – Кабилемнең
Рәхимле Алласы!
Әйт, бу эшләр нинди бер
Яшрен сереңнең шәүләсе?

Кабил
(*ачы*)

Ул җавапсыз? Тик тора?
Мең нәләт!!

Әкълимә

Тукта, ах! Безне газапламас
Болай ул та әбәд.
Көн килер: бу кайгы-хәсрәтләр,
Газапларны алыр,
Ярлыкар, безгә тагын
Шәфкать күзен, хөкемен салыр...

Кабил

Үтте еллар... Мин сабыр иттем,
Түзеп тордым һаман.
Күз тегәп, шәфкать көтеп,
Күккә, гарешләргә табан.
Тик минем көткән бәхет,
Шатлык-өметләр алдады,
Мәрхәмәтсез Тәңрегә
Һичбер теләгем бармады, –
Өстебездән мәңгелек каргыш
Газабын алмады.

(*Әкрен.*)

Инде күкләргә минем һич-

бер теләгем калмады...

Пауза.

Мәңге сөргендә... газапта...
Нинди язмыш?!

Әкълимә

Яңадан –
Кил, сөеклем, тезләнеп
Шәфкать сорыйк без Алладан –
Ул кичәр!

Кабил

Алладан?!
Мин бүген төнлә, адашкач,
Кулларым сузган идем,
Соңгы кат ярдәм сорап, күп
Тезләнеп торган идем.
Тик минем соңгы теләкләрне
Кирегә кактылар,
Газраилләр өстемә
Күктән нәләтләр аттылар.
Иштәсеңме?! Кактылар!
Каргыш, нәләтләр аттылар!
Шунда белдем: җирдә мин берь-
ялгызым калганлыгым,
Бар гыйбадәт, сәҗдәләремнең
Бикяр, ялганлыгын...
Ул – рәхимсез!

Әкълимә

Юк, рәхимле, алтыным! Кил,
Тел тидермә Аллага.
Тотма юл, саклан, җаным,
Янган тәмугларга таба.

(*Күккә күрсәтеп.*)

Анда утлар.

Кабил

Анда утлар... Анда утлар,
Тик ул утлардан бу төн
Мин нәҗат таптым, сөеклем!

(*Әкълимәгә, яшеренеп.*)

Кайгы-хәсрәт утларында
Кайнаган мәхзун йөрәк
Берлә мин юлдан язып,
Тауларда йөргәндә, кинәт
Әллә кайдан чыкты шунда
Нурга күмлеп – кемдер ул? –
Бирде кул, кодрәт белән
Сызды миңа бер якты юл.
Якты юл – күз яшь,

Газаплардан сәгадәткә таба,
Мәңге шатлык һәм бәхет берлән
Бизәлгән дөньяга...
Кайда юк янган тәмуг,
Утлар, газаплар, аллалар;
Кайда юк мәңге газапларга
Сөрелгән бәндәләр.

Әкълимә
(*тиз-тиз генә*)

Нишләдең син? Нишләдең син?!
Куркыныч, ах! Куркыныч –
Алдыңда мин упкын күрәм.
Мәңгелек бушлык – караңгы,
Күз җиталмаслык тирән...
Син адашкансың,
Сине азгын Газазил алдаган,
Юлларыңны куркыныч пәрдә белән
Ул каплаган.

Кабил
(*кинәт*)

Әкълимәм! Сөрсә әгәр
Җирдән мине күк, аллалар,
Мәңгегә мәхкүм итеп,
Янган тәмугка салсалар;
Мәсхәрәләп, язмышым белән
Шаярсалар алар,
Газраилләр өстемә
Янган кисәүләр атсалар;
Калсам әгәр юлбарыслар
Уртасында ялгызым –
Син килерсеңме аралаучы
Булып шунда мине?..
Юкса син дә калдырырсыңмы
Янар утта мине?

Пауза.

Син тик торасың?!
Син тик торасың?

Пауза.

Син дә миңа читме әллә?

Пауза.

Әмма мин сөйдем сине...
Әй сөекле Әкълимәм, ник
Алдадың соң син мине?
Ник мине алдап сөйләдең
Һәр сораганым саен,
Ник мине кызганмадың,
Ник алдадың, якты аем?!

(*Сәхнәдән читкә атлый.*)

Мин караңгы сахрада ялгыз гына
Калдым, мине
Ташлады барлык туганнарым,
Бөтен җир, күк иле...
Качтылар миннән алар, бер
Юлбарыстан куркынып
Качкан әрләндәй алар,
Качты еракка, хурсынып.
Бер карында бергә яткан
Әкълимәм дә килмәде,
Мин чакырдым, ул ераклашты,
Миңа кул бирмәде.
Әй, мине баштан сөеп,
Бәгърем, дип алдаучы кыз!
Мин китәм ялгыз караңгы
Сахраларга мәңгегә...
Анда кошлар: «Әкълимәң
Кайда?» – дип миннән сорар, –
Мин сөйләрмен;
Хәсрәтемнән бар-бөтен
Рухлар елар.

Ашыгып, сәхнәдән атлый. Кинәт туктый, Әкълимәдә көчле хәрәкәтләр.

Әкълимә
(*алга таба атлап*)

Китмә ташлап ялгызымны,
Алтыным, кил! Монда кал!

(*Үкереп елый.*)

Китмә ялгыз,
Мин калалмыйм, ал мине,
Бу уттан ал!..

(*Кабилнең муенына сарылып.*)

Сөрсәләр дә, күз нурым,
Җирдән сине күк, аллалар,
Атсалар да, мәсхәрәләп,
Зур тәмугларга алар...
Ташламам – яклап килермен,
Утта калдырмам сине,
Әйдә, яксыннар тәмугларда
Синең белән мине!..

(*Уйлап.*)

Мин гыйбадәтләр итәрмен,
Мәңге елап ялварым.
Күз яшем белән юармын
Мин гөнаһларың,
Тагын –

Көн вә төн уйлап сорармын
Тугры хөкемен Алланың...

Кабил
(*мәсхәрә белән*)

Ул кичәрме?!
Юк. Җитәр!
Кылмыймын мин, кимсенеп,
Сәҗдә аңа моннан битәр...
Ул – залим... Сырган аның
Хөкемен мәкерләр, хәйләләр...
Бушка китте күп минем
Елап кылган сәҗдәләр...
Мин аңардан мәңгегә киттем,
Тагын да та әбәд
Кайтмамын...

Күк күкри, бөтен табигатьне дәһшәтле бер төс ала. Әкълимә сәҗдәгә егыла. Сәхнәгә шашкан Адәм балалары килеп керәләр. Тавышлар.

Кабил
(*утлы яшеннәр уртасында*)

Нәләт!
Нәләт!
Нәләт!
Нәләт!
Нәләт!

(*Тауларга кереп югала.*)

Пәрдә.

Бу күренеш белән өченче күренеш арасында биш минут вакыт үтә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын, пәрдә көчле күк күкрәүләр эчендә ачыла. Адәм балалары, тезләнеп, кулларын күккә күтәргәннәр. Арада ике яшь бала да бар.

Тавыш

Зур тәмугларымны яктым;
Мин бүген төннән алып
Яндырым шунда Кабилне,
Мәңге утларга салып...

Адәм балалары
(*Хор*)

Кул сузып, күзләрне тектек,
Әй, Иляһи, алдыңа,
Алма үч, кызган Кабилне,
Үч алу – кимлек сиңа.

Адәм

Чал сакалым берлә тезләндем,
Иляһым, күр менә.
Сал күзеңне хәсрәтемә
Бер генә, тик бер генә!
Бер минутлык сиңа кылган
Гөнаһым, гаебем өчен
Ташладың тау-тау газаплар
Мин колыңның өстенә.
Күпме ялварсам да, Тәңрем,
Хәсрәтемне алмадың.
Кызганып мискин колың,
Шәфкать күзеңне салмадың!..

*(Күк күкрәү әкренәя.)*

Чал сакалым белән тезләндем,
Иляһым, күр менә,
Какма читкә – ялварам – тик
Бер теләгемне генә!

Адәм балалары

(*Хор*)

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,
Үч алу – кимлек сиңа...

Хава

Әй гөнаһымның шаһиты,
Көч вә кодрәт Алласы!
Кайгылардан, күрче,
Канланды күземнең алмасы.
Мин, сөрелгәннән алып
Киң җәннәтеңнән дөньяга,
Күпме михнәт, канлы күз яшьләр
Агыздым дөньяда...
Кодрәтең берлән миңа
Бирдең, Иляһым, йөз бала,
Күр әнә, куллар сузып
Тезләнгән алар алдыңа!

Адәм балалары

(*Хор*)

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,
Үч алу – кимлек сиңа...

Һабил

Ул адашкан тугры юлдан,
Дәргяһың табалмаган,
Мәңгелек сөрген Газазил
Ул колыңны алдаган...
Сал үзең син тугры юлга,
Ярлыка гаебен, Рәхим!

Кодрәтең тиңсез синең һәм
Шәфкатең чиксез вә киң!

Адәм балалары

(*Хор*)

Салма безне, Тәңре, тагын
Син газапка, кайгыга,
Үтте гомребез болай да
Канлы хәсрәт, кайгыда...

Әкълимә

Күкрәгемдә ут булып
Аккан кызыл каннар белән,
Төн бетеп, һәр төндә аткан
Якты ак таңнар белән
Ант итәм, Тәңрем, минем
Бар шатлыгым тик ул гына,
Ул гына бар тормышымны
Яктыртып, нурлап тора...
Син аны үзең миңа, Тәңрем,
Бүләк иткән идең,
Ник тагын тартып аласың
Якты бәхтемне минем?
Салма хәсрәткә аны,
Тәңрем, сузам кул иркеңә!

Адәм балалары

(*Хор*)

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,
Үч алу – кимлек синә...

Ике яшь бала

Күр, синең иң кечкенә һәм
Иң гөнаһсыз колларың
Суздылар киң кодрәтеңә
Ак мамыктай кулларын;
Без сорыйбыз тезләнеп,
Тәңре, синең дәргяһыңа,
Сал күзеңне без гөнаһсыз
Колларыңның аһына...

Адәм балалары

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,
Үч алу – кимлек сиңа...

Сәхнәнең тирә-ягыннан, җырлап, фәрештәләр чыгалар. Алар уң кулларын күккә таба сузганнар.

Фәрештәләр

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,

Үч алу – кимлек сиңа...

(*Фәрештәләр тезләнәләр.*)

Сал күзеңне, шәфкать ит,
Кодрәт әләмеңне күтәр,
Җир йөзеннән мәңгелек
Хәсрәт, газапларны китәр!

Адәм балалары һәм фәрештәләр

Алма үч, Тәңре, Кабилдән,
Үч алу – кимлек сиңа...

Кинәт бик каты күк күкри. Адәм балалары арасында курку тавышлары ишетелә. Алар бер-берләренә сырышалар. Фәрештәләр сәҗдәгә китәләр. Сәхнә яктырып,
сәхнәгә Җәбраил-Канун килеп керә. Адәм балалары тезләнәләр.

Канун

Кылмагыз юкка гыйбадәтләр
Аның өчен Аллага –
Сәҗдә итте ул бүген
Төндә Ходайдан башкага...
Юк аңар шәфкать Ходайдан,
Ул – әбәдлек дошманы,
Яндырыр, мәңге кичермәс,
Зур тәмугларда аны!
Кил, Адәм! Тәңре сиңа
Күндерде кодрәт фәрманы,
Әкълимәне бир Һабилгә!

Адәм балалары

Һабилгә, Һабилгә?..

Канун

Әйе, Һабил алсын аны!..
Бергә торсыннар алар,
Кушылып кыяматкә кадәр,
Бергә кылсыннар гыйбадәтләр,
Шөкерләр, сәҗдәләр...
Якты Тәңре зур тәмугларын
Бүген төннән алып,
Яндырыр шунда Кабилне,
Мәңге утларга салып...

Һабил

Нәрсә? Әкълимәне миңа? Тәңре!..

Канун

Бу – Тәңренең үзгәрмәс әмре!

Әкълимә

Тәңре... Тәңре... Тәңре...

Һушсыз булып, җиргә егыла. Канун сәхнәдән югала, көчле күк күкрәүләре астында пәрдә ябыла.

Пәрдә.

Бу күренеш белән өченче күренеш арасында унике сәгать вакыт үтә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таулар арасы. Янар таулар ут атып тора. Көн бетеп, кояш иңәр вакытлар. Тирә-як тын. Сирәк-сирәк сандугач тавышлары. Тагын тынлык. Пәрдә күтәрелгәндә, сәхнәдә берәү дә юк. Серле музыка. Бераздан сәхнәгә, ашыгып, Кабил белән Әкълимә керә.

Кабил

Әйдә, бу каргалган илдән
Без сәгадәткә таба
Юл салыйк, очыйк икәү
Иркен хәятлы дөньяга!
Кайда юк Алла, Канун
Һәм эч пошу, хәсрәт, көек;
Кайда без иркен яшәрбез,
Хөр, азат җилләр кебек...

Әкълимә

(*Әкълимәдә көчле хәрәкәтләр. Ул, Кабилдән аерылып*)

Мин калам, моннан киталмыйм...
...................
Хөр йөрәгемне минем кыскан
Тимердән алкалар.
Мин киталмыйм, мин өзалмыйм –
Утлы зынҗырлар алар...

Кабил

(*Әкълимәне кочаклап*)

Калма, юк. Әйдә минем белән,
Икәүләп без качыйк,
Теткәләп бу шомлы сәдләрне,
Сәгадәткә ашыйк...
Күкрәгемдә изге антым
Төсле яшреп, мин сине
Саклармын бар юлбарыслардан, –
Тидертмәм. Ант итәм!

(*Тезләнеп.*)

Әкълимәм! Калдырма син ялгыз мине.

Әкълимә

(*уйлый, кинәт сискәнеп*)

Куркыныч... Юк, юлларымда
Сакчылар...

(*Кулын күккә күтәреп.*)

Һәм Алла бар!..

Кабил

Хөр мәхәббәтнең көченнән
Җимрелер, өзлер алар!
Әйдә, без анда табарбыз
Киң, Ходайсыз дөньялар,
Һәм дә аннан яудырырбыз
Мәңге ләгънәтләр аңар!

Әкълимә
(*тиз генә*)

Кайда барсак та, аңардан
Без качалмабыз, күрер
Дә, җибәреп аждаһаларын,
Диюләрен – барын,
Бәхтебезне утлы төн,
Дүзәхкә ул әүрелдерер.
Ай, кояш, йолдызларын да
Мәңгелеккә сүндерер.

Кабил

Сүнсә йолдызлар, сәмави
Күзләреңнән нур алыр,
Таң туар гөлләргә төренеп,
Мәңгегә төннәр валыр...
Әйдә, оч анда, канатлан
Сахраларга, хур кызым.

*(Ялынып.)*

Әкълимәм! Әйдә, сөеклем!

Әкълимә

Кабилем, ах! Йолдызым!
Әллә нәрсә сизенә күңлем,
Әллә ниләр уйланам.
Кабилем! Белсәң иде, ах!
Мин тәмугларда янам...
Бар табигать, бар агачлар,
Сандугачлар, лаләләр –
Барсы да тәкрар итәләр:
«Сез – хаиннәр!» – ди алар...

Кабил

Бул тыныч, бәгърем, сөеклем!
Безгә юк бер куркыныч...

Әкрен генә сәхнәдән атлыйлар. Кинәт күк күкри, Әкълимә Кабилнең күкрәгенә яшеренә. Сәхнәгә Канун-Җәбраил килеп керә. Ул, Әкълимә белән
Кабилне аерып, урталарына баса. Әкълимә тезләнә.

Кабил
*(чигенеп)*

Канун?..

(*Мәсхәрә белән.*)

Ни кирәк миннән сиңа?
Әллә тагын да Алладан
Бер әмер бармы минем өчен?

Канун
(*мәһабәт*)

Әйе, бар хак Мәүлядан!
Куй бу фикреңне, Кабил, син
Тәүбә ит, тезлән аңар!

Кабил
*(мәсхәрә белән)*

Тезләнергә?!
Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!
Юк, минем өчен
Җирдә башка Алла бар...
Бар, хәзер кит! Оч кире,
Кайт көчле, залим Тәңреңә!
Әйт аңар, буйсынмыймын
Мин ул залимнең әмренә!
Тар бишектән Әкълимәмне
Шатлыгым дип асрадым,
Йокламый төннәр буенча,
Күкрәгемдә сер итеп, –
Ант итәм, – бар шомлы көчләр-
дән яшердем, сакладым...
Инде мин син, син
Хаиннән кул тидертмәм...
Кит! Югал!..
Юкса бел!..

Кабил Канунга таба ташлана. Канун, ачы көлеп, Кабилне Әкълимә янынннан көчле рәвештә этеп җибәрә. Кабил җиргә егыла. Канун сәхнәдән Әкълимәне тартып алып югала. Кабил җиргә капланып кала. Сәхнәгә Идея-Газазил чыга. Ул Кабилгә якын килә.

Идея

Тор, Кабил! Тор, кимсенеп ятма,
Түбәнләндең, җитәр.
Аллаларга каршы ләгънәт,
Үч алу кылчын күтәр!

*(Кылыч чыгарып ялтырата.)*

Мин куылганда оҗмахтан,
Мәлганәт камтын киеп,
Һәм чыгып барганда оҗмахтан,
«Мин»легемә баш иеп,
Читтә йоклап яткан оҗмах
Сакчысының хәнҗәрен
Тартып алдым, хәсрәтемнең
Ядкяре булсын диеп...
Ятма, тор! Ал бу кылычны!

Ал аны, кулыңа алып
Ялтырат бер кычкырып, бар
Җиргә ут-ялкын салып!
Ул кылычның ялкыныннан
Күк янар, гөлләр шиңәр,
Тетри-тетри бар кануннар
Синең алда баш ияр.

*(Кабилгә нидер иелеп сөйли һәм, кылычын Кабилнең алдына кадап, сәхнәдән югала.)*

Пауза.

Кабил, җирдән башын күтәреп, тирә-якка карана.

Кабил

Кайда ул рух?
Ник югалды,
Канлы кылычын калдырып,
Күкрәгемдә әллә нинди
Ялкын утлар яндырып?..
Нинди сер ул сөйләде?
Чү! Нәрсә әйтте?
Ах! Янам!..
Чәйни бәгъремне еланнар,
Өзгәлиләр, мин тәмам
Шаштым...

Пауза.

(*Тирә-якка каранып, Әкълимәне эзли. Кинәт башын тотып, бик каты.*)

Әльәман, аһ! Әльәман!..

(*Акылсызланып кычкыра.*)

Әкълимә!

Тынлык.

Әкълимә!

Тынлык.

Юк беркем дә...
Барлыгымны алдылар...
Алдылар... Ах! Зобанилар!
Янган утка салдылар!..
Яшренеп бәхтем күгендә,
Бер нурым калган иде,
Бер юанычым булып, бер
Ул гына, тик ул гына,
Тормышымда нур биреп,
Әкрен генә янган иде...
Күрде җәлладлар аны да,
Күрделәр, кызгандылар.
Килделәр дә мәңгегә
Тартып кулымнан алдылар!..

*(Тора. Кылычын җирдән алып, һавада болгап.)*

Калмады бер сердәшем дә.
Әй, хаин Алла, минем
Күз карашымнан югалды
Бар канун, хөкмең синең...
Мин хәзер женнәр туенда
Җил белән,
Хөкмеңә каршы давыл
Үкреп исәм,
Таптыймын гөлләр вә сөнбелләр илен.
Каплыймын җирне үләксә һәм
Кара комнар белән...

Сәхнәдән ашыгып чыгып барганда, Адәм килеп керә.

Адәм

Нәрсә бу? Кемгә каһәр?

Кабил

Ерткыч, зобани Аллага!

Адәм

Мәүлямә?

Кабил

Әйе, аңа!
Инде куллардан өзелде
Соңгы ут зынҗырлары.
Көл булып янды, тетелде
Хөр йөрәгемне минем
Чорнап алган куркынычлы,
Канлы кодрәт куллары...
Бел: хәзер күкрәк минем
Тулган кара көчләр белән;
Нәкъ җәһәннәмдәй яна
Яшрен, бөек үчләр белән...

(*Кабил Адәмгә якын килеп, әкрен һәм серле.*)

Бирәмсез Әкълимәмне,
Әткәем, вөждан белән,
Бел, аны тартып алам мин
Бик бөек корбан белән!..

Адәм

Алланың хөкеме шулай.

Кабил

Ул – каһәр, ләгънәт аңарга!

Адәм

Йа Ходай!

Кабил

Ул гадил булса, нигә соң
Күкрәгемә ут салып
Яндыра? –
Күз яшьләремне тамдыра,
Бәхтем алып...
Ул – каһәр! Әйдә чыгарсын
Зилзилә, дулкыннарын, –
Әйдә йотсыннар мине!

Адәм

Кабил, онытма!

*(Кулын күккә күрсәтеп.)*

Анда ут – дүзәх барын...

Кабил

Әйдә яндырсын мине.
Яксын җәһәннәм утларын,
Атсын әйдә Газраилләр
Өстемә ут, укларын!
Курыкмыймын мин, ул – каһәр, дим;
Каргыймын мин, ул – хаин!
Ишетәсеңме?! Ул – хаин!

Адәм
(*кулларын күтәреп*)

Йа Рәхим!

Кабил

Ник мине ул, ник яраткан,
Куймагач юл иркемә?!
Ник минем бәхтемне биргән
Башкаларның иркенә?!

*(Бик каты.)*

Ант итәм иркем белән, бел!
Әкълимә булыр минем.
Бирмимен мин башкаларга –
Ул – минем Аллам, динем!

Адәм
*(күз яше белән)*

Ник тудырдым мин сине?
Ах! Ник бала дип асрадым?
Ник сине туган вакыттук
Янган утка атмадым?!

Кабил
*(нервный)*

Ник атмадың?!

Адәм

Көчле утлар, зур тәмуглар
Мәңгелек йортың булыр.

(*Йомшак.*)

Тәүбә ит! Кил, сөйләмә – ул куркыныч...

Кабил

Тәүбә!
Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!
Бул тыныч!
Мин табынмыйм ул Ходайга,
Ул Ходай җәббар, явыз,
Мин табам башка Ходай,
Ярдәмчене, бел: ул – кылыч!

Кылычын ялтыратып, ашыгып сәхнәдән югала. Адәм аның артыннан бара да бик тиз кире кайта.

Адәм

Кылыч??!
Ләүхе мәхфуз битләрендә
Күргән идем мин аны...

Тавыш.

Ул кылыч батырыр кара канга
Бөтен җир-дөньяны,
Ул кылыч – шәфкать-мәхәббәт дошманы!..

Адәм
*(кулларын күтәреп тезләнә)*

Йа Ходай! Бирмә Кабилгә син аны!..

Пәрдә.

Бу күренеш белән бишенче күренеш арасында җиде сәгать вакыт үтә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Янар таулар туктаусыз ут атып торалар. Пәрдә күк күкрәүләр, утлы яшеннәр уртасында ачылып, бөтен дөньяны кызыл канга батырып, җир өстенә беренче мәртәбә Газраил иңә. Аның күзләре коточкыч ачылган, ул мәһабәт.

Газраил

Мин бүген төннән алып
Җир йолдызында мәңгегә
Кан түгеп, җаннар алырга
Тезләнеп антлар белән
Вәгъдә бирдем Тәңрегә...
Тетри-тетри, кятибиннәр,
Минем алда баш иеп,
Ләүхе мәхфуз битләренә
Яздылар утлар белән:
«Мин – мәхәббәт, мәрхәмәткә
Мәңгегә дошман!» – диеп...

*(Ачу һәм ачы мәсхәрә белән.)*

Яздылар утлар белән:
«Мин – мәхәббәт, мәрхәмәткә
Мәңгегә дошман!» – диеп...

(*Газраилдә ниндидер ят хәрәкәтләр күренә. Ачы.*)

Инде моннан соң минем
Эчкән суым каннар булыр;
Мәскәнем – салкын каберләр,
Мәңгелек тәхтем минем
Баш сөякләрдән өелгән
Зур, биек таулар булыр...

(*Җир йөзенә.*)

Куркыныч хәсрәт уты,
Әй җир йөзе, каплар сине!..
Күкрәгеңә кап-кара каннар
Сеңәр, таплар сине...
Ак чәчәкләргә күмелгән
Фирдәвестәй кырларың-
да суярмын мин аяусыз
Сөрген илнең улларын.
Нинди язмыш?!

(*Каргышлы һәм газаплы уйга кала.*)

Нәрсә уйлыйм?!

*Көчле күк күкрәү. Газраил, тезләнеп, кулларын күккә күтәрә.*

Әй Тәгалә! Шәфкать ит,
Мин сиңа биргән бөек антымда,
Вәгъдәмдә сабит!..

(*Ашыгып, сәхнәдән югала.*)

Тирә-якта коточкыч юлбарыс, арыслан, киек тавышлары. Саташкан бер төстә Әкълимә керә.

Әкълимә

Уйгаталар да йокыдан
Төнге гыйфритләр килеп
Сөйлиләр:
«Җаннан сөеклең – Кабилең
Үлде...» – диеп...

(*Тауларга карап.*)

Төнге таулар, сез беләмсез?
Кайда ул, кайда тора?
Ул исәнме? Кайда ул
Ялгыз бу төнне уздыра?..

Пауза.

Нигә соң сез тик торасыз?
Нигә сез эндәшмисез?

Пауза.

Вәхшиләр!

(*Тирә-якка каранып.*)

Кайда ул? Кайдан табыйм мин?
Кап-караңгы... Ни эшлим?
Куркыныч төн! Ник яшердең
Син Кабилемне минем?!
Ник аны син күз каршымнан
Сихерләп каплыйсың
Да үзең мөдһиш,
Янып сүнгән җәһәннәм тынлыгы
Уртасында алтынымны
Бер убырдай саклыйсың?

(*Тезләнеп.*)

Тулган ай! Төн патшасы, чык!
Чык, болытларны тарат!
Ач юлымны, күр менә: мин
Тезләнеп, күккә карап,
Сүз көтәм.

Пауза.

Син сөйләмисең?

Тынлык.

Кем дә миңа сөйләми...
Вәхшиләр!..
Кем белә? Ах! Кем белә, кайда
Сөеклем, алтыным
Уздыра бу куркыныч төннең
Зәһәрле салкынын...

(*Ашыгып, алга таба атлый. Кинәт чигә һәм, шашып.*)

Нәрсә? – Ул ялгыз гына
Тауларда йоклый? – Күр, әнә
Әйләнәсендә, улап, ач
Юлбарыслар әйләнә...
Әйләнәләр дә улыйлар,
Тукта, чорнап алдылар...
...Алдылар!..
Ах! Өстенә ташландылар!!

Тавышсыз булып җиргә егыла. Тынлык. Серле музыка. Таулар арасыннан, җырлап, фәрештәләр чыгалар. Алар Әкълимәне урап әйләнәләр.

Фәрештәләр
(*җырлап*)

Ник яраттың җиргә, Тәңре,

Син мәхәббәт утларын?!
Ник яраттың канлы күз яшьләр,
Газапларның барын?..
Ник мәхәббәтне яраттың?
Ник яраттың да аны, –
Ут итеп шул ялкын утка
Ташладың ник бәндәне?..
Ник җиреңне, бар җиреңне
Фирдәвестәй итмәдең,
Ник бөтен җиргә үзеңнең
Рәхмәтеңне сипмәдең?
Ал җир өстеннән, Иляһи,
Ал газапларның барын,
Ач сәгадәт юлларын,
Сүндер җәһәннәм утларын!..

Көчле күк күкрәү. Фәрештәләр, тезләнеп, сәҗдәгә китәләр һәм, торып, җырлый-җырлый, сәхнәдән югалалар.

Әйе, бу, Тәңре, синең
Безгә белемсез серләрең;
Без, зәгыйфь коллар, белалмыйбыз
Каанлык серләрен...
Без сәламлибез сине тик
Төн сәламнәре белән,
Зурлыйбыз зурлык, каанлыкның
Әләмнәре белән...

Бераз тынлык. Еракта Адәм балаларының тавышлары ишетелә.

*(Хор)*

Төн караңгы, куркыныч,
Һәр як кабер төсле тыныч...
Бер тавыш юк... Коточыргыч
Куркыныч... Ах! Куркыныч...

*(Хор якыная.)*

Шундый төндә, шомлы төндә,
Безне калдырып, нигә
Төнге золмәткә югалдың,
Әкълимә, ах! Әкълимә?!

Адәм балалары сәхнәгә килеп керәләр. Һабил алда.

*(Хор)*

Төн караңгы, куркыныч,
Һәр як кабер төсле тыныч...
Бер тавыш юк, коточыргыч
Куркыныч... Ах! Куркыныч!..

Һабил
(*Әкълимәне күреп*)

Туктагыз, монда җир өстендә
Нидер ауный менә.

Адәм балалары арасында көчле хәрәкәтләр. Чигәләр.

Беренче Адәм баласы
(*алга атлап*)

Юлбарыс!

Икенче Адәм баласы
(*шулай ук*)

Ерткыч!

Һабил
(*Әкълимәгә якын килеп, танып*)

Әкълимә! Әкълимә!

Әкълимәнең гәүдәсе өстенә ташлана. Адәм балалары Әкълимәне сырып алалар.

Хава
(*тезләнеп*)

Күкрәгеннән ак сөтен
Назлап имезгән карт анаң
Алдыңа тезләнде, уйган!
Тор, күзеңне ач, балам!..
Ач күзеңне! Ник болай
Сулган синең ак йөзләрең?
Ник йомылган һич ачылмас
Төсле – янган күзләрең?!

(*Үкереп елый.*)

Әллә кайтмаска тагын да
Мәңгелеккә, мәңгегә,
Безне ташлап, син юнәлдеңме
Яраткан Тәңрегә?..

Адәм
*(күкләргә)*

Бармы бер чик?!

Пауза.

(*Кинәт балалары алдына тезләнә.*)

Әй бәхетсез улларым!..
Мин китердем җиргә бу
Хәсрәт, газапларның барын;
Капладым сезгә ачылмаска
Сәгадәт юлларын...
Булса сезнең күңлегездә
Әз генә шәфкать әгәр, –
Кичерегез!.. Йә, карт атагызны менә
Таптагыз, җиргә салып, сез
Көлгә дүнгәнгә кадәр!..

(*Үкереп елап, сәхнәдән югала.*)

Адәм балалары арасында көчле хәрәкәтләр. Аларның күбесе Адәм киткән якка ташланалар.

Адәм балалары

Әткәй, әткәй!

Елау тавышлары.

Хава
*(торып)*

Ятмасын, җирдән алыгыз!

Адәм балалары, Әкълимәне күтәреп, әкрен генә сәхнәдән атлыйлар.
Һабил ялгыз кала.

Адәм балалары

(*Хор*)

Салма, Тәңре, безне тагын
Син газапка, кайгыга,
Үтте гомребез болай да
Канлы хәсрәт-кайгыда...

(*Сәхнәдән югалалар.*)

Һабил ялгыз калып, тезләнеп, кулларын күккә күтәрә.

Һабил

Ялварам, төн Тәңресе!
Шәфкать күзеңне сал миңа,
Күр менә, керсез күңел белән
Тагын да алдыңа
Тезләнеп, мин күзләремнән
Кан катыш яшьләр түгәм,
Саф күңел белән, сине зурлап,
Кара җирне үбәм.

(*Сәҗдәгә китә. Башын күтәреп.*)

Иштәсеңме сүзләремне,
Күз саламсың син миңа?
Алма үч, Тәңрем, Кабилдән
Үч алу – кимлек сиңа...
Ал кирәксә, ал җанымны,
Ал, Иляһым, ал да аны
Сал тәмугларга, газапла, –
Тик, бөеклек солтаны,
Син газаплама Кабилне!
Куйма, Тәңрем, киртә итеп,
Бер-берен сөйгән ике
Яшь күңелләрнең сәгадәт
Юлларын каплап, мине...
Ал мине! Ал юлларыннан,
Ал җиреңнән гаршеңә!
Анда, мәңге буйсынып, мин
Бар боерган әмреңә
Сәҗдә итәрмен, торырмын
Мин мәләкләрең белән...

(*Сәҗдәгә китә.*)

Сәхнәнең арт ягында Кабил күренә. Ул Һабилне күрми, агачлар арасында сөйләнә.

Кабил

Бер әмер шуннан...
Тәмуглар сакчысы тиз-тиз генә
Килде дә ут ташлады
Гыйшкым сарае өстенә...
Ташлады, ах! Мең нәләт!
Гомрем буе табынып, сөеп
Килгән иркәмне – сөекле
Әкълимәмне – вәхшиләр,
Күкрәгемнән өзгәләп,
Бәгъремне тартып алдылар...
Алдылар да аттылар бер
Юлбарысның куенына,

Мин, тилергән ач бүре
Төсле улап,
Читтә калдым, кан сыгып ялгыз гына...
Әй, тәмуглар Алласы!
Мин ант итәм таңнар белән,
Ант итәм мәңге тәмугында
Янар җаннар белән!
Сүндердем бәхтем сараена
Кабынган утларың-
ны туганымның бугазыннан
Агар каннар белән!!

(*Якын атлый. Һабилне күреп, артка таба чигә. Үз-үзенә.*)

Тукта, кем бу монда ялгыз?
Чү, Һабил мескен, синең

(*Хәнҗәрен ала.*)

Җитте инде соңгы гомрең.

Сәхнәгә Газраил чыга.

Бу суык хәнҗәр минем
Өзгәләр бәгъремне сырган
Бар әсирлек бауларын,
Теткәләр алдымдагы барлык
Каанлык тауларын!

(*Хәнҗәре белән Һабилне чәнчи.*)

Газраил Һабилгә таба канлы байрагын суза да югала. Күктән җиргә дәһшәтле тавышлар уртасында ташлар ява башлый. Кабил чигә-чигә, кинәт юл эзләгәндәй
кулларын алга таба сузып, озак ук йөри.

Пауза.

Кабил

Нишләдем мин?

(*Шашкынлык.*)

Нишләдем мин?

Пауза.

Бар да бетте... Мин кара
Төндә югалттым юлларым...
Канга батты зур теләкләргә
Сузылган кулларым...
Алда упкын... Артта ут...
Уңда Һабилнең гәүдәсе...
Кайда юл?.. Кайда сәмави яктылык
Берлә янган идеалымның
Сихерле шәүләсе?!
Бар да каннарга күмелде,
Кап-караңгы – мин бетәм...

(*Һабилнең гәүдәсенә таба кулларын сузып.*)

Тор, Һабил! Тор, суз кулыңны,
Мин синең хөкмең көтәм...
Канлы күкләр киртә итеп
Юлыма куйгач сине,
Үч итеп күкләргә үтердем...
Һабил... Кичер мине!

Һабилнең канлы гәүдәсе өстенә ташлана. Серле музыка. Сәхнә яктырып, болытлар өстендә фәрештәләр заһир булалар. Алар Әкълимәне күкләргә алып баралар.

Фәрештәләр
*(җырлый)*

Атма, таң! Чыкма, кояш!
Нурлар сибеп син дөньяга,
Куркынырсың, куркынырсың,
Куркыныч... Ах! Дөньяда...
Тау башында канлы гәүдә, –
Бер гөнаһсыз ир бала,
Иң беренче кат җиһанда
Җан биреп әрнеп ята.
Атма, таң! Чыкма, кояш!
Нурлар сибеп син дөньяга,
Куркынырсың, куркынырсың,
Куркыныч... Ах! Дөньяда...
Иң беренче – җирдә Кабил,
Алланың хөкемен бозып,
Мәңгегә дуслык, туганлык
Чәчкәсен алды өзеп.
Калды дөнья мәңге нурсыз,
Мәңге хәсрәтле, кара...
Калды рухларда аның
Канлы кулыннан зур яра...
Атма, таң! Чыкма, кояш!
Нурлар сибеп син дөньяга,
Куркынырсың, куркынырсың,
Куркыныч... Ах! Дөньяда!

Әкълимәнең фәрештәләр арасында тавышы ишетелә.

Әкълимә

Ал канатыңны, Микаил!
Бер генә, тик бер генә
Күз салыйм мин соңгы кат
Торган җиремнең өстенә.
Анда калды пакь фәрештәм,
Күз нурым анда минем
Калды ялгыз тилмереп,
Калды минем
Җәннәтем, изге илем...
Ал канатыңны, Микаил,
Бер генә, тик бер генә
Күз салыйм бәгърем-сөеклем,
Алтынымның өстенә...

Микаил канатын ала. Фәрештәләр арасында Әкълимә күренә, аның чәчләре кара болыт кебек тузган.

*(Җир өстенә карап.)*

Кем белә? Ах! Кем белә,
Кайда сөеклем, алтыным
Уздыра бу куркыныч
Төннең зәһәрле салкынын?..
Төн җиле! Бар, Кабилемнең
Чәчләреннән сөй дә син
Әйт аңарга: «Мин хәзер
Бар нәрсәдән калдым ятим...»

Микаил

Нинди күз яшьләр бу, Тәңрем?
Кулларымны яндыра,
Зарлары туңган йөрәгемне
Кисә, сызландыра...

(*Җир өстенә күргәзеп.*)

Ач күзеңне, җир кызы!
Күрнеп тора торган җирең,
Күр, әнә анда Кабилең!

Әкълимә
*(кулларын сузып)*

Кабилем, ах, Кабилем!
Тор йокыңнан, кил бире,
Үбием сине мин соңгы кат,
Яд итәрсең, Әкълимәңне
Бик сагынганда елап...

Фәрештәләр ерагаялар. Ерактан Әкълимәнең тавышы ишетелә.

Әлфирак, ах! Әлфирак!

Фәрештәләр
(*җырлый*)

Атма, таң! Чыкма, кояш!
Нурлар сибеп син дөньяга,
Куркынырсың, куркынырсың,
Куркыныч... Ах! Дөньяда!

(*Югалалар.*)

Кабил
(*җирдән башын күтәреп, тирә-якка карана*)

Бу сихерле, моңлы өннәр
Нинди җирдән иштелә;
Нинди рухлар җырлый, бу
Көйләр миңа кайдан килә?..

(*Тора.*)

Бу тавышлар гүя миңа:
«Син, Кабил, шаштың!» – диләр.
Кемнәр ул, әй! Бу нәләтле,
Шомлы көйне көйлиләр?!

(*Күзләрен күкләргә тегә, кинәт чигә.*)

Тукта! Анда әллә нәрсә
Серле очкыннар белән
Кайный күкләрдә сихерле
Шәгъләләрдән бер күләм.

(*Әкълимәне танып.*)

Нәрсә? Ах, мин шашам!

(*Кулларын күккә сузып, таулар өстенә ташлана.*)

Әкълимә, Әкълимә!..

Күк күкри. Күктән ташлар ява башлый. Сәхнәнең тирә-ягыннан Кабилгә таба ялангач куллар сузыла. Кылычлар ялтырый. Канун, Кабилнең юлын кисеп.

Канун

(*мәһабәт*)

Сузма канлы кулларыңны
Анда күкләргә таба,
Сузма, пычрак кулларыңнан
Тамчылап каннар тама!
Бәдбәхет, мәгърур җир улы,
Тәңренең әмре белән
Мәңгегә мәхкүм син утларда
Янарга. Тәңредән
Юк нәҗат, бел, юлларыңны
Бәйләде ут сәдләре,
Як-ягыңны чорнап алды
Газраилләр гаскәре!..

Сәхнәнең тирә-ягыннан шыр сөяктән гәүдәләр чыга.

Кабил

(*шашып көлә*)

Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!
Як-ягымны чорнап алган
Газраилләр гаскәре!..

(*Кулындагы хәнҗәрен бутап, бер алга, бер артка тая-тая сөйли.*)

Кызганыч коллар... Баһадирлар!..
Юкка гына алданып –
Килдегез сез, кулларымны
Бәйләп алырга минем,
Күктәге шәүкәт, газамәт
Алласына ялланып!..
Кол булып тусам да җирдә,
Буйсынып күк әмренә,
Инде белегез: мин аны җиңдем
Хәзер һәм, шатланып,
Үз теләгем берлә чәнчим
Хәнҗәремне бәгъремә!..

*(Хәнҗәрен күкрәгенә чәнчеп, җир өстенә егыла.)*

Күкләр

*(көлә)*

Ха-ха-ха-ха-ха-ха!
Үз теләге берлә чәнечте
Хәнҗәрен ул бәгъренә...

Шәүкәтле, мәсхәрәле көлүләр уртасында пәрдә төшә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

### Эпилог

Пәрдә күтәрелә. Кабилнең гәүдәсе янында Идея. Ул Кабилнең гәүдәсе өстенә бик озак кулларын сузып тора.

Идея

Үлде ул... Үлде... Ләкин
Ишетелми калмас зарлары,
Җиргә сеңмәс, мәңге кипмәс
Монда тамган каннары...
Кайгыларын сөйләп илгә,

Хөр-азат җилләр исәр,
Җиргә тамган каннарыннан
Ал-кызыл гөлләр үсәр...

(*Кабилнең гәүдәсенә иелеп.*)

Бул тыныч! Кабрең булыр киң, –
Хөр күңелләр кәгъбәсе,
Һәм дә анда мәңге кайнар
Үч алу кан шәүләсе!..

(*Шәүкәтле янау тавышы белән.*)

Бетмәде канлы көрәш
Кабилнең үлүе белән,
Бетмәде аның теләге
Җиргә күмелү белән!
Мин бөтен рухларны
Күккә каршы аякландырам,
Җир йөзендә үч белән
Зур-зур тәмуглар яндырам!
Көн килер, кодрәт әләмем
Җир күгендә ялтырар,
Кодрәтемнән җимрелер
Күкләр, тәхетләр, гаршеләр!
Тез чүгәр алдымда бар көчләр,
Мәләкләр, аллалар!
Күктә канлы Алла булса,
Җирдә башка Алла бар!

(*Ашыгып, сәхнәдән югала.*)

Пәрдә.

## ТАҢ КЫЗЫ

Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа,
Гөлләреңне ыргытып, бер елмайдың да
Ник яшерендең, төренеп таң нурларына?

Мин бара идем ялгыз гына урман буйлап,
Ат өстендә тирән серле уйлар уйлап,
Тиргә баткан туры атымның ефәк ялын
Туздырып, тагын үреп, уйнап-уйнап.
Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
Тәмуг гөлен тотып нечкә кулларыңа?
Күз аттың да күзләремә, ник ыргыттың
Уйнап-уйнап мине тәмуг утларына?

Шәүкәт белән таң нурлары арасыннан,
Бәхет эзләп, илдән илгә барган чакта,
Таң кызы, Гөл, ник чыктың да юлларыма,
Бәхет гөлен тотып нечкә кулларыңа,
Маңгаемнан үбеп мине, ник югалдың,
Тагын кире төренеп таң нурларына?

Хәнҗәремне кулыма алып әкрен генә,
Таң алдында карурманнан яшрен генә
Яу өстенә барган чакта, кинәт кенә,
Таң кызы, Гөл, ник чыктың да юлларыма,
Кискен хәнҗәр тотып нечкә кулларыңа,
Чәнчеп бәгърем уртасына хәнҗәреңне,
Ник югалдың, төренеп таң нурларына?

Таң да атты. Ай да батты. Мин кузгалмыйм:
Таң сахирәсен ат өстендә туктап көтәм,
Тагын килер, сөяр диеп – алыр диеп
Хәнҗәрен ул канга баткан күкрәгемнән...

## ОНЫТЫЛГАН АНТ

Уйный-уйный таң алдында әкрен генә,
Җилләр килеп тәрәзәмне кагалар да:
«Син уйлыйсың, шашкан кеше?» –
Диләр дә, алар
Тагын бик тиз югалалар далаларга.

### I

Таянып мин ак ефәктән мендәремә,
Карап ятам бакчамдагы гөлләремә.
Алар шиңгән; селкенәләр арлы-бирле,
Түзалмыйча көзнең ачы җилләренә.
Уйный-уйный таң алдында әкрен генә,
Җилләр килеп тәрәзәмне кагалар да:
«Син уйлыйсың, шашкан кеше?» –
Диләр дә, алар
Тагын бик тиз югалалар далаларга.

### II

Төн сакчысы – тулган ай да батты күптән,
Таң пәрдәсе күтәрелде күк читеннән.
Ялгызым ашгып-ашгып нидер уйлыйм,
Табалмыйм; нидер эзлим кара төннән,
Гүя күңлем кәгъбәсеннән мәгъбүдәмне
Йоклаганда пәриләрдән алдырганмын,
Гүя бәхтем кошын артта – томаннарда
Берьялгызын онытып мин калдырганмын.

### III

Тукта! Кем ул минем янда тузылып яткан?!
Елан кебек толымнары сузылып яткан.
Нинди ят кыз оялмыйча күкрәгемә
Зәмһәрирдәй суык, салкын кулын аткан?
Кем ул?.. Ах! Мин шашам...
Ул... Ул – бер төн кызы;
Исме аның – Галия, ул – бер җен кызы.
Ничек кергән дә ул минем ятагыма,
Ничек мин соң тиңсез башым оялмыйча
Игәнмен бер пәри кызы аягына?..

### IV

Җилләр, килеп, тәрәзәмне кагалар да:
«Ник хыянәт иттең, – диләр, – син аңарга?»
Ыжгырышып алар, берен-берсе куып,
Тагын бик тиз югалалар далаларга.
Таң сызылгач, җилләр белән бер күләгә,
Төренеп ал гөлләргә, ул килә дә,
Күргәзеп ак мәрмәрдәй кулы белән
Тыныч кына йоклап яткан Галиягә:
– Оныттың! – ди.

Үзе җиләс җилләр белән,
Җитез генә җилфердәтеп канатларын,
Очып китә:
– Мин идем бит, мин идем, – дип, –
Кайчандыр, егет, синең яратканың.
Хәтерлимсең, бәхтең эзләп барган чакта,
Мәхәббәт сахрасыннан үткән идең;
Сахраның сакчысы мин – Фәйрүзәне,
Антлар биреп, уң битемнән үпкән идең,
Үпкән идең...
Хәтерлимсең, сөйгән идең?!
Кайтырмын, дип киткән идең,
А... Киткән идең... –
Китте дә тагы кире килмәде ул;
Тәрәзәмнән кулым суздым –
Бирмәде кул.
Фәйрүзәм!
Мин адаштым, табалмыйм юл...
Үткәннәр... Үткәннәргә күмелгән ул...

**V**

Ефәк үргән чәчләремне туздырам да,
Шашып, төннәр буе йөрим мин урамда.

Очраганнар! Әйтегезче, сөйләгезче,
Кайда ул җир – гөл түгелгән серле сахра?..

## *1922*

### КҮЛӘГӘЛӘР

**I**

Йокы бирми һаман... һаман...
Төн буенча ишек кага, кем ул килгән?
Нигә шулай, тыныч бирми, газаплыйлар,
Ни кирәк хаиннәргә инде миннән?
Барып ачам, берәү керә. Кулын сузган.
Матур бер сын, кәфенле һәм озын, тузган
Чәче, каплап зифа буен, күкрәкләрен,
Кочаклап билләреннән, тезен узган.
Мин ашыгып барам да: «Син кем?!» – дим.
Ул кинәт йөзен каплый,
Сөрлегеп, әкрен генә читкә атлый,
Башын тотып ике кулы белән, кинәт
Тиз-тиз генә минем яннан китә башлый.

**II**

– Буй кыз! Тукта, китмә! Ах! Син нигә
Капладың да йөзләреңне, күзләреңне
Җиргә тегеп уйга талдың? Әллә сине
Рәнҗетте минем ачы сүзләремме?
Мин уйлаучан, шулай бик күп төннәр буе
Газаплый мине, буй кыз, тәмуг уе;
Ә шунда, үч иткәндәй, чүмеч кагып,
Өй алдымнан җырлап үтә шайтан туе;
Уйларымны бүлдерәләр. Мин сине дә
Шуларның берсе диеп белгән идем.
Әмма синдә кайгы күрәм: син елыйсың.
Әй гафиф кыз! Нигә миңа килгән идең?
Кайгың булса, күз яшьләрем белән юып,
Югалтырга тырышырмын күкрәгеңнән.
Чәчләреңнән сөя-сөя юатырмын,
Ач йөзеңне, зифа буй кыз! Качма миннән! –
Дим дә мин тезләнәм.
Ул, тиз-тиз генә
Килеп, минем кулларымнан кысып ала:
– Абыем! – ди.– Синең зәңгәр күзләреңдә
Әле һаман шул ук шәфкать уты яна,
«Күзең ач!» – ди миңа амиранә.
– Тәрәзәңнән күрәсеңме: еракта әнә
Ачлык патша,
Җансыз ирләр;
Минем дә, – ди, –
Җанымны ул тартып алды хаинанә;
Таныймсың, – ди, – мине менә? –
Кинәт
Йөзеннән ак пәрдәсен ертып ала...
– Фәйрүзәм?!
Ул, кулын җәеп күкрәгемә,
Шыр сөяктән үле гәүдә, сынын сала.
Күкрәгемә кысам аның гәүдәсен... Чү!
Сөякләре кулларымнан коелып китә.
Фәйрүзәм!.. Фәйрүзәм!..
Ул еракларидан... Әллә кайдан:

«Мин үлдем бит, мин үлдем...» –
Дип тәкрар итә.
......................

**III**

Мин бишектә уяу ятам. Әнкәм минем
Ашгып-ашгып көйли миңа бәллү көен;
Әнә анда, тәсбих тартып, карт әбиләр
Сырып алган әткәемнең тирә-юнен.
Йоклый җаным-әткәм... Мин дә күзем йомам;
Еламыйм, дим, тынычсызлап, тынган булам,
Ләкин һаман йоклый алмыйм. Гүя минем
Баш астымда йоклап ята кара елан.
Сикреп торам: әнә анда әткәемә
Карт әбиләр ап-ак бүздән күлмәк тегә;
Әткәемнең йөзен ачып, тагын ябып,
Тагын ачып, нидер эшли әнкәем дә.
Менә мулла, тагын кемнәрдер керәләр;
Карт әбиләр аларга юл бирәләр;
Догалыклар укый-укый, әллә кемнәр
Әткәемә ап-ак күлмәк кидерәләр.
Кидерәләр,
Җөйлиләр.
Шуннан –
Нәрсә ишетәм?
Әткәй, әткәй, сине үлгән диләр...

**IV**

Төн җилләре, ерак илдә йоклап яткан
Фәйрүзәмнең чәчләреннән сөегез дә,
Абыең бүген өзлеп елый, диегез дә...

**V**

Кулларымны болгый-болгый, бүлмәм буйлап
Ашгып-ашгып йөрим, белмим, нидер уйлап:
Ачлык патша сизгән минем уйларымны,
Әнә килгән, тәрәзәмнән карый туктап.
Кем ул аның күкрәгендә? Бер яшь бала.
Ул яшь бала тәрәзәдән күзен сала:
– Абыем! – ди. – Мине коткар, мин үләм, – ди.
Үзе суза ике кулын миңа таба.
– Ачлык патша! Хаин патша! Ник урладың
Минем сөйгән энемне син?..
Ул югала...
Ташланам мин тәрәзәгә. Тәрәзә уала,
Хыялда коточкыч бер шәүлә кала...

**VI**

Әнә тагын... Тагын ишек ачылып,
Берәү... икәү... Күләгәләр керә качынып.
Керәләр дә алар мине сырып ала,
Берсе килеп иңнәремә кулын сала.
Сала да,
Канлы яшен сөртә-сөртә:

– Оныттың, – ди, – безне син!
Әй бала... бала...

**VII**

Бирегез ат миңа! Кем, әй?! Мин атланыйм!
Могҗиз көчләр бармы? Бирегез, канатланыйм!
Ташлап фахиш, сатлык илен, канга баткан,
Каберлеккә әйләнгән үз илемә барыйм.

**VIII**

Уйганам мин... Кинәт таң алдында
Сөякләрдән сарай тора күз алдымда.
Сарае зур, нәкышләнгән, энҗеләнгән;
Кискен нурлар сибелеп тора энҗеләрдән.
Кемнәр монда? Берәү дарга менеп баскан,
Җепкә тезеп, күкрәгенә күзләр аскан.
Кем ул? – Кара көч?
Чү!.. Әмер бирә –
Ауру ирләр тыңлап ята тирә-яктан.
Ә сарайның тыш ягында бертуктаусыз
Әллә кемнәр әрле-бирле йөренәләр.
Йөренәләр... Туктыйлар да илерәләр.
Шуннан ап-ак кәфеннәргә төренәләр...
Кемнәр алар?

**IX**

– Тукта? Кем син? Синең кулда кискен хәнҗәр?
– Ташла!
– Бу ни бу?
– Ата... Ата...
– Син ни эшләдең, син ни эшләдең?
– Тик торасың?
– Бу кем, бу кем, канга батып, җирдә ята?!

## НӘЛӘТ

Пролог

Күк читендә канлы пәрдә.
Әллә кемнәр:
– Таң, – диләр,
– Таң түгел ул, җиргә төшкән
Шомлы каргыш, кан, – диләр.

**I**

Бер әмер – шуннан тәмуглар
Сакчысы тиз-тиз генә
Килде дә ут ташлады
Илнең сарае өстенә.
Ташлады, ах! Мең нәләт!
Чү! Кемнәр анда көлделәр?
Мәсхәрәләп илне, көлде
Канлы уклар, сөңгеләр...
Юлбарысларга атланып,
Алтын сарайның уллары
Килделәр дә ил сараена
Тагын да керделәр...

## II

Качты илдән бар-бөтен рухлар,
Мәләкләр, куркынып,
Качты йолдызлар еракка,
Вәхшиләрдән хурсынып...
Калды тик ил ут эчендә,
Тәкъдиренә буйсынып...

## III

Кит, болыт! Ай, син нурың,
Күргәз тагын –
Нинди золмәт, вәхшәт алды
Ил багын...
Алда, артта шаулый туплар,
Уйный уклар шәүләсе.
Баскан эз – гүрлек-каберлек,
Канлы илнең гәүдәсе...
Канлы куллар, ыржаеп, ил
Бәхтенә сузылып тора,
Әллә кемнәр бик еракта:
«Инсаниятькә, туганлыкка үлем!» –
Дип кычкыра...

## IV

Кит, кояш! Чыкма
Бүген син дөньяга –
Куркынырсың... Куркыныч, ах, дөньяда!
Тау башында күп халык һәм канлы дар.
Нинди корбан? Кемне китергән алар?
Кем елый?.. Кем яшь түгә? Кем?..
– Эшче ул...
Сүн, кояш! Сүн, –
Сүн дә син бер шәүлә бул,
Шәүлә бул да бар, көйлә шәфкать көен.
Бар аларга:
– Җирдә шәфкать бар, – диең.

## V

Күкнең уртасында нурлы ай тора,
Ай тулы... Бар җирне нурлый, яктыра.
Төшми җиргә шәүләсе. Җир болгана.
Болганып, канлы төтеннәргә яна,
Ай түрендә кайгылы Гайса нәби
Утыра, канлы йөзе, ул уйлана...
Тек күзеңне җиргә, Гайса, күр әнә!
Син сөйгән эшче халык утта яна...
Текмә, тукта!..

## VI

Кайда сез, әй, илне
Саклаучы баһадирлар? Нигә
Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы бәйгегә?!
Әллә сезне тар, кысынкы
Төрмәләр үтердеме?!

Йә зобанилар, тәмуглардан җыеп,
Өстегезгә ач үлем,
Чума мурын китердеме?!
Эчтегезме сез зәкъкум?!
...Нигә сез эндәшмисез?

**VII**

Кайда сез, әй, илне
Саклаучы баһадирлар? Нигә
Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы бәйгегә?!
Әллә сезнең үз кулыгыз берлә
Койган сөңгеләр,
Чәнчелеп саф бәгърегезгә,
Вәхшианә көлделәр?!
Әллә сезне җир йөзеннән
Мәңгелеккә сөрделәр?!
Сез сөеп үстергән атлар,
Аргамаклар да бүген
Вәхшиләрне өстегезгә
Атландырып китерделәрме
Алар?!
– Әйе, хыянәт иттеләр...
Мең нәләт!

**VIII**

Кайда сез, әй, йортны
Саклаучы баһадирлар? Нигә
Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы бәйгегә?!

**IX**

Чыктылар... Тик соң иде,
Һәм зур сарай янган иде,
Ил сараеннан фәкать көлләр генә
Калган иде...
Инде илнең кырларында
Канга баткан каргалар,
«Кар!» диләр дә каргыйлар
Үлгән сөякләрне алар...

**X**

Бер баһадир чыкты мәйданга –
Кылычын ташлады,
Кайгылы илдә торырга
Йорт корырга башлады...
Тик аның йорт нигезенә
Куйган авыр зур ташлары
Булды гәүдә һәм батырларның
Киселгән башлары...

**XI**

– Ха-ха-ха-ха...
Көлмә анда, әй, кара көч,
Ул төзер бер зур сарай,

Үч итеп сезгә, куяр ул
Нәкъ түренә канлы ай...
Ул сарайда мәңге шатлык
Һәм ирек шаһлык сөрер;
Ул сарайда хөр йөрәк,
Көчле, батыр ирләр торыр.
Ул сарай мәңге булыр киң, –
Хөр күңелләр кәгъбәсе,
Һәм дә анда мәңге кайнар
Үч алу, кан шәүләсе...
..............

## XII

Мин караңгы сахраларда
Канлы күз яшьләр җыям,
Ил каны һәм күз яшеннән
Зур, бөек һәйкәл коям...
Туктагыз! Мин һәйкәлемнең
Кайгылы йөзен уям.
Маңгаена канлы яшьләрдән
Янар күзләр куям...
Күкрәгенә мин хаиннәрнең
Фахиш исемен язып
Җырларым.
Таушым минем
Бар җир-зәминнәрне ашар,
Дәһшәтеннән тәңреләр,
Гыйфрит, пәри-җеннәр
Шашар.

## XIII

Мин, җыеп бар зар-фиганны,
Моңлы кылларга салып,
Рух сараеннан сәмави
Сихри бер сорнай алып
Җырларым, –
Һәм җырларымны көйләр илләр
Та әбәд,
Яудырырлар ул хыянәтче
Хаиннәр исменә
Мең нәләт!

## XIV

Яшь балаларын аналар
Сөт имезгәндә һаман,
Күз тегәр каргыш белән
Алтын сарайларга табан...

## УРМАН КЫЗЫ

Кем ул анда, кара шәлен ябынган да,
Гөлдән үреп, муенсалар тагынган да,
Күбәләктәй, гөлдән гөлгә күчеп йөри
Шаулап торган кырыйсыз киң карурманда?
– Әминәм! – Ул туктый, тагын атлый,
Бөглеп-бөглеп, гөлләр өзә ул,
Тирә-ягы гаднән – гөл диңгезе.
Шул диңгездә уйный, йөзә ул.
Кемгә өздең, сеңлем, ул гөлләрне?

### I

Син уйныйсың, ә мин шундый ардым;
Өзлеп-өзлеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син – бер хәят үзең
Уйнап йөргән илдә, яланда.
Толымнарың белән җилләр уйный,
Уңга-сулга ташлый туздырып,
Алар – бәхетлеләр...
Соң мин, соң мин нигә,
Төннәр буе шунда утырып,
Кул сузарга куркам?!

### II

Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне!
Алар тузлып төшсен алдыңа, –
Шулай килешә сиңа. Су кызыдай
Кил дә хәзер минем алдыма,
Төпсез күзләреңне айга тегәп
Утыр; күлдә шәүләң уйнасын,
Узган-барган кешеләр, туктап карап,
Су кызы дип сине уйласын!
Ах, Әминәм! Булмадың ник бер су кызы,
Иркенлектә уйнап йөрүче?
Ник булмадым мин бер урман углы,
Синең дустың – яшь бер көтүче?
Кыймас иде безгә мәкер күзләр
Болай шөбһә белән карарга.

### III

Һейне җан сөйгәне Матильданың
Һаман шулай чәчен тараткан;
Син белмисең, ах, ул Матильданы
Ничек өзлеп сөйгән, яраткан!
Үлгән чакта Һейне, Матильдасы
Төпсез күзе белән һаман да
Карап торган; үлгәч, яшрен генә
Чыгып киткән шунда яланга.
Бик күп еллар үткән, шул яланда
Ялгыз гына гомер уздырган;
Өзлеп сагынганда Һенрихын, ул
Толымнарын һаман туздырган...

### IV

Син уйныйсың?! Ә мин шундый ардым;
Өзлеп-өзлеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син – бер хәят үзең

Уйнап йөргән илдә, яланда...
«Яшь шагыйрьне сөйгән Матильдадай,
Мин дә чәчләремне таратам;
Кил, син ардың, дустым! Мин бит сине
Өзлеп-өзлеп сөям, яратам!»
– Ник димисең шулай?
Сорасам да:
«Син бит абыем минем!» – диярсең,
Ике кулың белән йөзең каплап,
Башың түбән табан иярсең.
Толымнарың белән җилләр уйный,
Уңга-сулга ташлый туздырып;
Алар – бәхетлеләр...

**V**

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?!
Кайчак, күзләреңнән көчләр алып,
Биеклеккә табан ашам мин,
Ә кайчакта башым түбән иям,
Әй Әминәм, синнән качам мин.
Син кем, белмим, синең шаян күзләр
Нигә, белмим, болай багалар;
Нинди көчләр, сөйлә, әй аппагым,
Керфек очларыңнан агалар?!
Син ал инде, ал ул күзләреңне,
Алар шундый, шундый караңгы...
Үле тынлык анда, саф мәхәббәт
Исреп йоклый әле...

**VI**

Таң алды...
Син кер инде! Тиздән кояш чыгар,
Кер, Әминәм, йокың калмасын!
Мин дә шунда, дустым, ялгыз калып,
Мактый-мактый ак таң Алласын,
Соң мәртәбә чиртеп сорнаемның
Өзгәләнгән сихри кылларын,
Таңның салкын, йомшак җилләренә
Күзләреңне мактап җырларым.
Алар акрын гына тәкрар итәр,
Илдән илгә күчеп җырларлар.
Таңда су алганда, яшь киленнәр,
Туктап, таң җилләрен тыңларлар.
Син кер инде, тиздән кояш чыгар,
Әнә томан басты болынны;
Уйганырлар инде кош-кортлар да,
Бир, акыллым, сеңлем, кулыңны!

**VII**

Күл янында утрып, җырлар язам,
Әй таң җиле, тукта, исмәче!
Йоклап яткан таллар, тирәкләрнең
Яфракларын уйнап ишмәче!
Нindидер ят өннәр күкрәгемдә

Иштелә дә тагын тын кала;
Эзлим ул өннәрне, тапмыйм... Кинәт
Тагын бәгърем таша, ут ала.
Туктагыз! Мин җырлыйм:
– Шул урманда
Үскән фәрештәдәй кыз бала,
Җирдә түгел, күктә, гарештә дә
Булмаган бер генә тиң аңа.
Урман биргән аңа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр,
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә,
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр,
Таң җилләре аның, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган,
Төн ае, төннәрдә йокламыйча,
Ана булып күктән караган.
Карурманның барлык матурлыгы,
Бар серләре анда җыелган;
Зифа буе булган ак мәрмәрдән,
Күзе сихри нурдан коелган.
Көннәр үткән шулай,
Ул зур үскән.
Менә беркөн матур ак таңда
Кара шәлен ябнып чыгып киткән –
Йөрер өчен кара урманда.
Очраткан ул шунда, күл янында,
Абынып-йоклап яткан берәүне;
Уяткан ул аны –
Ул бер юлчы булган.

**VIII**

Әй таң кызы! Сиңа талган юлчың
Таңда искән йомшак җил белән
Сәламнәр җибәрә. Иртә белән
Син килерсең шунда, бик беләм,
Тик мин булмам,
Сеңлем, әй Әминәм!
...................
Соңгы ядкяр итеп, күл янына
Гөлләр өзеп куям бер күләм.
Аны сөйгән гөл-чәчәкләр! Ул килгәндә,
Тәгъзим итеп башыгыз иярсез,
«Сине өзлеп сөйгән юлчы абыең
Еракларга китте», – диярсез.

**IX**

Тирән сахра – минем барыр юллар,
Күчалмаслык ерак, караңгы...
Беләм, анда мине кара көннәр,
Ул килер дип, анда караулый,
Беләм, мине көткән кайгы-хәсрәт
Тау-тау булып анда өелгән;
Беләм, шул тауларның асларында
Мин эзләгән җәүһәр күмелгән.

## ЭШЛИЛӘР

### I

Алар эшли, күптән эшли инде
Тимер куллы даһи эшчеләр;
Айлар, еллар үтә, – һаман шунда
«Даң! доң! Даң! доң!..»
Нидер эшлиләр.

### II

– Табигать! Кит минем юлларымнан!
Ташла сангать коралларың кулларыңнан!
Менә санигъ сиңа! Юл бир миңа!
Төзим җәннәт ташландык ил, кырларыңнан!
Шулай ди ул, мәгърур бер яшь эшче,
Киң сахрада җәннәт төзә ул;
Тирә-ягы гаднән – гөл диңгезе.
Шул диңгездә эшли-йөзә ул.

### III

Төн уртасы... Эшче уйлап ята
Җир өстендә җәннәт төзәргә,
Көчле кулы белән табигатьнең
Барлык богауларын өзәргә...
Табигать тә, аңа баш игәндәй,
Төн карасын вата, тарата.
Нурлар түгеп шунда, көлә-көлә,
Күк читендә ашгып таң ата.

### IV

Алар эшли, күптән эшли инде
Тимер куллы даһи эшчеләр.
Айлар, еллар үтә, – һаман шунда
«Даң! доң! Даң! доң!» нидер эшлиләр.
    Менә рәссам ашгып дивар бизи,
    Шагыйрь җырлый, тәмам тилергән;
    Әнә эшче, батыр үгез кебек,
    Нидер бөгеп ята тимердән!

### V

    «Яңа җәннәт җирдә төзелде!» – дип,
    Җибрил күккә хәбәр китерде.
    Мәгърур патша – көчле күк Алласы
    Әүвәл көлде,
    Шуннан –
    Тилерде...

## БАКЧАЧЫЛАР

### I

Тынлык... Шундый авыр тынлык...
Гүрләр өелеп ята тирәмдә;
Үләннәре сары, кояш күрми,
Кара гөлләр үскән чирәмдә
Тик утырам.
Кайгы шәлен ябынып, әй, кем,
Нигә һәр көн киләсең?
Киләсең дә
Төпсез күзләреңне
Еракларга табан тегәсең.
Ни көтәсең аннан?
Син җавапсыз?
Сары гөлләр синең кулыңда,
Үлем йоклап ята юлыңда.
Мин, гыйсъянчы, менә уңыңда
Карап торам.
Тынлык.
Әбәд үзенең тирән серен саклый:
Кемнәр килер аннан – билгесез;
Әйе, аннан кемнәр килер, белмим.
Әмма монда шундый авыр,
Шундый күңелсез...
Сүнгән күзле минем төнге дустым,
Әйт син миңа, җырлый беләмсең?
Җырлыйсы иде, шашып җырлыйсы иде,
Юкса нинди хәсрәт, күрәмсең?
Әйе, кара төндә ерак зур урманда
Син җырладың,
Ялгыз җырладың,
Мин ишеттем;
Ләкин кайгылы иде,
Сагышлы иде синең җырларың.
Тукта! Мин дә җырлыйм:
«Бу төн мәңге булмас;
Кояш чыгар, дөнья ямьләнер,
Сары каберлекләр яшелләнер,
Кара гөлләр утка әйләнер;
Әйләнер дә –
Килер бакчачылар,
Каберләрне ватар, сүтәрләр,
Гүрләр өстен бизәп гөлләр белән,
Иляһи бер бакча итәрләр.
Шуннан
Алар, көчле бакчачылар,
Шундый-шундый бер көй җырларлар,
Бар үлекләр, чыгып каберләрдән,
Таңга калып көйне тыңларлар».
Син дә, дустым, җырла, ләкин хәят җырын!
Син ул җырны җырлый беләмсең?
Яки бер көл, шундый матур итеп!
Йә, көл инде!
Көләмсең?

### II

Бакчачылар!
Нигә соңладыгыз?

Юлыгызны җеннәр кистеме?
Яки өстегездән җәһәннәмнән
Чыккан сәмум җиле истеме?
Истеме?..
Бик күп инде, бик күп юлаучылар
Бу җирләргә килеп киттеләр;
Алар:
«Аннан, безнең арттан
Бакчачылар килә!» –
Диеп хәбәр иттеләр.
Бакчачылар!
Нигә соңладыгыз?
Юлыгызны җеннәр кистеме?
Яки өстегездән ком бураны,
Көчле сәмум җиле истеме?
Истеме?..
Айлар, еллар үтә. Һаман әле
Гүрләр уелып ята тирәмдә.
Үләннәре сары. Кояш күрми,
Кара гөлләр үскән чирәмдә
Мин утырам.

## *1923*

### МӘҢГЕЛЕК ӘКИЯТ

Әкият сөйлим сезгә, таң җилләре!
Туктагыз да минә тыңлагыз!
Шул урманда булган бер әкиятне
Илдән илгә күчеп җырлагыз!
Менә урман, чиксез кара урман,
Мәңге шомлы, мәңге караңгы;
Җилләр белән ишелеп, һаман, һаман
Улап торган үткән заманны.
Шул урманда яшрен бер урында
Ялгыз кабер тора. Кем анда?
Нигә ялгыз анда адашкан да
Нигә яшрен җирдә урманда?
Ул – бер егет кабре.
Ул егетнең
Кайгы белән үткән көннәре,
Озын булган мәңге газап белән
Йоклый алмый үткән төннәре.
Ул күп, бик күп уйлап йөргән:
«Адәм кайдан килгән, тагын да
Кайда китәр?» Ләкин моңа җавап
Табалмаган үзенең аңында.
Табалмагач, килеп тезләнгән дә
Мәңгелектән җавап сораган.
Озак көткән –
Җавап алалмагач,
Болай диеп егет җырлаган:
«Нәләт төшсен сезгә, нәләт төшсен!
Әй, урманнар, кырлар, далалар!
Мәңге телсез каты ташка әйләнгән
Җирләр, күкләр, фәннәр, аллалар!
Җавап көттем сездән, бирмәдегез,
Инде эзләп китәм – табармын;
Көчле кулым белән мәңгелекнең
Тимер ишекләрен ватармын.
Ватармын да илгә яшрен булган
Барлык серне чишәр, ачармын».
Шуннан соң ул, яшрен урын сайлап,
Кабер казып, җиргә күмелгән;
Мескен егет, кайтам, диеп киткән,
Кайтмас җирдән – упкын төбеннән...
Мин әле дә аның кабрен эзлим
Урманнардан, яшрен җирләрдән,
Мин тавышын ишетәм, һәр көн иштәм
Таң алдында искән җилләрдән.
Ул киләчәк...
Мин дә кабрен, табып,
Гөлне үпкән кебек үбәрмен,
Зәңгәр күзләремнән, аямыйча,
Кайнар яшьләремне түгәрмен.

Зәңгәр күзле егет кабрең үбәр,
Яшьләр түгәр кабрең өстенә!
Гөлләр сибәр һәр көн таң алдында,
Җырлар җырлар синең исмеңә.

Син эзләгән яшрен, зур серләрне
Мин дә эзлим, егет, –
Тыныч бул!
Син күзләгән төпсез упкыннарны
Мин дә күзлим, егет, –
Тыныч бул!

## УРАМДА

### I

Ишек шакыйм. Тыңлыйм – бер тавыш юк.
Тагын шакыйм, тагын... Тагын да...
Төн уртасы. Шундый, шундый шомлы.
Берәү дә юк тирә-ягымда...
Куркам, әнкәй! Куркам, ач ишегең!
Мин бит бала сезгә! Курыкмагыз!
Җаным туңа минем төн салкыннан,
Җилләр, каһәр төшкән җилләр, туктагыз!

### II

Ишек шакыйм. Тыңлыйм, бер тавыш юк.
Тагын шакыйм, әллә шашаммы?!
– Әнкәй!
Ник ачмыйсың?!
Әнкәй!
Ник дәшмисең?!
Ник ачмыйсың да ник кертмисең
Төн салкыннан туңган балаңны?!
Олактырып мине чит илләрдә,
Ялгызымны ташлап киттегез.
Мин каргамыйм сезне, барсын кичәм,
Тик, әнкәем-бәгърем, тагын кире
Кумагыз сез мине, кертегез!
Тәрәзәне ватып, өйгә керәм,
Нәрсә күрәм? Әллә шашаммы?!
Берәү дә юк...
Ә мин үз илемнән
Эзләп кайттым атам, анамны.

### III

Мин тик йөрим хәзер урамнарда.
Әнием үлгән... Юлчы! Иштәмсең?!
Минем өзлеп сөйгән әнием үлгән.
Тәкъдир шулай, дустым! Нишләрсең?!
Каһәр төшкән юлчы! Синең йөздә
Ниндидер бер яшрен сер күрәм,
Син түгелме әнкәемне үтерүче?
  Ах! Юк, кичер! Әйт, тик төн белән
  Шул сахрадан үткән чакта,
  Канга баткан, качып ашгып барган берәүне
  Очраттыңмы, әйе, очраттыңмы?..

### IV

Мин тик йөрим хәзер урамнарда.
Угры диеп, этләр, өрмәгез!
Мин – гакыллы бала. Узгынчылар, узгынчылар,
Шашкан бала бу дип белмәгез!
Минем әнием матур иде, үз кул көче
Белән эшләп гомер итүче;
Әткәем дә, бәлки, беләсездер –
Гыйльман бабай – карт бер көтүче.
Ә хәзердә алар юк бит инде...
Мин тик йөрим хәзер урамнарда,

Кышкы төндә, салкын буранда.
Җаным туңа, дер-дер калтырыйм мин,
Өем юк шул минем кунарга.

## ГЫЙСЪЯН

Бар да исрек, бармы бер аек сорарга?
Әйтегез!
Кем кабакның патшасы?!
Йә, кайсыгыз
Бу фахиш йортны төзегән?!

### I

Йорт караңгы, бар да исрек,
Зур кабак дөньясының
Мәйданында – муллалар, поплар,
Түрендә – зур санәм.
Тантана, мәҗлес кабакта.
Тук аюлардай булып
Джентльменнар, мадмуазельләр
Гөр килеп, җырлап, дулап,
Зур кабакның уртасында
Туйлыйлар...
Ул философлар,
Әдипләр
Ниндидер сер уйлыйлар,
Уйлыйлар.
У-у-у...
«Дин» диләр,
«Әхлак» диләр,
«Сәнгать» диләр –
Саф гакылларны агулап,
Зур хыянәткә, һәлакәткә
Халыкны димлиләр.

### II

Кайгылы гыйсъянчы мин,
Мең кат аларның йортына
Ут җибәрдем, ут җибәрдем, –
Зур кара йорт янмады.
Ах! Минем тик бер генә ут та
Янып кала алмады.
Сизде тиз мәлгунь – кара йортның
Убырлы сакчысы.
Сүнде ут, илгә күренми
Утларымның яктысы...

### III

Йорт караңгы, бар да исрек;
Зур кабак дөньясының
Мәйданында – патшалар, лордлар,
Түрендә – зур санәм,
Зур санәм... Ул аузын ачкан...
Канлы бәйрәм...
Шау-шулар...
Тантана...
Төн...
Зур санәмнең аузына
Ниндидер ят кап-кара җаннарны
Ыргый, ташлыйлар...
Ташлыйлар, ул зур санәмнән

Мәңгелек бәйрәм теләп.
Мәңгелек бәйрәм...
Сәгадәт...

### IV

Кимсетелгән ул кара халыкның
Явыз гыйсъянчысы –
Мин киләм...
Әй, төнге албасты,
Убырлар сакчысы!
Иштәсеңме?
Мин киләм!
Мин киләм шул йортка, кайда
Зур сәгадәтләр өчен
Корбан иттеләр илемне.
Әйе, аларның зур үчен
Мин киләм алмак өчен.

### V

Кычкырам. А... Ишетәсезме?
Әй, тиленләр, мин менә
Куркыныч утлар ягып
Чыктым тагын җир өстенә.
Шыңшый-шыңшый, гүрләр өстендә
Иман-Коръән укып,
Илнең исрек гәүдәсеннән
Калҗа-калҗа ит чукып,
Шакшы исләрдән исергән,
Әй, үләксә кортлары!
Мин менә чыктым ягып
Җиргә җәһәннәм утлары!
Мин бүген Коръәнне утка яктым
Иртә таң белән –
Тәүратыңны, Инҗилеңне[2],
Әй, гарепнең поплары!
Мәңгегә себерепп түгәм
Һәм –
Тез чүгәм:
Ул килә – шәп атка атланган гасыр,
Әйе, беләм,
Ул килә.
А... ни оят! А... ни оят
Каршыларга ул гасырны
Мулла, поп исме белән!

### VI

Гыйсъян итеп сезгә каршы,
Сорыкортлар, мин менә
Куркыныч утлар ягып
Чыктым янар тау өстенә.
Аллагызны,
Дөньягызны
Утка ташлыйм, яндырам,

Җирдә тик эшне Иляһ дип калдырам.
Иштәсезме?!
Әй, тилеләр!
Нинди шау-шу иштелә?
Ул килә –
Капланга атланган гасыр.
Зур чор килә –
Дәһшәтеннән бар хорафат селкенә.
Ул килә – корыч гасыр,
А... ни оят,
Каршыларга ул гасырны
Шул килеш – исрек көйгә!

## САГЫНУ

*(«Зәңгәр күзләр» шигыреннән бер ләүхә)*

Мин сагынам өзелеп яшь чагымны...
Тик ул чаклар минем хәтердә
Бик томанлы, бик томанлы булып калган.
Менә хәзер дә
Бик еракта, гүя бик еракта
Серле җәннәт булып күренә:
Серле җәннәт... Зәңгәр утлар янган.
Бишек элгән җәннәт түренә.
Мин тирбәләм шунда:
«Тирбәт, әнкәй, минем бишегемне!
Очындыр бер тагын һавага!..»
Шундый рәхәт миңа, шундый рәхәт.
Уйный-уйный иркен һавада,
Мин тирбәләм:
«Тирбәт, апай, минем бишегемне!
Уйнат мине, назла, иркәлә;
Йокла, диген, шаян уйнар өчен
Уйганырсың тагын иртәгә!»
Бирегез миңа, бирегез зәңгәр күзле яшь чагымны.
............................
Ах, ул чаклар, шундый ерак калып,
Күм-күк томаннарга төренгән,
Төштә күргән пәри сараедай,
Күрнеп тора күм-күк сөремнән.
Менә мин, бер зәңгәр күзле ят-яшь бала,
Тәпи йөреп чыгам урамга,
Кулымдагы нечкә чыбык белән
Казлар куган булам урамда.
Бәбкәләрен саклап, ак ана каз
Миңа таба килә, җилкенә;
Күп тә үтми, аунап җир өстенә,
Калам усал казның иркенә...
Бирегез миңа, бирегез зәңгәр күзле яшь чагымны!
Ах! Сез бирмисез?!
Сез явызлар!.. Сез... Сез... Сез явызлар!
Минем хәсрәтемне күрмисез!..

## ЗӘҢГӘР КҮЗЛӘР

*(«Зәңгәр күзләр» шигыреннән бер кисәк)*

**I**

Бүген таң алдында торып сәлам сөйлим.
Кемгә?
– Белмим.
Бүген таң алдыннан торып сәлам сөйлим.
Кемгә?
– Белмим.
Илчем – җил аркылы сәлам сөйлим
Сезгә:
Чәчәкләргә, гөлләргә,
Нәфис лаләләргә, сөмбелләргә,
Сахраларга, барлык җирләргә!

**II**

Зур бакчамны нәфис итеп
Бизәдем дә
Матур иттем мин;
Йоклап яткан назлы гөлләремне
Уяттым да
Сулар сиптем мин.
Зур-зур утлар яктым бөтен җиргә,
Утлар яктым бөтен җиргә мин.
Бөтен дөнья йоклый, тәмле йоклый,
Тик йокысыз икәү –
Җил дә мин.

**III**

Әй, сез! Кунак булып җиргә килгән
Юлаучылар, талган юлчылар!
Әй, сез, кемнәр, белмим,
Гыйсъянчылар!
Юлбасарлар!
Коллар!
Ялчылар!
Кем булсагыз да сез, аермасыз,
Килегез миңа бүген кунакка!
Үткәрерсез иркен көнегезне
Гөлбакчамда бүген кунакта.

*

Зәңгәр күзле егет кунак итеп
Сезне чакыра.
Әй, сез!
Ишетәмсез?!
Зәңгәр күзле егет ял итәргә
Сезне чакыра.
Әй, сез!
Киләмсез?!

Без бу җирдә сирень гөлләреннән
Матур итеп таҗлар үрербез.
Кайгы-хәсрәтләрне онытып, без
Балалардай уйнап йөрербез.
Кызык булыр,
Биредә безгә карап
Көлүчеләр дә юк, кем дә юк.
Акыллылар да юк, Алла да юк,
Патша да юк монда, җен дә юк.
Килегез сез!
Мин дә, зурлап сезне,

«Зәңгәр күзләр» көен көйләрмен.
Күкрәгемдә бик күп еллар яшереп йөргән
Бер серемне сезгә сөйләрмен.

**IV**

Тыңлагызчы!
Матур бер көн иде –
Үз илемдә, ерак-еракта:
Мин килә идем җырлап урман буйлап
Иярләнгән матур туры атта.
Хәтерлимен, әле бик яшь идем,
Күзләрем дә минем ул чакта
Тагын зәңгәр, тагын уйнак иде...
Шулай килгән чакта, еракта
Җыр ишеттем.
Миңа, күп тә үтми,
Очрадылар урман кызлары;
Алар шундый шатлар иде,
Нәфис гөлдәй
Елмая иде нурлы йөзләре.
Мин туктадым, алар арасында
Танып зәңгәр күзле берәүне.
– Кем иде ул, кем иде ул? – дисез,
Шулаймы?
Сез сорыйсыз? Ә мин сөйли алмыйм.
Ах, ул серләр шундый караңгы...
Сөйли алмыйм, мине кичерегез!
Ача алмыйм йөрәк ярамны.
Ул карады миңа бары бер генә кат,
Шуннан
Башын бөкте, бакмады;
Мин карадым, ә ул йөзкәйләрен
Ябынчасы белән каплады.
Ник каплады?
Көлеп, оялыпмы?
Мин белмәдем.
– Ник капладың зәңгәр күзкәйләрең?
Ник елмаеп миңа көлмәдең?!
Көлмәдең дә нигә:
– Оялтасың,
Болай бакма, егет, – димәдең?!

**V**

Мин сагынам,
Өзлеп сагнам аны,
Тик ул инде минем хәтердә
Бик томанлы, бик томанлы булып калган.
Менә хәзер дә
Бик еракта, гүя бик еракта
Сихерле сын булып күренә.
Сихерле сын... тирә-ягы – чиксез урман...
Төренеп ул сирень гөленә,
Туктап карап тора.
Гүя үзе кешелекнең җанлы сыны кебек,
Күзләрен мәңгелеккә табан тегеп,
Туктап карап тора...

**VI**

Аның исемен җырлап, таҗлар үрдем,
Берсен кидем, берсе – кулымда,
Таң сызылган минем уңымда,
Гөлләр йоклап ята юлымда;
Гөл патшасы – мин бер ялгыз шунда,
Тәкрар әйтәм:
– Ул кыз хәзер юк шул, юк монда...

## ПАСХА ЧАҢНАРЫ

Шырпы алдым да кулыма, тын гына
Мин юнәлдем бәдбәхетләр йортына.
Күптән инде ниндидер мәҗнүн менә,
Атланып бер таш манара өстенә,
Чаң суга.

Әй, хорафат, искелекнең сакчысы!
Туктыйсыңмы?
Юкса бит, – килдем менә, –
Ут җибәрәм чиркәвеңнең өстенә!
Бар канун, диннән азат күңлем минем,
Иштәсеңме?
Мин үзем Тәңре!
Табынсын җир-күгең.
Соң шулай булгач,
Нигә:
Аллаң,
Динең,
Җәннәтең, Гайсаң, Мөхәммәтең синең!
Сукма, әй, мәҗнүн, хорафат чаңнарын,
Кимсетеп фән һәм азатлык таңнарын.
Ял итә эштән арып кайткан халык, –
Күрмисеңме? –
Тәмле йокыга талып.

Әй, тиле, эшсез халыкның чаңчысы!
Әй, хорафат, искелекнең сакчысы!
Туктыйсыңмы?
Туктамыйсың?
Ә, алаймы?!
Алайса, күр менә:
Ут җибәрдем чиркәвеңнең өстенә!
Әйдә гыйсъянчы тәмугында бүген
Мунча чабынсын Ходай,
Гайсаң синең!

**ТИЛЕЛӘР**

Шыр тиеләр
Бер көтү килгән миңа.
Бер-берләрен
Төртешеп, шырлап көләләр дә,
Чыгарып телләрен:
– Бу, – диләр, – шашкан, юләр,
Каткан киемнәр өстенә
Сипте күңеленнән бәһасез
Бриллиантлар, энҗеләр...

Мин тиеләр дөньясында
Бер тиле төсле торам.
Һәр кара төндә урамнарда йөрим
Йә тын гына,
Яшренеп, бер җен кебек,
Керәм тиеләр йортына.

Зур тәти йорт.
Мавританский ысулда заллары...
Залда
Татарның франтлары,
Түрәләре,
Тагы
Джентльмен, мадмуазельләре,
Сөрелгән ханнары...
Сәхнәдә,
Бер энҗеле башмак белән бик дуслашып,
Танцевать итә
Мөхәммәтнең тәрәт комганнары.
Кул чабалар,
«Бис-с-с-с...»
Дияләр,
Баш ияләр,
Ха-ха-ха-ха!
Туйлыйлар эш гасырының
Койрыклы пәһлеваннары...

Антракт вакыты.
Тәти зал уртасында гөрләшеп,
Ак якалар,
Пудралар
Сәнгать хакында серләшеп
Әйләнәләр.
Берсе сөйли:
– Нинди киемемне киярмен,
Әнкәем, зур бал була,
Балда гаскәри эфисәрләр,
Комиссарлар була.
Икенчесе:
– Шәп булыр, кулга төшерсәм
Мин Фатыйманы әгәр...
Шәрәф:
– Аллага мең-мең шөкер,
Гөрли хәзергә сәүдәләр...

Мин карыйм, бер җен кебек, читтән...
Кинәттән алдыма
Бер мәче килгән, мияулый,
Торгызып сырт йоннарын,

Тырный җирне, арт аягы
Берлә ташлый комнарын...
Ул мияулый,
Мин карыйм.
Ул
Шунда шаркылдап көлә
Дә коточкыч чал әби, бер
Карт убырга әүрелә.
Әүрелә дә, кул сузып:
– Кил, мин – синең җанкай, – ди
Һәм
Йөзләренә, күзләренә
Әллә ниләр сөртенә...
Мин тиеләр сахрасында
Төндә ялгыз утырам,
Вак-төяк ташлар җыеп,
Таштан биек бер сәд корам.
Шунда мин барлык тиеләрне
Җыеп япмак булам
Һәм,
Сызып шырпы, аларны
Иркәләп якмак булам.

## НОТА

Бу шигырь, ип. Воровскийны үтерү хәбәрен ишеткән төнне язылып, икенче көнне комбинат тарафыннан басылып, манифестациядә таратылып йөрелде.

Илебезне җимрер, талар өчен,
Комсыз байлар, лордлар, түрәләр
Бүген анда, канлы Европада,
Тәре үбеп антлар бирәләр.
Соң сез, мәгърур, көчле ил уллары,
Шуңа карап башыгыз иямсез?!
Мескеннәрчә тагын, оялмыйча,
Коллык богауларын киямсез?! Юк, юк!
Күкрәгендә ирек хисе булган
Һичбер кеше моңа баш имәс!
Ышанмыйбыз, юк, юк, ышанмыйбыз,
Ил уллары алай кимсенмәс!

Илебезнең иркен туфракларын
Таптатмаска антлар итәбез!
Әй сез, лордлар, ерткыч юлбасарлар!
Мәйдан ачык,
Сезне көтәбез!
Без ирекне җанлы коллык белән
Алмаштырып сайлый алмыйбыз!
Күрәсезме?! –
Сезгә нәфрәт итеп,
Көлә-көлә, кылыч сайлыйбыз!
Яки безгә үлем, яки сезгә,
Ишетегез!
Илчебезнең канын даулыйбыз!

## ЯНАР ТАУЛАР

Җир шарының мәркәзендә
Мәңгелек бер көч белән
Кайный гыйсъянчы атомнар,
Кайныйлар
Бик бөек бер үч белән.

Без,
Шул гыйсъянчы атомнардан
Җыелган яу булып,
Бер янар тау уртасыннан
Куркыныч ут тау булып
Кап-караңгы пәрдәләргә
Чормалып чыктык та бер
Җырладык
Гыйсъян җырын:
– А, атомнарны кояштан
Каплаган җир катлавы,
А, кояшны без – атомнардан
Яшергән көл тавы!
Без менә чыктык янар таулар булып,
Җирнең утлы мәркәзеннән яу булып.
Сезгә,
Безне каплаган зур пәрдәләр,
Сүнгән атомнар,
Тарихлар,
Гәүдәләр;
Сезгә,
Безнең өстебездә йөк булып
Атланып торган черек үләксәләр!..
Без – атомнар – мәңгелеккә буйсынып,
Киң фәза
Мәркәз тирәсендә һаман
Әйләнеп йөрдек кояшларга табан,
Ут теләп,
Хәят теләп.
Ә сез һаман
Капладыгыз безне гел
Аска табан...
Без менә чыктык янар таулар булып,
Җирнең утлы мәркәзеннән яу булып
Сезгә,
Безне каплаган зур пәрдәләр,
Сүнгән атомнар,
Тарихлар,
Гәүдәләр;
Сезгә,
Безнең өстебездә йөк булып
Атланып торган черек үләксәләр!..

Без караңгы пәрдәләргә чорналып,
Мәңгелек көрәш уты белән янып,
Җырлыйбыз, өске кабатларга карап,
Куркыныч гыйсъян курайлары алып:
– Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз
(Кайсылар безне үлемдәй каплаган).
Иштәсезме?!
Без яңа юл башлыйбыз
Мәңге утларга, кояшларга табан!

Искереп бетте
Тарих,
Еллар,
Гасырлар,
Дөньялар...
Искереп бетте гомер,
Барлык
Фәза,
Тормыш...
Алар
Искереп чергән диварлардай аудылар,
(Безнең өскә)
Алар капландылар...

Алар капландылар...
Канлы гыйсъян,
Соңгы гыйсъян!
Без беренче кат набат суктык,
Икенче кат набат суктык,
Өченче кат набат сугып менә,
Ташлыйбыз гыйсъян авазы
Җир шарының өстенә.

А, кояш күрми: түбәндә,
Интегеп гомер буе,
Яшренеп җир мәркәзендә,
Кайнаган гыйсъян уе.
А, җәберләнгән атомнар,
Йә, сәгать сукты менә,
Чыгыгыз җимереп коточкыч
Зур янар таулар булып
Безне кояштан яшергән
Төнге золмәт өстенә!..
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Без янып сүнгән атомнарны
Түбәндә калдырып,
Киң фәза, бушлык эчендә
Яңа йолдыз яндырып,
Яңадан
Бертуктамый, һаман, һаман
Без йөзәрбез мәңге утларга,
Кояшларга табан...

## КОЯШ КҮКТӘ ШУЛАЙ МӘҢГЕ ЙӨЗӘР

(*«Зәңгәр күзләр» шигыреннән*)

Ах, ул чаклар, шундый ерак калып,
Күм-күк томаннарга төрелгән;
Төштә күргән пәри сараедай
Күренеп тора күм-күк сөремнән.

Бакча ясыйм,
Менә карагызчы!
Бакча ясыйм нәфис гөлләрдән;
«Зәңгәр күзләр» көен көйли-көйли,
Сулар агызам тирән күлләрдән.
Айны каплап ап-ак болыт белән,
Йолдызларын сибеп күгенә,

Болыт үтә төшкән ай шәүләсен
Төшереп куям күлнең төбенә.
Тын калыгыз!
Менә кинәт кенә
Йоклап яткан күлнең төбеннән
Ашыгып бер кыз чыгар.
Сирень гөленнән
Күлмәк кигән,
Шундый, шундый матур итеп киенгән.
Алай түгел –
Пәрдә ачам,
Менә карагызчы!
...Май айлары,
Бөтен дөнья яшел киемнәргә киенгән.
Гөл түгелгән бөтен сахраларга,
Урманнарга сирень гөленнән
Исләр аңкып тора.
Алай түгел –
Менә үткәннәрнең тимер ишеген ачам,
Сез көтегез!
Аннан колынга
Атланып, бер кыз чыгар,
Аның кулында
Хәят гөле булыр.
Алай түгел –
Ничек, ничек башлыйм соң
«Зәңгәр күзләр» дигән җырымны,
Ничек кенә матур итеп сөйлим
Туып үскән урман-кырымны?
Ах, әгәр мин бер зур рәссам булсам,
Тәрсим итеп ул кыз баланы,
Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.

Җир йөзенең бөек рәссамнары!
Килегез дә миңа сөйләгез!
Аның тузган чәчен буяганда,
Нинди буяу белән буйыйм да,
Зәңгәр күзкәйләрен, җанлы итеп,
Ничек кенә буяп куйыйм да,
Ничек тәрсим итим мин аны?!

*

Иркә җир кызларын буяу белән
Җанлы итеп буяп буламы?
Булса,
Ничек буйыйм, ничек кенә буйыйм мин аны?

*

Ах, әгәр мин даһи рәссам булсам,
Тәрсим итеп ул кыз баланы,
Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.

*

Килсеннәр дә сорасыннар иде:
«Ник кайгылы болай,
Ник кайгылы болай син?» –

Диеп,
Мин дә башым җиргә табан иеп
Сөйләр идем:
– Яшьлек көннәремдә мине сөйгән,
Мин ул кызның – матур Мариянең –
Оныттым мин, мине табындырган
Күз карашын, әйе, мин аның, –
Оныттым.
Нинди кайгы!
Гомеремдә мине бер кыз сөйде,
Аның да
Күз карашын яшреп хыялымда
Җәүһәр итеп саклый алмадым.

*

Мария!
Мине синнән дин исменнән аердылар,
Тартып алдылар,
Милләтләр белән, диннәр белән
Арабызга киртә салдылар.

*

Бик күп еллар үтте...

*

Без ул диннәр, кануннарны тар-мар иттек.
Ял итәм мин хәзер киң далада,
Гыйсъянчылар белән бергә мин;
Минем белән бергә ял итәргә,
Минем дустым Мария,
Кайда син?

*

Мин ул безне аерган дингә, кануннарга
Каршы көрәшкәндә,
Атым арды, кулым талды инде,
Яраларга, канга баттым мин.
Яраларым юып юатучы
Минем дустым Мария!
Кайда син?
Хәзер инде безнең арабызда
Безне аерган һичбер дин дә юк,
Канун да юк,
Шулай ук бит, Мария!
Шулай ук бит, шулай ук бит
Җир өстендә хәзер син дә юк.

*

Кояш күктә шулай мәңге йөзәр,
Көлә-көлә йөзәр-йөзәр дә...
Бер көн килер: көчле тимер канун
Мәңгелекнең җебен өзәр дә,
Бер-берсенә бәрелеп бар йолдызлар,
Бөтен дөнья утка әйләнер,
Әйләнер дә,
Бик күп еллар үтәр,

Атомнарга атом бәйләнер.
Тагын хәят каплар күк йөзен.
Тик ул чакта, тик ул чакта безне аерган
Бу кануннар булмас, йолдызым!

**КАЗАН**

*(Бер монолог)*

Күзләремә ничек ачык итеп
Кайгы нуры төшкән!
Аларда
Үз-үземә нәфрәт хисе яна.
Оялам да,
Куркамын да хәзер карарга...
Ә кайчандыр алар көн килерен
Хәбәр иткән язгы таңдагы
Кояш нуры кебек якты иде,
Өмитле иде;
Хәзер андагы
Ул сихерле нурлар сүнгәннәр...
А, тагы
Алар шулай итеп янармы?..

Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңа
Мин, гыйсъянчы, кереп адаштым.
Череп беткән мещан баткагында
Иркен уйларымнан саташтым.
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңда
Җанга җылы юктан туңам мин,
Череп беткән мещан мунчасында
Көзге чәчәк кебек сулам мин.
Казан!
Шагыйрьләрең бардак җырлый синең,
Әдипләрең эчеп тилергән,
Нэпманнарың, чуар дуңгыз кебек,
Кеше каны эчеп симергән.
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңа
Көчле дуслар эзләп килдем мин,
Тик ялгыштым,
Синдә Дон-Кихотлар[2],
Милләтчеләр туе күрдем мин...
Киләчәктә юкса мине дәме
Шушы ваклык басар, күмәрме?
Күкрәгемдә янган җәһәннәмнәр
Шулай әкрен генә сүнәрме?
Әгәр алай булса,
Ул вакытта...
Үләргә? –
Ачу итеп тормыш чүпләренә,
Үз-үземне җиргә күмәргә? –
А, юк!
Әгәр алай итсәм, алар өчен
Бик зур корбан булыр идем мин.
Шул тормышның астын өскә китереп
Җимерергә, тар-мар итәргә!
Әйе,
Бу тормышны җимрер, ватар өчен,
Алар килә,

Ишетәм:
Яшь көчләрнең
Аяк тавышлары иштелә!

**ТАКТАШ ҮЛДЕ**

Көчле кояш күптән баткан инде,
Караңгылык баскан җир өстен, –
Ә ул һаман утын якмый, тик утыра.
Бәлки... кем белсен,
Аның көчле кулы бик күп еллар
Шулай эшли-эшли талгач та,
Күкрәгендә хәят нурларыннан
Соңгы нуры сүнеп калгач та,
Аның ирекле күңле, тынар өчен,
Караңгылык тели торгандыр?
Бәлки, шулайдыр да,
Бәлки...

Өстәлендә аның бер хат тора –
Карт анасы язган;
Хатында
Шундый юллар:
...Хәләл сөтен имезеп, төннәр буе
Йокламыйча, сине саклаган,
Авырганда, үлем кочагына
Үзен атып, сине яклаган –
Ул кем иде?
Соңгы сынык нанын сиңа биреп
Ач калса да, «балам» диюче,
Бөтен дөнья синнән качканда да,
Берьялгызы калып сөюче –
Ул кем иде?..
Син ач килеш читтә йөргән чакта,
Синең өчен
Елый-елый күзсез калучы,
Синең бәхтең өчен җир өстендә
Тәмуг газаплары алучы –
Ул кем иде?..
– Мескен әнкәң!
Ул әле дә өзлеп сагна сине,

Ә син?..

Әткәң,
Ул әле дә шулай сөренә-сөренә,
Таяк тоткан килеш, урамда
Туктап ютәлли дә:
«Мин әле дә сезнең өчен
Салкын буранда
Һаман йөрим», – ди ул.
Аның күләгәсе һаман йөри,
Һаман, һаман да.
Бер ул гына түгел,
Бире бик күп алар;
Ач, ялангач килеш яланда
Тик йөриләр...
Тик йөриләр...
«Син кайт, балам!
Син кайт безнең янга,
Әүвәлгедәй сине сөярбез,
Балам, иркәм, бәгърем, диярбез!
Син кайт, балам!»
Төн үтә дә,

Иртәнге җил аңа җавап яза:
– Улың үлде.
Сагнып хатлар язма, бәхетсез карт,
Зәңгәр күзле улың исменә;
Ул юк инде...
Сагнып хатлар көтмә, изге карчык!
Көзге төндә,
Тәрәзә төбендә.
Тәрәзәңне кагып:
– Аңардан! – дип,
Хат китермәс хәзер беркем дә...
Төштә күреп аны, уянгач та,
Рәсмен кулыңа алып син аның,
Таң җилләре аша
Елый-елый
Көтмә инде аның сәламен!
Ул юк инде,
Ата!
Синең өчен
Ул юк инде...
Ана!
Синең өчен,
Сезнең өчен үлде мәңгегә...

Иске тормыш!
Синең кырларыңда
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет –
Ул юк инде...
Иске тормыш!
Синең «гөлбакча»ңда,
Сөренә-сөренә ачтан интегеп,
Хәят эзләп йөргән уйчан егет –
Ул юк инде...
Гаиләң тар синең аның өчен,
Йортың – төрмә,
Ишекләре корыч-тимердән.
Балаларың – исрек,
Исреп-исреп,
Нәслең черегән!
Барысы тилергән!..
Нәфрәт итеп «синең гаиләңә»,
Барлык матурлык дип белгән нәрсәңә,
Нәфрәт итеп сиңа!
Ул ант итә Казан урамында,
Ул ант итә мещан базында,
Ул ант итә сезнең арагызда,
Әй сез, калдык нэпман уллары!
Базар корольләре!
Шарлатаннар!
Череп беткән сыра кортлары!
Сез табынган алтын-көмешләрне
Тәңре итеп үзенә алалмый;
Сез аунаган пычрак баткаклыкта
Үзе өчен урын табалмый;
Ишетәсезме!
Сезгә кабак дусты,
Җырчы малай булып калалмый!

Көрәшчеләр!
Сезнең арагызга яшь бер егет килә,

Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да,
Атасы да,
Анасы да,
Сөйгән яры да...

## ОКТЯБРЬ ТӨНЕ

(*«Янар таулар» трагедиясеннән*)

**I**

Төн.
Тиле җил!
Ник, тәрәзәмнән кереп,
Яндырып куйган шәмемне сүндереп,
Син качып киттең?!
Минем ак кәгазь өстендә калды кулларым,
Ялгышып, бертуктамый язган
Сихерле юлларым...
Төн. Тиле җил!
Ник, тәрәзәмнән кереп,
Яндырып куйган шәмемне сүндереп,
Син качып киттең?!
Төн үтә.
Ә мин шулай таш урамнарга карап
Утырам.
Кем син, әй, мескен, нәләтләнгән карак?!
Бүлмәгә күз ташлыйсың да
Монда шәүләмне күреп
Яшренәсең! Мескенем!
А... ник шәмем сүнде минем?
Мин яза идем шундый бер зур төн хакында,
Кайсы төн – таң илчесе,
Килде дә, зур таш урамнардан
Тузаннар туздырып,
Тиргә баткан аждаһа бер
Аргамакка утырып
Сөйләде:
– Зур нәләтләр,
Зур давыллар,
Көчле янгыннар белән
Үчле зур гыйсъян явының
Уртасында «Ул» килә!

А... нигә нурлы шәмем сүнде минем?
А... нигә нурлы шәмем сүнде минем?
Кил, юат, әнкәй, «балам, иркәм!» диген.
«Син язарсың,
Төн үтәр, кояш чыгар да,
Син язарсың:
Октябрь төне».
Төн.
Набат тавышы.
Тавышлар:
– Набат, набат, набат!
– Сугыгыз!
– Мең кабат!
Зур набатның көчле тавышы

Җир шарында соңгы кат
Канлы гыйсъян билгесе булсын!
Набат, набат, набат!..

Нәрсә бу? Кемнәр качалар?
Таш урамнар гөр килә,
Чаң сугалар, туп аталар,
Канлы өннәр иштелә...
– Кем килә?
– Зур нәләтләр, зур давыллар,
Көчле янгыннар белән
Үчле зур гыйсъян явының
Уртасында «Ул» килә!
– А... хыянәт!
– А... һәлакәт!
– Кемнәр ул, рөхсәт сорамый,
Төрмәләрне ачтылар?
Таш урамнарга, котырган
Юлбарыслардай чабып,
Кулларын бутый-бутый,
Кемнәр алар, а... качтылар?!
Кайда сез, әй, ант белән
Тәре үбүче сакчылар?!

Капкалар бикле, тәти йортлар караңгы;
Яшренеп,
Куркынып, күзләр урамнарга карый...
Ә урамнардан үтә – кемнәр алар?
Кулларында зур чүкечләр, балталар
Берлә чолганган кылычлар, сөңгеләр;
Уртасында
Болгана канлы әләмнәр – билгеләр...
Җырлыйлар:
«Без идек әүвәл сарайларны төзүче ялчылар,
Инде без булдык хәзер зур, куркыныч гыйсъянчылар.
Без бөтен гомер буена туктамый,
Без озын төннәр буенча йокламый
Эшләдек:
Йортлар төзедек,
Без кызу утлар эчендә эшләдек,
Без түбәндә җир казыдык –
Без бөтен дөньяны төзедек!
Ни өчен безнең балаларны урамга аттылар?!
Ни өчен безне?..
Җавап юк?!
Ташлагыз ут
Шул нәләтләнгән сарайлар өстенә!
Ташлагыз, янгын бөтен илләрне
Алсын, капласын!
Янсын әйдә төрмәләр,
Барлык фахиш йортлар, сарайлар калмасын!
– Ягыгыз!
– Яндырыгыз!
– Набат, набат, набат!
– Сугыгыз!
– Мең кабат!
Зур набатның көчле тавышы
Җир шарында соңгы кат
Канлы гыйсъян билгесе булсын!
Набат, набат, набат!»

Таң ата...
Авыл читендә күп халык
Кулларына канлы балталар алып
Шаулыйлар:
– Нәрсә бар?
– Нинди хәбәр, ул кем килә?
– Зур нәләтләр,
Зур давыллар,
Көчле янгыннар белән
Үчле зур гыйсъян явының
Уртасында «Ул» килә!

Таң ата...
Гыйсъян явы әкрен генә
Канлы кырлардан басып җырлап килә;
Уртада «Ул» – Октябрьнең билгесе,
Җил белән яу уртасында селкенә.
  (Ут булып канат җәя ул
  Иске тормыш өстенә.)

  Таң ата...
  Гыйсъян явы әкрен генә
  Канлы кырлардан басып җырлап килә:
  «Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз
  (Кайсылар безне үлемдәй каплаган).
  Иштәсезме?
  Без яңа юл башлыйбыз
  Мәңге утларга, кояшларга табан!»

*1924*

**ГАСЫРЛАР ҺӘМ МИНУТЛАР**

Таш урамнар...
Атлы сакчы тиз генә
Бер урамнан бер урамнарга чаба...
– Кем җинаятьче? –
Атын ул камчылап,
Атлыга тагын караңгы,
Тын урамнарга таба...

Таш урамнар!..
Шундагы зур төрмәдә
Без богауларда озак яткан идек
Һәм,
Тилергән юлбарыслардай, авыр
Зур ишекләрен бәреп ваткан идек.
Ул, –
Чабып киткән кылычлы сакчы да –
Зур җиңүдән соң куелган сакчыбыз;
– Кемнәр, әй? – Узгынчылар!
Ник сакчыга
Сез болай нәфрәт белән күз аттыгыз?!
Төн.
Тирән тынлык.
Шулай мин таш урамнарга карап
Утырам.
Мең кат санап,
Мин саташтым:
Бер, ике... дүрт – адаштым...
Ун... егерме... ах, тагын
Мин югалттым шомлы көннәрнең,
Гасырларның санын...

Төн карасын яндырып, таңнар туа;
Таңны – көн,
Көнне
Гасыр, еллар куа.
Бер минут – үлде,
Шулай ук туктамый,
Картаеп, эштән чыгып, көннәр үлә,
Ак сакаллы канлы еллар тын гына
Җан бирә.
Туа,
Тагын да җимерелә...
Көн килер дә,
Бер матур таңда кинәт
Карт тарих башын түбән табан ияр
Һәм:
«Бүген көн Октябрьгә
Илле ел тулды», – дияр.
Яңгырар завод, урамнар;
Тротуарлар буйлатып
Җир балалары йөрерләр,
Шул урамнарга тулып,
Зур факелларга ягылган
Көчле утлар уйнатып.
Ә хәзер

Күзләр тегәлгән
Канлы мәйданга табан.
Без beләбез!
Иң каты һәм
Зур көрәшнең соңгысы
Үтмәгән –
Алда һаман!..

Ул көрәшкә хәтле илнең
Чикләрендә атлылар
Туктамый чабып йөрер,
Мәгърур иркле сакчылар
Ил чигендә һәр күренгән
Шомлы шәүләгә табан
Сөңгесен очлар –
Көрәшнең соңгысы
Алда һаман!..

Таш диварлар...
Зур завод әкрен генә
Күз төшерде бер кызыл йорт өстенә.
Анда кем, төндә агач мылтык тотып,
Туктамый гел арлы-бирле селкенә?
– Ул – пионер.
Бер чигә, бер тиз генә
Мылтыгын очлап суза алга таба.
Ул белә:
Канлы көрәшнең соңгысы
Үтмәгән –
Алда һаман!..

Мәскәү...
Коминтерн Мәскәү эченнән торып
Сигнал бирә:
Төн үтә...
...Тиздән кызыл таң...
Соңгы кан...
Җир шары сулдан...
Азатлыкка табан!

***21 гыйнвар***

Сәүдәгәр Сәйфетдинов
Төнлә бүген
Зур урамнан карт аю төсле йөри.
Совзнаклар, червонецларны тотып,
Рестораннан ресторанга өстери.
– Дайте пиво!
Ул эчә,
Ялгыз түгел,
Бик күп алар –
Гайниләр,
Сәйфелмөлекләр, башкалар...
Туктамый эчә,
Бөек шатлык бүген (?),
Ак сыра ташып йөриләр
Ресторанда марҗалар!
Туктагыз, торгаш,
Сифилитик марҗалар!..
Туктагыз! –

Еллар,
Гасырлар,
Дөньялар!
Бер минут –
                үлде.
Икенче бер минут
Шундый бер җимрү белән килде...
Кинәт
Радио,
Радио:
– Ленин үлде...

Комклуб;
Обком бүген доклад бирә.
Чү!
Кинәт докладчыбыз ник туктады?
Зал көтә.
Шомландылар,
Рәис торып башын иде;
Һәм
Радио:
– Ленин үлгән! –
Диде.
Бер секунд...
Шуннан? –
Зал елый, үкси иде...
«Сез корбан булдыгыз
        авыр сугышта...»

Кино, –
«Тарзан»[2],
Джунгли маймыллары,
Американың адашкан уллары,
Юлбарыслар,
Әллә нәрсәләр тагы!
Чү!
Кинәт лента өзелде.
Залда ут сүнде.
Берәү:
– Радио,
Ленин үлгән! –
Диде...
Туңды зал –
Күз яшь,
Елаулар...
Экранда ут янды тагын,
Тик бу юлы күрделәр анда
Кайгылы рәсмен аның...
Зал таралды,
Тын урамнарга таралды бар халык,
Канлы яшь, хәсрәт белән зур
Кайгылы хәбәр алып...
Төн.
Завод.
Мастер Иванов
Берүзе сүзсез генә
Нәрсәдер бора,
Тагын тиз-тиз генә
Яшьләрен сөртә.
Ул, ишетсә дә хәбәрне,

Үз постын ташламады.
Иртәгә
22 нче гыйнвар...
Радио,
Радио,
Радиолар...
Җир шарын сүзләр болыты чорнады;
Электроннар,
Болытлар барсы да
Җырлады:
– Ленин!
Ленин!
Ленин!
Ленин!
Баррикадаларда,
Сарайларны җимергәндә,
Бомбалар,
Утлар эчендә,
Төрмәләрдә,
Шахталарда
Син идең безнең белән.
Канлы кырларда сугышканда,
Синең шәүләң һаман
Безгә ак юллар сызып торды
Азатлыкка табан!
Безне коллыктан азат иткән
Бөек юлбашчыбыз,
Безгә ирекле сарай төзгән
Беренче ташчыбыз!
Син бүген бездән киттең...
Ленин,
Ленин,
Ленин, хуш!
Ленин был,
Ленин умер,
Прощай, Ильич!
Прощай, вождь!

Радиолар
Лондон, Париждан,
Даниядән:
– Ленин үлмәде,
Ул һаман үлмәде,
Ул һаман юлбашчыбыз!
Испаниядән:
– Без аның сызган юлы белән
Тәхетләрне ватып,
Таҗларын,
Корольләрен,
Бароннарын утка атып
Яндырырбыз.
Италиядән
Шундый ук радио;
Бөтен җирдән –
Төрек, Германиядән!..

Зур сарай;
Керзон[3], сараен актарып,
Эзләде рәсмен Ленинның.

Тапты да
Кулына алып туктады.
Нигә ул:
– Үлде, –
Диеп шатлана алмады?
Чөнки:
Зур сарайның читендә бүлмәдә
Йорт караучысы һаман да сөйләнә:
– Ленин!
Ленин!
Ленин!..

Ул менә шунда ята.
Ул, ул – Кеше,
Кайсы өчен бүген
Бөтен Җир яшь түгә,
Кайсының рәсмен бүген бездән ерак
Африканецлар табып елап үбә.
Ул менә шунда ята.
Нинди тыныч,
Баш очында дуслары сакта тора.
Ул ята –
Бәйнәлмиләлнең мәркәзе –
Тын гына,
Тып-тын гына...

***27 гыйнвар***

Без бүген тордык караңгы төн белән
Мәңгегә саубуллашырга.
– Кем белән? –
Дустыбыз,
Юлбашчыбыз Ильич белән!
Без бүген билге кададык
СССР сахрасына,
Таш урамнарга,
Авылларга,
Урал, Донбассына.
Кайгылы билге, –
Бөтен дөнья тулы
Ул кара билге белән.
Миллион йөрәкләр берьюлы
Тын гына тибә:
– Ленин!
Ленин!
Ленин!

Без, бөтен дөнья, урамда:
Франция,
Испания,
Дания,
Германия...
Анда ораторлар сөйли,
Монда пионерлар:
– Ул үлмәде,
Ленин мәңге бар!
Ленин – без ул!
Ә без? –
Бөтен дөнья!
Без бар!
Без – миллионнар,

Көчле ленинчылар!
– Кузгал, уян, ләгънәт ителгән[4]...
Ораторлар!
Сәгать дүртне сукты!
Эш дөньясы кинәт туктады.
Башлар түбән таба иелделәр,
Машиналар шымды,
Тын калды.

Рур иле[5]...
Зур шахталар...
Мәйданында меңнәр туктаган,
Серле бер тынлык эчендә әкрен-әкрен уртадан
Күтәрелә бер рәсем.
Күзләр тегәлә,
Соңгы кат саубуллашып,
Ул рәсемгә табан...
Зур Париж.
Шау-шу.
Урамнар.
Тротуарларда халык
Бер-берен таптый,
Кызу сәүдә бара,
Сатып алып,
Шаулыйлар;
Зур урамнан
Автомобильдә барон йоклап килә,
Йоклый ул, исрек, яланбаш,
Йөзтүбән яткан көйгә.
Чаттагы йорттан шофер
Күрде сәгать тулганлыгын, –
Туктады.
Артындагы исрек барон
Сизмәде
Ник,
Нәрсә,
Ни
Булганлыгын...
Ул менә шунда ята.
Ул, ул – Кеше!
Кайсын гасырлар тудырды,
Минутлар үтерде.
Ул ята,
Иске тормышны күмәргә килгән бөек каберче.
Биш минут,
Шуннан:
«Сез корбан булдыгыз авыр сугышта...»
Син, кояш!
Аны тудырдың,
Син аны назлап сөйдең,
Син аны, һәр көн чыгып:
– Ул бармы? –
Дип карый идең...
Ул хәзер юк,
Ул кабердә...
«Сез корбан булдыгыз авыр сугышта...»

Ник елыйсыз сез, урамнар,
Ник елыйсыз? Туктагыз!
Атыгыз, туплар, бароннарга каратып атыгыз!
Бу булыр Ильичка биргән
Иң ахыргы антыбыз...

Ә Совнаркомдагы Ленинның бүлмәсе
Бик озак көтте хуҗасын, –
Килмәде...
Таш дивар,
Ятим диваннар белмәде...
Юк!
Ул үлмәде!
Ул җибәргән көчле янгын
Зурая, үсә һаман,
Станоклардан киләбез ант белән
ВКП сафына табан.
　　Бер заявление,
　　Мастер Иван яза.
　　Кемнәр тагын?
　　Мең вә миллионнар!
　　Күгәргән Җир шарын
　　Селкетеп антлар итәбез без бүген
　　Яндырырга мәңгегә коллык йөген!
　　Ул үлмәде.
　　Җир шары өстендә Ленин
　　Шәүләсе көн-төн йөри,
　　Уң кулында канлы байрак,
　　Сул белән
　　Куркыныч елларны алга өстери.
　　Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,
　　Төрмәләр, подвал, заводларга керә
　　Йә, коточкыч байрагын тоткан килеш,
　　Ул кинәт килеп чыга зур
　　Парламентлар өстенә!..

* * *

Бүген радио безгә хәбәр итте:
Германиянең сатлык палачлары
Соңгы чиккә килеп җиттеләр;
Урбанусны ун ел каты төрмә,
Каторгага хөкем иттеләр.

Урбанусның кансыз хакимнәре!
Бүген сездә,
Төрмәдә кан,
Ләкин
Белегез:
Кан тудырган
Көрәш күләгәсе һаман да,
Инәлүсез каты кулы белән
Чикләр сызып канлы яланда,
Зур көрәшкә чакыра!
Озак түгел,
Шул ук хөкем сараенда
Үзегездән хисап алыныр,
Байракларыгыз пычрак гәүдәгезгә
Оят кәфене булып ябылыр!
Бүген СССРның ирекле гаскәрләре
Җиде еллык данлы бәйрәмен
Иткән чакта,
Урбануслар исме белән бизәп,
Урамнарга кадый байрагын!

## УРМАН

*(Рабфакны бетереп, вузда укучы бер студентның истәлегеннән)*

...Мин, партизан, анда кайтырмын.
Урман.
Анда давыл симфониясе,
Анда үзенә башка тавышлар,
Анда кыргый кошлар,
Ач бүреләр җырлый,
Анда шаулый күлләр, камышлар...

Урман.
Бер агачтан күчеп бер агачка,
Азык эзләп очкан сандугач
Адашкандыр, бәлки,
Ул урманда,
Мескен,
Кайда кунар инде, төн булгач...

Урман.
Яфраклы төн.
Урман –
Зәңгәр төтен.
Яздыр әле анда
Һаман да...
Бүген, бәлкем, энем Әхмүш шуннан
Волсоветка табан үткәндер;
Арык бүре камышлардан чыгып
Туктап торгандыр да

Киткәндер...
Әхмүш агай, бәлки, төн йокламый,
Качып кына, юкә кискәндер...

Урман.
Читләрендә аның әнкәй арыш урган, –
Ләкин башкаларга...
Мескен...
Үзе ачтан үлгән соңыннан.
Миннән хәзер ерак булган,
Минем көтү көтеп йөргән урман!
Сәлам сиңа сөйгән улыңнан!
Синең бөтен җирең минем хәтердә;
Сагынсам да сине,
Яратсам да сине,
Кайта алмыйм әле хәзергә.

Көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе
Алдан чабып йөри торгандыр;
Мин партизан булып киткәч, яланыңда
Кемнәр көтү көтеп йөргәндер...

Мин, юкәләр юнып, җырлый-җырлый,
Чабаталар үргән урында
Кем ул – җырлый-җырлый көннәр буе,
Ак юкәләр сырып кулында,
Утыра торгандыр ул шунда.
Урман!
Сагынсам да, синдә тиз булмам.
Юлларымның башы синдә, урман!
Яшьлек көнем синдә узган!
Синең яланыңда
Әткәй китте аклар кулыннан.

Урман!
Мин, партизан, сиңа кайтырмын!
Кайтырмын бер килер көннәргә;
Тик көтүче булып түгел,
Ә инженер булып эшләргә!

## КАРТ АРТИСТ

(*31 мартта ясалачак Кари кичәсенә багышлап*)

Менә карагыз минем йөзләремә, –
Анда нинди юллар сызылган,
Зур күзләрем эчкә кереп баткан,
Ак чәчләрем ничек тузылган...
Мин – карт артист,
Татар сәхнәсендә
Ач-ялангач килеш күп еллар
Хезмәт итәм. Менә шушы юллар –
Минем хезмәтемнең шаһиты.

*

Салкын сәхнә минем йортым иде,
Ертык пальто, тузган киемдә
Бөтен гомрем буе хезмәт итәм.
– Кемгә?

Анысын белмим үзем дә...
Караучылар: байлар, байбәтчәләр,
Пудраларга чумган курчаклар
Көлә иделәр миннән;
Бармак төртеп көлә иделәр алар ул чаклар.
Әрәм хезмәт,
Ачлык, ялангачлык
Тормыш төбенә мине ташлады,
Зур теләкләр тулган күкрәгемне
Үлем микроблары каплады...
Менә карагызчы минем йөзләремә,
Анда нинди юллар сызылган.
Зур күзләрем эчкә кереп баткан,
Ак чәчләрем ничек тузылган...

*

Бәхетле сез, иркен яшь артистлар;
Иркен сәхнә – сезнең йортыгыз,
Шул сәхнәдә ярлы эшчеләргә
Хезмәт итү – сезнең бурычыгыз!
....................
Бирегез миңа шушы «эшче картны»!
Мин ул картны шулай уйнармын, –
Чәчләрегез сезнең үрә торыр,
Яшьләрегез агар,
Мин дә ул карт булып зур сәхнәдә
Тыела алмый үкреп елармын...
Чөнки мин дә, шушы эшче карттай,
Бөтен авырлыкны күрдем мин;
Аның кебек, байга хезмәт иттем,
Аның кебек, сөрелеп йөрдем мин...
Бирегез миңа шушы эшче картны,
Шулай матур итеп уйнармын.
А, юк!..
Карагызчы минем йөзләремә, –
Анда нинди юллар сызылган,
Күзләремнән үлем карый хәзер,
Ак чәчләрем ничек тузылган...

## ДАВЫЛДАН СОҢ

### I

Минем геройларым
СССРның
Бөтен җирләрендә яшиләр;
Эшсез урам даһилары минем геройларым,
Минем геройларым
Көлә, елыйлар;
Минем геройларым
Кабакларда
Чәнчелгәнче сыра эчәләр...
Материалым:
      буран,
              давыл,
                       таңнар,
                                 кичәләр.
Материалым:
      син дә,
              мин дә,
                       ул да,
                              бу да,
                                     алар да.
Бу темага кирә давылдан соң бөтен типлар:
Эшле,
Эшсез –
           бары да.
Монда концерт бирә: кулаклар да,
Мин дә.
Бүлмә.
Бүлмәдә кошмар.
Ертык чалбар.
Китап, шкафлар.
Ә урамда
Кояш чәчәк аткан;
Нурдан туфан
Мәйданнарга ташланган,
Җир уянган.
Урам дулкынланган.
Тормыш симфониясе башланган...

Тормыш симфониясе.
Оркестр
  Йөрәк кылларыннан,
  Аһ-зарлардан,
  Көлү өненнән,
  Тимер тавышлары,
  Гудоклардан,
  Миллион тавышлардан төзелгән...
  Ул оркестр шушы урамнарда
  Күптән уйнап килгән,
  Аның йөрәк өзгеч кылларында
  Үлем тавышлары,
  Коллык аһәңнәре,
  Корал тавышлары ишетелгән...
  Мин дә бүлмә;
  Бүлмәдә кошмар,
  Ертык чалбар,
  Китап, шкафлар...

Бүлмә ишеген бикләп чыгып китәм
Кырга, урамга;
Ачлар арасына,
Туклар дөньясына –
Тормыш симфониясен тыңларга.
Менә урам.
Урам симфониясен
Аяк тавышлары башлыйлар;
Иртә сәгать биштән
Төнге өчкә кадәр:
Шап-шоп, шап-шоп!
Директорлар,
Завлар,
Зур корсаклы кешеләр
........атлыйлар...

**II**

Байрак илтүче.
Сүзне башлап китәм шул урамда
Моннан бер ел әүвәл күргән баладан,
Исмен хәтерләмим.
Гомеремдә бер кат яңадан
Күрерменме?
Белмим.

– Бәйрәм.
Зур мәйдан.
Комсомоллар Ирек мәйданына
Колонналар булып агалар,
Ә ул иң алдан
Байрак тотып килә,
Бөдрә чәче
Җилләр ирке белән таралган.
Байрак илтүче,
Көләч йөзле кем иде ул? –
Белмим.
Бөдрә чәчле,
Зәңгәр күзле,
Күк блуза кигән комсомол
Кем иде ул? –
Белмим.
Байрагында
«Киләчәк көн якты,
Тарих канаты
Безне алып бара.
Без туачак тормыш сызыгында,
Бәлки, үләрбез...
Ләкин, бөтендөнья азатлыгы
Ишеген ачып,
Хезмәт явын азат итәрбез,
Җиңәрбез!»
Дигән сүзләр.

Исмең белмим.
Ләкин син Казанда
Мине, бәлки, бик күп күргәнсең,

Кыш буенча бу ел укыгансың,
Клубларга йөргәнсең.
Ә мин?
Очратмадым сине...
Ләкин
Очратырмын, бәлки,
Собраниедә,
Клубта,
Ә бәлки, бергә булып та,
Танышмыйча үләрбез без
Бер үк полкта,
Бер үк фронтта...
Урам.
Урамда
«Барабыз»лар йөри буранда.
Әй, кем анда?
Милиционер.
Рабфак.
Рабфакта –
Кичә.
Кичекмәбез хәзер барсак та.
Зур зал,
Залда «Интернационал».
Комсомоллар җырлый:
«Кузгал...»

Бу гимнга мең клублар кушыла.
Подваллардан,
Завод диварлары арасыннан
Меңнәр тавышы бергә бәйләнә.
Җирдә гыйсъян җыры,
Җирдә тормыш симфониясе,
Җир әйләнә.

Корсак:
Үсәр әле аз-маз сыптырсак!
Кояш иңгән.
Күк йолдызлар белән күмелгән.
Кабакларда кыллы оркестрлар
Мазуркалар белән яңгырый.
Исрек җырлар,
Шешә музыкасы,
Эчке бокаллары шалтырый...
Кошмар.
Бер якта зур зал.
Залда «Интернационал».
Икенчедән:
Нэплар, бокаллар.

Ул авылда туды,
Шунда үсте,
Аны зифа авыл таллары
Кояш эссесеннән саклады.
Салам япкан җимрек каралтылар
Салкын җилдән, кыштан каплады.
Ул авылда туды,
Батрак улы,
Бик күп авырлыклар күрде ул,
Көтүче дә булды,
Фронтларда

Партизан да булып йөрде ул.
Ә бүген
Рабфак кичәсендә,
Зал эчендә ул да бар.
Әүвәл авыл улы иде,
Хәзер – комиссар.

Ул шәһәрдә туды,
Шунда үсте,
Пар атларда чапты,
Типтерде,
Гимназиягә керде.
Себерләрдә йөрде,
Бывший офицер,
Хәзер
Кабак исрекләре арасында
Ул да бар...
Кошмар.
Комиссар да зал.
Залда
«Интернационал...»
Офицер да кабак,
Кабакта шешәләр...
Көчле яшен зәңгәр күк йөзендә
Уттан кылыч булып яна да
Кинәт сүнә.
Көчле күк күкрәве, юлбарыстай,
Киң сахрага тавыш сала да
Кинәт тына.
Тагын яшен яшьни,
Тагын күкри,
Тагын шулай җилләр исәләр,
Тагын яңгыр ява,
Тагын, тагын, тагын...
Айлар, еллар шулай үтәләр...

Табигатьнең иркен күкрәгендә
Мәңге көрәш,
Мәңге хәрәкәт,
Мәңге туу,
Мәңге артып тору
Белән бергә
Үлем-һәлакәт...
Картлар үлә,
Яшьләр туа бара.
Тормыш яңара...

Базар...
Базарда
Магазиннар.
Сәүдәгәрләр план корып ята таларга, –
Күршедәге эшче кибетләре
Үлем маршы җырлый аларга...

Авыл...
Авылда
Этләр улый җилле давылда.
Кырлар...
Кырларга
Тракторлар килә җырларга.

Октябрина.
Пионерлар исем сайлый:
Кайсы алай,
Кайсы болай ди,
Шаулашалар.
Соңыннан
«Вил» дип аңар исем кушалар.
– Минем нәни дустым!
Бәйрәмеңдә синең булалмыйм,
Ләкин туган көнең белән тәбрик итми,
Катнашмыйча читтә калалмыйм.
Ни булса да,
Гомреңне кайда гына уздырсаң да,
Тормыш җепләреңне
Ничек кенә туздырсаң да,
Барыбер миңа.
Ләкин
Көрәшче бул!

Ул үзенең улын исемләргә,
Мәҗлес корып, мулла чакырды;
Гайнүк кулак килде,
Ибруш керде,
Шулай итеп мәҗлес ачылды.
Бәлешләрне бөгеп,
Балны сөзеп,
Әнвәр диеп исем бирделәр.
Битләр сыпырдылар.
Мулла болай диде:
«Егет, изге юл!
Озак яшә,
Әнвәр паша кебек,
Динле бул!»
Шулай итеп кошмар...

Пәрдә әкрен генә күтәрелә.
Зур пәрдәнең ике ягында
Ике тормыш күренә,
Тагын да
Пәрдә төшә.
Бер ягында аның иске тормыш:
Зур чиркәүләр, мәчет, кабаклар,
Таш урамнар –
Шунда бик күп халык,
Акылсызлар, мулла, монахлар...
Бер ягында аның яңа тормыш:
Совнаркомнар,
ЦИКлар,
Губкомнар,
Комсомоллар,
Эшче, коммунистлар,
Комиссарлар, тагы наркомнар.

Иске тормыш үлә,
Коммунизм гиганты күтәрелә.

Көннәр туа,
Еллар әкрен генә
Аренага безне үстерә.

Кояш һәр көн чыгып, көлә-көлә,
Безне карап китә.
Без үсәбез! –
Үткән күперләрне ягып,
Якты киләчәккә күчәбез.

Киләчәк көн якты,
Тарих канаты
Безне алып бара.
Без туачак тормыш сызыгында,
Бәлки, үләрбез...
Ләкин,
Бөтендөнья азатлыгы ишеген ачып,
Җир йолдызын азат итәрбез!!!

## ЕЛЛАР ТАҢЫНДА

Эшсез булсаң, айга мен дә утыр,
Шуннан кара җирнең төн ягын:
Менә Азия,
Менә Европасы,
Ә бу җирдә менә атаулар,
Зур диңгезләр,
Күлләр,
Урманнар да
Күкрәп торган тимер, таш таулар...

Шәһәрләрнең түбәләрен күтәр,
Йорт башларын алып ташла.
Әкрен!
Йоклыйлар...

Төнге закон
Матур сарайларга саклар куйган.
Саклан «яман» уйдан!
Закон!

Европада
Төндә йөргән «шикле» кешеләрне
Полициягә тотып озаталар,
Күп тә үтми, аңа:
– Коммунист, –
дип хөкем була.
Шуннан...
Аталар.
Үсәр ачу таңы ерак, диләр,
Шуның өчен алар тынычлар,
Ишекләре бикле,
Ялан кылычлар
Ышанычлы.
Әкрен!
Йоклыйлар...
Сарайларга саклар куелган.
Саклан «яман» уйдан!
Закон!

Кинәт гасырларның күз яшеннән
Бомба ясап ыргытсаң да,
Шушы йоклап яткан Европаны
Уятсаң да,
Әйтсәң әгәр:
– Ленин тере! –
дип...

Тынлык.
СССРның чиге.
Менә сакчылар.

Тагын тынлык.
Тынлык өзелә.

Мәскәү урамыннан
Шаулап үтә төнге атлылар...
Иртән беренче гыйнвар.

Урам.
Урамда
«Барабыз»лар йөри буранда.
Алгы көннәр безгә җиңү алып килә.
Шуның өчен
Бүген без кичен
Декабрьнең соңгы көнге битен
Календарьдан ертып ташлыйбыз.
Һәм
Үткән көннәр кире кайтмасыннар,
Үткән көннәр үлсен!
Үткәннәрне сагнып, бик кирәксә,
«Тиздән үләчәкләр» тилерсен!

(Үткән көннәр безнең якты түгел,
Ләкин шәүкәт белән алар үтелгән,
Җиде елда безгә каршы булган
Бик күп көчләр тар-мар ителгән.)
Тарих адымнары – туар еллар
Безне алып бара.
Беләбез!
Үсәр ачу таңы ерак түгел.
Шуның өчен, көлә-көлә, без
Иске елның канлы зур пәрдәсен
Үлем маршы белән ябабыз
Һәм
Яңа елга пәрдә ачкан чакта
Кычкырабыз:
– Долой аренадан фиргавеннәр! –
Үлем каргалары,
Бароннар!
Долой фашистларга маневрлар,
Зур корсаклар,
Алтын погоннар
Аренадан китсен!
Тормыш аренасы
Трибунага бу ел әйләнсен.
Катакомбаларның,
Төрмәләрнең
Канлы диварлары эчендә
Богау тавышлары шалтырый.
Һиндия, Әфган, Кытай кырларында
Кылыч шәүләләре ялтырый.
Мисыр чикләрендә шашкын туплар
Корбаннарын чәйнәп улыйлар,
Миллион коллар әкрен,
Ләкин йөрәк өзгеч
Моңлы тавыш белән елыйлар:
– Ай-й-й-й...
– Ай-й-й-й...

Европаның канлы кырларында

Окоп канаулары һаман да
Күккә карый,
Ә анда
Сынып калган куллар,
Җимерек башлар,
Яңа елның таңы атканда,
Аренага безне көтәләр!..

А, Германия!
Синең Гамбургта[2]
Былчыракка салып тапталган
Байрагыңда
«Без туабыз,
Алар бетәләр!»
Дигән сүзләр
Бу ел үч алырга
Аренага сезне көтәләр!..
Тарих адымнары – туар еллар
Шунда алып бара.
Беләбез.
Үсәр ачу таңы ерак түгел –
Шуның өчен, көлә-көлә, без
Иске елның канлы зур пәрдәсен
Үлем маршы белән ябабыз.
Һәм
Яңа елга пәрдә ачкан чакта
Кычкырабыз:
– Долой
Аренадан зур корсаклар!
Тормыш аренасы
Трибунага быел әйләнсен,
Гарептәге палач-сволочьлар
Үлем дарларына бәйләнсен!

**СЫРКЫДЫ АВЫЛЫ**

Шәхми карт –
Авыл советында каравылчы,
Икенче ел була, –
Көн дә ул төндә шулай ялгыз кала,
Көн дә шул йортның эчендә карт белән
Бик таныш дусты «берәү»,
Һәм
Ут яна...

Төн.
Үзе кыш.

Җил улар,
Кар буранын туздырыр,
Юлчылар юлдан адашыр...
Кем белә? –
Юлчылар
Шул авылны тапсалар да төн белән,
Бәлки, советта алар кунып чыгар...
Җил хәбәр сөйли.
Караңгы, кар-буран.
Карлы тауларга күмелгән киң урам
Таң көтә.

– Ят, балам... иртән утынга!
Төн үтә.
Җил бүген эшли:
Йорт башындагы саламны селкетә...
Җил хәбәр сөйли,
Җил котырган,
Җил тилергән,
Җил дулый.
Ач бүре юлдан адашкан.
Ач бүре шыңшый,
Улый:
– У-у-у-у-у...
Еракта...
Төн.
Үзе кыш.
Төн –
Давыллы,
Кар туза...
Төн тилергән,
Төн котырган,
Төн узар.

Төн узар...
Шәхми карт –
Авыл советында каравылчы;
Икенче ел була, –
Көн дә ул төндә шулай ялгыз кала,
Көн дә шул йортның эчендә карт белән
Бик таныш дусты – Ленин,
Һәм
Ут яна...

Ут янар,
Шәхми бабай һәр төндә дә,

Ялгызы утрып, чабаталар үрер;
Төн үтәр,
Иртә булыр,
Һәр иртәдә
Ул диварда Ленинның рәсмен күрер...
Җил.
Җил бүген – хезмәт батыры,
Җил урамда кар көри,
Җил молодец!
Карт авылны
«Ду-у-у» килеп күмеп йөри.
Җил бүген ач,
Җил ишектән
Нан сорап борнын суза,
Җил – пионер,
Морҗалардан, бай кулакларны янап,
Йодрыгын селкеп уза:
– У-у-у-у-у-у-у...
Кар туза...
Искелек,
Коръән,
Иман сеңгән диварлары җил белән
Селкенә.
– Ләхәүлә!
(Йортта),
Тышта кышкы җил көлә.
Бу – авыл.
Монда Мифтах мулла дигән бер
Карга бар.
Ул гына түгел,
Аңардан башка бик күп каргалар,
Мал өчен, корсак өчен бер-берсенең
Борыннарын чәйнәшәләр дә алар,
Сизмәсен дип хәйләбезне башкалар:
– Дин, – диләр,
– Алла, – диләр.
(Шәхми бабайча:
Тфү! Сабынчы марҗалар!)
Кыш.
Кышын карлы буран булса,
Язын яңгыр була.

Кыш.
Кышын карлар дуласа,
Яз көне иген уңа.
Бу шулай.
Син комсомолмы?
Булмасаң,
Бел:
Комсомоллар – яшь ленинчылар алар,
Комсомоллар – искелеккә
Бомбалар!
Син комсомолмы?
Булмасаң,

Иртәгә доклад советта,
Кил дә тыңла.
Комсомол
Гаптери доклад укый,
Ул докладында
Муллаларны борынлар!
Җирләр, налогларны алып,
Сәүдәгәрләргә кирәкләрен бирер дә,
Ленин сүзенә тукталып,
«Ярлыларга кооператив төзергә киңәш итәр».
Шау-шу китәр,
Буталырлар,
Ду кубарлар,
Ярлылар яклап сөйләр,
Сәүдәгәрләр пыр тузар да
Комсомолларны сүгәр,
Якалашырлар...
Шулай.
Син комсомолмы?
Комсомоллар –
Яшь ленинчылар алар,
Комсомоллар – искелеккә
Бомбалар!

Ястү намазын укыганда,
Иманлы Әптерүш
Йоклады.
Иртән уяныр.
Сәүдәдән кайтканда, Нуркай
Кар базыннан чыкмады.
Йөзтүбән килсен!
Җилгә эш!

Төн.
Төндә –
Җил.
Төндә –
Караңгы.
Шәхминең йорты тора,
Җил кунак йортта.
Хуҗасы килмәде,
Килмәс, пожалуй, йортына...
– Сез аны күптән беләсез,
Ул гомердә бер генә
Шул кара йортка килеп,
«Хуҗа» булып,
Тук килеш куналмады бер төн генә.
Мәңге ялчы,
Мәңге читтә,
Шуның өчен дә менә
Ул һаман карый Ленинның рәсменә.

Ул белә:
Ленин – Кеше!
Нәфрәт итеп
Күз тегә
Ленинны сүккән байгуралар өстенә!

Җил.
Җил, манараның аена утырып,
Сызгыра:
– Фу-у-у-у-у-у...
Нәни пионер... Яшь песи мыштым гына,
Өстәл итеп Әүхәдинең Коръәнен,
Әнкәсе тоткан нәни бер тычканын
Куйды да
Кичке ашын уздырды ул...
Шул,
Нәрсәгә аңарга синең Коръәнең дә,
Нишләсен, алыш-биреше булмагач,
Диннәрең, ходайларың белән аның!

Төнге гыйнвар.
Җил дә
Кыш.
Акбай бүген,
Туңудан куркып, урамга чыкмады, –
Хуҗасында икмәге юк.
«Ярлы эт!»
Ач килеш саламга күмелеп йоклады...

Төнге җилдә
Җил тишек тапкан да
Шуннан сызгыра.
Төнге җилдә
Шул авылга
Почтада өч хат тора.
Берсе Нәҗиптән.
Болай ди:
«Инде нишләргә икән?
Сәүдәләр юк;
Хәл начар,
Әткәй!
Кире кайтам», – дигән.
Икенче хат.
Бу хатны рабфактагы яшь
Комсомол Әсгать яза:
«Мортаза!
Мин бу ел рабфакны тозлап,
Борычлап тәмам итәм.
Көзгә, Алла йөзтүбән килсә, дигән,
Вузга китәм.

Тик менә кайда китәргә? –
Әллә Мәскәүгә микән?»
Соңгы хатны
Яшь политрук
Комсомол Мәхмүт яза.
Адресы:
«Сыркыды авылындагы ячейкага».
Хатта шундый җөмләләр бар:
«...Искелек үлә,
Аңарга без – кабер казучылар,
Иске утлар мәңгегә сүнә,
Без –
Яңаны ягучылар!
Без –
Давыл балалары, –
Без – мәңгелек,
Искелек – җанлы үлек.
Без – мәңгелек...

..................
Без – караңгылык, түбәнлектән атылган
Шундый бер утлы таган,
Без барабыз соңгы һәм
Канлы көрәшләр аркылы
Мәңге кояшлы кызыл таңга табан...
Хушыгыз!
Сәлам белән
Мәхмүт. Казан».
Төн минутлары үтәләр,
Төн –
Буранлы кыш төне,
Төн үтәр дә, көн килер,
Салкын ачы гыйнвар көне.

Төнге җилдә
Җил тишек тапкан да
Шуннан сызгыра,
Төнге җилләр уртасында
Комсомол ячейкалы зур
Сыркыды авылы тора!..

*1925*

**ПИОНЕРЛАР МАРШЫ**

Без яңа тормыш алып киләбез,
Урамнар, безгә юл бирегез!
Барабаннар сугып үтәбез без
Ал байраклар белән, күрегез!..

Пионер, алга!
Зур көрәш алда.
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез!..

Без кәкре борынлы суканы
Тракторга алмаштырырбыз,
Иске, черек тормышны җимреп, без
Яңа якты тормыш корырбыз!

Пионер, алга!
Якты көн алда.
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез!..

Без – ачулы сыйныфның уллары,
Бездә һәммәбездә теләк бер:
Коммунизм өчен зур көрәшкә
Һәр сәгать, һәр минут без әзер!

Пионер, алга!
Зур көрәш алда.
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез!..

Без яңа тормыш алып киләбез,
Агайлар, безгә юл бирегез!
Барабаннар сугып үтәбез без
Ал байраклар белән, күрегез!

Пионер, алга!
Зур көрәш алда.
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез!..

**НИКАХСЫЗЛАР**

Тукта,
Без шул бүлмәдәге пәрдәгә
Ут җибәрсәк тә янып китсә әгәр,
Ни булыр? –
Бернәрсә булмас,
Әйдә, янсын пәрдәләр!
Күрсен әйдә һәр үтеп барган кеше,
Бездә юк яшерергә, дустым, берни дә.
Бары шул:
Без икәү –
Динсез,
Никахсыз – бер өйдә!
Кайберәүләр:
– Ул, – диләр, – өйләнде дә
Барлыгын бирде аңарга мәңгегә.
Ялгышалар,
Мин сиңа бирдем бары ядкяр итеп
Дуслыгым белән
Ленин рәсемен генә.
Башка берни бирмәдем
Һәм бирмәмен;
Мин сиңа үлем алырга килмәдем.
Мин сыйныфныкы
һәм
үлмәдем!
Бер кеше бәхте өчен сүнмәс минем, –
Күкрәгемдә канлы ут сүнгәндә дә,
Мин – көрәшче бер сыйныфның солдаты,
Үләрмен аның өчен, үлгәндә дә...
Кайберәүләр сине дә:
– Иргә чыкты да, юләр,
Инде ул безнең өчен үлде, – диләр.
Ялгышалар,
Мин сине һич алмадым
Һәм алмамын,
Комсомолның постка куйган солдатын!
Тик бары юллар гына
Бергә туры килде дә,
Шуннан гына
Без икәү киттек, –
Артык берни дә.
Тагы шул:
Без икәү –
Динсез, никахсыз – бер өйдә.
Шурпалы учак,
Җылы почмак,
Нигә алар? –
Йөзтүбән килсен аның өчен башкалар.
Без бүген монда,

Ә иртәгә?
Кем белә? –
Җыенырбыз да кылычка-сөңгегә!
Без – бары
Бер казарманың усал солдатлары!
Яз чәчәк аткан,
Томанлы төн минутларны куа.
Без икәү.
Ә безнең уртада
Киләчәктә чәчәкле тормыш туа.

**СИН ДӘ ҮЛ ИНДЕ**

Бүген – соңы җиңү белән беткән зур көрәшнең
Сигез елы...
Мин – ерактан килгән авыл улы,
Кемне миңа тәбрик итәргә?
«Берәү» килә,
Аны туктатам да сөйлим:
– Бәйрәм безнеке, – дим, –
Сезнең тараф
Мәңгелеккә инде җиңелде,
Шуның өчен син дә үл инде!

Бүген бәйрәм көне...
Һәм мин – шашкан уйлар,
Тилергән хисләрнең даһие –
Бүген, урам буйлап килгән көе,
Үткәнемне уйлыйм:
Менә авыл өе...
Мин – авылның «бурлак Һадие».

Юллар мине шушы урамнарга
Бәйрәм итәр өчен китерде,
Еллар мине, авыл урамыннан алып,
Җырчы малай итеп үстерде...
Бүген – соңы җиңү белән беткән зур көрәшнең
Сигез елы,
Мин – ерактан килгән авыл улы,
Кемне миңа тәбрик итәргә?..
Яз үзенең соңгы җырын җырлый,
Урам бәйрәм көнен уздыра,
Нэпман гына шунда, урамдагы
Асравына
Ачуланып, нидер кычкыра.
Мин аңарга барып сөйлим:
«Кычкырма! –
Дим, –
Сезнең тараф мәңгелеккә инде җиңелде.
Шуның өчен
Лучше үл инде!»

Бәйрәм иткәндә,
Урамнардан бергә, җырлый-җырлый,
  Колонналар булып үткәндә,
  Кемне тагын тәбрик итәргә?..
  Бер авыл бар,
  Анда безнең күрше
  (Әнкәй белән кайчак дау булса)
  Мине сүгә.
  Ләкин хыянәтсез ана мәхәббәте
  Мин киенгән төпсез чабаталарны
  Саклый һаман.
  «Кайтыр балам, – ди ул, – сау булса!»
  Сез аңардан барып күпме генә
  Шушы тузган чабаталарны
  Сорасагыз да, ул бирмәс сезгә,
  «Баламныкы!» –
  Дияр,
  Каберенә илтәр аларны!
  Ә сез аңа барып сөйләгез:

«Балаң исән! –
Диегез, –
Ләкин сиңа булган мәхәббәте
Көрәш көче тарафыннан җиңелде.
Шуның өчен
Көтмә, кайтмас!
Син дә үл инде...»
Һәм ул тиздән үләр...
Еллар үтү белән, минем иптәш
Үзе шулай малай тудырыр.
(Ләкин минем балам художникмы,
«Разбойникмы», белмим, кем булыр?)
Ул да миңа, бәлки, әйтер:
«Яңа җырлар белән аренага
Яңа кешеләр килде,
Шуның өчен
Син дә үл инде...»
Мин дә үләрмен...

Ләкин бүген әле аренадан
Давыллы хисләрнең ташуын,
Гыйсъян иткән утлы йөрәкләрнең
Җиңелмәслек тиле ачуын
Җырлыймын мин:
«Бүген әле бик тар бер күләмдә
Итсәк тә без җиңү бәйрәмен,
Килер бер көн – бөтен Җир шарына
Кадарбыз без Ленин байрагын!
Шунда Англиянең бер солдаты,
Чемберленга нота урнына,
Сөялләнеп беткән кулы белән
Әкрен генә чиертеп борнына,
Әйтер:
– Сезнең тараф
Мәңгелеккә инде җиңелде!
Шуның өчен менә хәнҗәр сиңа,
Син дә хәзер, егет,
Үл инде!»

## ӘҮХӘДИ

Җил бүген төн, кулларын артка салып,
Йорт саен, эшле кешедәй, тукталып,
Тикшереп йөри:
Әүхәдинең йорт түбәсе япмаган,
Әүхәди кирәк дип тә тапмаган...
Кыш килер дә,
Җил, еракларга барып,
Зур болытларны авылга өстерәр,
Ул тишекләрне күмәр.
Тик,
Мич башында тун киеп яткан килеш,
Әүхәди:
– Ай-яй, малай, салкын!.. –
Дияр.
Әүхәдигә әйтегез:
Түшәмгә төкереп ятмасын,
Иртәгә үк йорт түбәсен капласын!

## БАЙРАК ТЕГӘБЕЗ

*(Казан университеты рабфагындагы комсомолкаларга багышлыйм.)*

Иртәгесе көнгә
Каршы төндә
Без утырып байрак тегәбез,
Байрак битләренә бронзадан
Ялкынланган сүзләр тезәбез:
«Октябрьнең биргән бүләкләрен
Тимер куллар белән саклыйбыз,
Чүкеч тавышлары уртасында
Ленин юлы белән
Тугызынчы елга атлыйбыз!»

Ә иртәгә безнең чиккән байрак
Комсомоллар белән уралыр,
Кояш безгә карап ялкынланыр,
Кояш безнең типкән йөрәкләрдән,
Кирәк булса, үзенә ут алыр.

Иртәгесе көнгә каршы төндә
Без утырып байрак тегәбез,
Читләренә асылмалар асып,
Ука белән читен бөгәбез.
Без беләбез:
Шушы ал байракның
Подвалларда яшрен ятканын.
Без беләбез:
Аның көрәшләрдә
Алгы сафта канга батканын.
Без беләбез
Аның киләчәген:
Соңгы байрак җирдә ал булыр!
Аның белән җирдә соңгы сугыш,
Соңгы кырылыш,
Соңгы кан булыр!

Шуның өчен дә без
Бүген төндә
Аны матур итеп тегәбез;
Читләренә асылмалар асып,
Ука белән читен бөгәбез!
Бәйрәм диеп, мещан кызларыдай,
Ашгып-ашгып, күлмәк текмибез,
Безнең бәйрәм башка, –
Бәйрәмне без
Пудра ягыныр өчен көтмибез!
Бәйрәм көнгә
Каршы төндә
Без утырып байрак тегәбез.
Бронзадан байрак битләренә
Ялкынланган сүзләр тезәбез!

**ПРОВОКАТОР**

Хөкем бара.
Совет законнары суд залында
Һава ярып яңгырап китәләр.
Аны бүген хөкем итәләр.
Суд алдында чәче көмешләнгән
Чал бер карчык, яшьле күзләрен
Сөртә-сөртә, залның йөрәгенә
Каннар белән яза сүзләрен:
– Бәхетле мин...
Әйе, үләр көннәремдә
Очраттым мин аны тагын да,
Ләкин охранкада түгел,
Менә монда –
Хөкем залында!..
Очраттым мин аны!
Бишенче ел иде... Минем ирем
Козлов фабригында чагында,
Ул һәр көнне безгә килә иде;
Ирем аны яхшы бер көрәшче,
Булдыклы бер ир дип белә иде...
Күп вакытта безнең бүлмәбездә
Собраниеләр булып үтә иде,
Качып йөргән бик күп большевиклар
Кайчак шунда кунып китә иде.
Ә беркөнне...
Төнге сәгать өчтә
Кинәт килеп ишек кактылар,
Ирем белән улым – күз алмамны –
Охранкага илтеп яптылар...
Ә бер айдан...
Алтмыш эшче белән
Икесен дә тотып аттылар!..
Алар өчен түккән күз яшьләрем
Тагын шулай җиргә агармы?
А, юк!
Беркем агыза алмас аларны.
Шул көннән соң кызым, эш табалмый,
Тәнен мәҗбүр булды сатарга,
Аңа «ул» гаепле, ишетәсезме?!
«Ул» гаепле!
Аны хөкем итми атарга!!!
Кичерегез, күздә яшьләр тормый,
Ләкин газапланып түгел,
Үзем дә
Белмим, нигә бүген хәзер шулай елыйм,
Ләкин йөземдә
Алар беренче кат шулай тәмле дә,
Газаплы да булып агалар!..
Шуннан соң мин аны охранкадан
Чыгып килгән чакта очраттым.
Ул күрде дә мине, туктады.
Ә соңыннан, танытмаска теләп,
Караңгыга кереп югалды.
Еллар үтте.
Үләр көннәремдә
Очраттым мин аны тагын да,
Ләкин охранкада түгел,
Менә монда – хөкем залында!

Хөкем кыска булды,
Совет законнары суд залында
Соңгы кабат яңгырап киттеләр,
Провокатор Борис Морозовны
«Атарга!»
Дип хөкем иттеләр.

## *1926*

### НӘНИ РАЗБОЙНИК

Рәхмәт, әнкәй, сиңа:
Ярый әле мине тапкансың,
Озын төннәр буе йокламыйча,
Җырлар җырлый-җырлый баккансың.
Синең авыр кара тормышыңда
Ярдәмчең булмадым булуын,
Ләкин
Авыр көрәш, бөек еллар өчен
Кирәк булган минем тууым.

Усал идем,
Шуның өчен дә шул
Гөнаһ-фәлән диеп тормадым,
Зәңгәр төндә
Күрше карчыгының
Ак әтәчен кереп урладым...
Шушы әтәч өчен усал карчык
Каргый-каргый теләк теләде:
– Денеңнән яз, явыз, урыс! – диде,
Кабул булды аның теләге...
Их!
Кышкы төннең салкын күкрәгеннән
Чаналар да шаулап үттеләр,
Чаналарга салып, еллар мине
Бик еракка алып киттеләр...
Әтәч пешреп яткан учакларда
Әллә кайчан утлар сүнделәр...
Усал идем,
Карчык-корчыкларга
Бик күп бәла-каза китердем;
Бакчабызга кергән үрдәкләрен
Таяк белән кыйнап үтердем...
Шул эшләрем өчен авыл халкы
«Разбойник» дип исем бирделәр;
Авылдагы бөтен усаллыкны
Миннән генә күреп йөрделәр.
Гомер уза,
Ләкин авылыбыздан
Тагын бер кат әле үтәрмен,
Сагнып сөйләр өчен ядкяр итеп,
Муллаларын кыйнап китәрмен...

Еллар безнең белән үтәләр,
Таңнарны алып килә кичәләр,
Минем нәслем булыр коммунарлар
Ата казлар кыйнап үсәләр...

Усал идем,
Шуның өчен дә бит
Мин авылга сыеп тормадым,
Сезгә килеп,

Авыл малаеның
Тилергән хисләрен җырладым...
..................
Давыл сүнәр, бәлки, йөрәктә,
Ул табылмас, бәлки, кирәктә,
Ләкин,
Үзем үлсәм, улым калыр,
Урным алыр,
Солдат булыр соңгы көрәштә...
..................
Еллар көрәш чиген үтәрләр,
Яшьләр тимер булып үсәрләр,
Ата казлар кыйнап үскән яшьләр
Буржуйларны тотып кисәрләр...

Их!
Маяклы юллардан юлчы бара,
Печән белән күмгән чанасын...
– Кая болай, юлчы, ашыгасың,
Нинди хәбәр алып барасың?
– Чемберленның сатыйм анасын,
Тупка тоткан Мәккә каласын!..

Динсез идем,
Шуның өчен дә бит
Әткәй мескен кулын ташлады:
– Бу имгәктән кеше чыкмас, – диде, –
Иблис булыр, – дия башлады...
Еллар үтте,
Менә хәзер инде,
Әткәй, килеп миңа карагыз,
Шагыйрь булды ата казлар кыйнап,
Шалкан урлап йөргән балагыз!..
....................
Шулай, әткәй,
Ленин юл күрсәтте
Юлдан язар усал улыңа,
Иптәшләрчә үткен каләм бирде:
– Мә, яз инде, – диеп кулыма.

Их!
Кичә генә әле февраль иде,
Бүген давыл кырга кар ташый;
Март аеның нечкә билле җиле,
Сузлып ятып җиргә, кар ашый...
Ерак калмый инде майга да,
Яз ясарбыз салкын тайгада.
– Җир безнеке булыр!
Ачулансак,
Шлем киертербез айга да...

Их!
Мин бит исән әле, күрше карчык,
Авылыбыздан тагын үтәрмен,
Сагнып сөйләр өчен ядкяр итеп,
Муллагызны кыйнап китәрмен.

**ӘЙДӘ, ЭНЕМ!**

Үләрмен дә,
                  онтырлар, дип,
Юкка гына, йөрәк, янасың,
Тамбов урманнары сагныр әле
Үзе үстергән бунтарь баласын!

Әйдә, энем, ташла фуражкаңны,
Төкер пиджагының өстенә,
Галстугы белән билең бу да
Бишмәтеңне киен өстеңә, –
Киттек!

Бүген бүлмәм өчен акча сорап,
Коммунхоздан килеп керделәр,
Акча таба алмагач, усал кешеләр
Квартирдан тотып сөрделәр...
Шулай, энем!
Монда акча кирәк,
Юкка гына йорттан кузгалдык,
Юкка гына шәһәр урамына
Чабатадан кереп югалдык.
Әйдә,
Егет, чишен аягыңны,
Төкер сандалына! –
Яланаяк кына кайтырбыз.
Авылыбызга кайткач:
– Шәһәрләрен яратмадык! –
Диеп әйтербез...
Их!
Шәһәр гудоклары, безне чакрып,
Көрәш таушы белән үкерсә,
Очкын атлар безгә ВКПның
Чакру әмрен тагын китерсә,
Без шәһәргә кире кайтырбыз!
Еллар!..
Авыр еллар,
Сезнең кулыгызда
Күрәчәкне бик күп күрдек без;
Буржуй халкы белән сугышып алдык,
Ертык чалбар киеп йөрдек без!
Әй, сез,
Килер кешеләр! –
Әле безнең хатыннарның
Каннарында аккан «түрәләр»,
Менә
Сезгә бабай булыр кешеләр
Шулай итеп газап күрәләр!
Белегез!
Сыйнфый көрәш тарихында беренче кат
Җиңүчеләр булып чыктык без,
Үзебез өчен дүрт кат чүкеч суксак,
Сезнең өчен биш кат суктык без!
Еллар үтәр,
Безнең аркабызда
Иркен, рәхәт көннәр күрерсез,
Бәлки, көнгә дүрт-биш сәгать эшләп,
Сигаралар тартып йөрерсез.
Ә без,
Һаман ертык чалбар киеп,
«Трезвон» тартып, постта калабыз!
Онытмагыз безне, карагыз!

Сезгә бәхет белән тәүфыйк теләп,
Сәлам яза Такташ бабагыз!..
Их!
Илебезнең чиге тар әле,
Анда соңгы көрәш бар әле!

Әйдә, энем,
Ташла фуражкаңны,
Төкер сандалыңның өстенә,
Галстугы белән билең бу да
Бишмәтеңне киен өстеңә, –
Киттек!
Җәен үсәр зәңгәр чәчәкләрнең
Җырын иштәм инде –
Яз килер:
Карлар эрер,
Бозлар китәрләр,
Тау битләре ачылыр,
Безнең кырда
Зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр.

## КЫР КАЗЛАРЫ

Кыр казлары бүген җылы яктан
Һава ярып, тезлеп үттеләр.
Алар миңа карап киттеләр...
– Кыр казлары, безнең урмандагы
Җылы күлгә барып төшегез,
Җәйгә анда мине көтегез...
Кайтсам, тирән күлнең ярларына,
Камышлыкка капкын куярмын;
Эләксәгез, тотып суярмын!..
Кыр казлары, зинһар, мактанмагыз,
Ерак түгел безнең арабыз,
Сез очсагыз, без дә калышмабыз,
Әле
Сезне узып оча алабыз.
Еллар үтәр – менә күрерсез:
Фәнне эшкә җигә белербез,
Күктә гүләйт итеп йөрербез!..

# КАРТАЙДЫМ ШУЛ

Яшьлек,
Зәңгәр урман,
Барып чыгар идем сиңа,
Кайтып китсәм килгән
юлымнан...

Картайдым шул, –
Еллар шулай итте,
Маңгай бөдрәләрен аклады,
Ләкин бунтарь йөрәк һаман әле
Яшьлектәге рухын саклады...
Күлдә йөзеп йөргән бакаларга
Хәзер дә әле ташлар ыргытам,
Үрдәк малайларын сөя-сөя,
Әле дә эшләремне онытам...

Их!
Ташла, мәзин дустым, манараңны,
Әйдә киттек балык тотарга,
Йомгакланып сулар агалар,
«Ком-корсаклар» анда кабалар...
Күңелсездер монда берүзеңә,
Мужикларың әнә килмиләр,
Килсәләр дә шунда – буш кул белән,
Намазны да рәтләп белмиләр...
Шулай инде,
Тормыш башка эздән ага...
Теге, ничек әле?
«Хисамилар» яши дөньяда?
Ә менә, бабай, – тар елгада гаҗәп балык каба.
Киттек мәллә икәү елгага?..

Авыл –
Һаман шулай катык ашый,
Һаман шулай –
Күлләрендә йөзә балыклар;
Дөнья җимреп әле дә җырлап йөри
Әтәч хатыны биби тавыклар...
Әнә кәкре аяклы ябь-яшь бала
Тәпи йөреп чыга урамга,
Кулындагы нечкә чыбык белән
Казлар куган була урамда...
Бәбкәләрен саклап, ак ана каз
Аңа таба килә, җилкенә,
Күп тә үтми, аунап җир өстенә,
Кала усал казның иркенә...

Их!
Минем дә бар иде, шуның кебек,
Күмер ашап үскән чакларым,
Тик кайтсам да хәзер монда тагын,
Яшьлек эзләремне тапмадым...
Яшьлек үткән инде...
Әйдә үтсен,
Сакал-мыек белән йөрербез,
Ләкин барыбер әле картайганчы

Яңа авылларны күрербез!
Агач сука йөргән яланнарда
Тимер тракторлар юргалар,
Елга буйларында балык эзләп
Чабып йөрер мәзин, муллалар...

Авыл,
Шул авылның мәчет тәрәзәсен
Яшьтә бәреп ваткан идем мин,
Әнкәйне елатып, Иман шартын
Тәмәкегә тарткан идем мин...
Хәзер
Зур үстем шул,
Урамнардан
Бик гакыллы булып үтәм мин,
Авыл картларына, зурлар кебек,
Сәлам биреп кенә китәм мин...
Карчыклар да мактый:
«Хәйрүк улы
Динле булып хәзер кайткан, ди,
Мәчет картларына:
«Алла сүзе – безнең сүз ул!» –
Диеп әйткән, ди...»
Ашыкмагыз әле мактарга сез,
Алла хакы өчен, көтегез;
Ячейкада бүген доклад укыр
Динле булып кайткан кешегез.
Авылым!
  Җырлыйм синең күкрәгеңдә,
  Гаҗәпләнмә минем җырыма,
  Кырын карап, кашың җыермачы
  Шәһәр киеме кигән улыңа...
  Шәһәр җырын җырлыйм, тыңлачы,
  Улың белән кушылып җырлачы:
  «Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
  Коллар һәм ачлар дөньясы...»

* * *

Әй җырлыйсы килә шушы җырны,
Бу җыр шундый якын күңелгә.
Җырланган җыр кебек, яшьлек таңы
Шаулап үтте,
Шаулап үтте инде гомергә!

– Пи-би-би-бип... –
Ди дә каз бәбкәсе,
Яхшатланып килгән, сөйләнә...
Каз бәбкәсе, белмим телеңне,
Шуңа бүлешә алмыйм сереңне...
Белсәм иде, мин дә, тыңлап сине,
Аунап ятыр идем чирәмдә.
Син дә, ашый-ашый, теләгәнчә
Сайрап йөрер идең тирәмдә...
Каз бәбкәсе, җаным, телең белмим,
Кем өйрәтте болай сөйләргә?
Гаҗәп матур сөйли беләсең...
Анаң – уңган каздыр, күрәсең...

Казлар көтеп үткән малай чагым
Күмлеп калды шушы урында...
Их!
Теләсәгез менә сүгенегез,
Тагын җырлыйм казлар турында...
– Каз канатлары ак була,
Ир канатлары ат була.
Малайларның төкреп йөргән чагы
Кыяр урлап йөргән чак була...

Кит лә, кояш!
Уйнап йөрмә монда,
Болай да бик кызу йөрәктә.
Тыңла әнә язгы сандугачны,
Ул да көлеп утыра тирәктә...

Алдадылар мине шәһәр халкы:
Эштән аерып алып киттеләр,
Анда баргач, шагыйрь иттеләр...
Хәзер...
Әгәр
Баскан эзем җирнең күкрәгендә
Югалмаслык уелып калса иде,
Җырлаган җырларым һаваларда
Утлар булып язылып барса иде,
Язып китәр идем киләчәктә
Шунда гомер итәр кешеләргә:
– Шагыйрь булмагыз сез,
Өйрәнегез
Җирне машинада эшләргә!..

Их!
Авыл кырын тутырып, бодай үсә,
Дулкынлатып аны, җил исә,
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә...

Гайшә кызы килә казлар куып,
Артта кала аксак бәбкәсе,

Бөглеп алган чакта бәбкәсен ул,
Шалтырап китә талир тәңкәсе...

Миңлениса чыккан, утын кисә,
Толымнарын селкеп, җил исә,
Кави, сиңа биреп җырларымны,
Калыйм мәллә монда югыйсә?
Инде монда мине хәзер
Тик бер генә нәрсә шатландыра.
Ул да:
Киләчәктә шушы кырларга
Тракторлар килер җырларга...
Тик бер генә нәрсә мине шатландыра:
Киләчәктә шушы урында
Нәни коммунарлар, ат көткәндә,
Җырлар җырлар минем турымда...

Бүген урам буйлап үткән чакта,
Очраттым мин аның бересен:
Ал галстук таккан, янар күзле,
Киләчәкнең тимер кешесен!..

* * *

Тамбов урманнарын ташлап китәм,
Нишлим? –
Шау-шуларга күңел чыныккан,
Давылларда туып канатланган
Бунтарь йөрәк кача тынлыктан...

Инде бу кырларда
Чикләнәлми минем теләгем,
Мәңгелеккә, беләм, мине моннан
Алып китә бунтарь йөрәгем!..
Сау булыгыз, кырлар,
Хәзер инде
Минем күңлем шәһәр кулында;
Бәлки, соңгы кабат шул урында,
Авылым! –
Уйлыйм синең киләчәгең,
Бәхетле көннәрең турында...
Киләчәктә синең урманыңны
Яман куллар урлап кисмәсләр,
Малайларың синең, безнең кебек,
Кыяр, шалкан урлап үсмәсләр...
Киләчәктә синең кәҗәләрең
Кеше бакчасына кермәсләр,
Тәүфыйкланыр инде этләрең дә, –
Чалбар төбен кабып өзмәсләр...
Парча суларың да, куермыйча,
Уймакланып ишелеп аксыннар,
Уңган киленнәрең бер-бер артлы
Алма кебек уллар тапсыннар!..
Авылым!
Инде синең урамыңда
Чикләнәлми минем теләгем,
Мәңгелеккә, беләм, синнән мине
Алып китәр бунтарь йөрәгем...

Соңгы сәлам сезгә, дус карчыклар,
Тиздән үләр сезнең күбегез,
Үлгән чакта, миңа тәүфыйк теләп,
Җан газабы күрми үлегез!..
Сау булыгыз инде,
Сау булыгыз,
Күрешмәбез, шаян этләрем,
Инде моннан соң сез, туры килсә,
Таламагыз шәһәр кешеләрен!..
Чөнки
Хәзер инде безнең законнарда
Андый эшләр бер дә ярамый,
Шәһәр этләре дә гакылланды, –
Борынгыдай,
Авыл халкын күрсә таламый...

Комсомоллар!
Минем күз карашым
Соң мәртәбә сезгә тегәлгән,
Авылыбызны Ленин юлы белән
Чыгарыгыз тормыш төбеннән...

## ХӘНИФӘ ТАКТАШЕВАГА

Болай безнең йортка бертөрле дә
Алпавытлар килеп йөрмәгән.
Тирә-күршеләр дә анабызны
Азгын хатын диеп белмәгән.
Ә шулай да синең башка атадан
Булуыңны монда белгәннәр, –
Стенага эре хәреф белән
«Дворян кызы» диеп элгәннәр...
«Өй эчендә булган күп сереңне
Күршең сөйләгәннән беләсең».
Әнкәй,
Әткәйне алдап, алпавытлар белән
Гуляйт итеп йөргән, күрәсең!..

*

Күз яшь түкмә, – йә!
Без әнкәйнең
Саф булуын аклый алырбыз,
Син дә,
«Алпыт кызы» түгел,
Сукачы карт
Хәйрүк кызы булып калырсың!!!

## ҖЫРЛАНАЧАК ҖЫРЛАР ТУРЫНДА

Авыл... җырчың синнән
Бөтенләйгә китәм ди...
...Кырларыңда, авыл, большевикча
Хисләр үссә дә,
Кем урыр соң, бар да шулай
Ташлап китсәләр?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
...Арт урамда берәү
Авыр башын салган цементка,
Ул эчмәгән үзе, ләкин аны
Җырланмаган хисләр исерткән...

*Х.Туфан. «Җырланмаган җырлар турында».*

*(«Безнең юл», № 10)*

Туфан!
Таш урамда башын салган егет
Синең тиргәвеңне ишетте.
Әйе,
Аны әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр исертте!..
Бөек җиңү алып килгән хисләр
Сыеша алмый таша күңелдә.
Әйтче,
Кайсын шунда җырлап бетереп була
Безгә тигән кыска гомердә?
Һәрбер фронт безгә зур көрәштә
Тиңсез җиңү алып китерсә,
Һәрбер җиңү алып килгән хисләр
Үзе белән безне исертә...
Ә җырлаучы кайда шул хисләрне?
«Җырчы» урыны көтә иясен.
Бөек еллар җырда үз Ленинын
Тудыралмый калды, күрәсең...
Маңгай бөдрәләрем туздырып, мин
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм, Туфан,
Әле җырланмаган,
Җырланачак
Хисләр турында...
Ташлап киттем Тамбов урманнарын,
Нишлим? –
Шау-шуларга йөрәк чыныккан,
  Давылларда туып канатланган
  Бунтарь йөрәк качты тынлыктан.
  Хәзер инде Тамбов урманнары
  Төшкә генә минем кererләр,
  Ләкин
  Дус агайлар минем җырларымда
  Мәңге шәүлә булып йөрерләр...
  «Әүхәди»не минем җырларымда
  Әле, Туфан, бик күп күрерсез,
  Минем белән әле киң кырларда
  Бик күп атлар көтеп йөрерсез...
  Ләкин бүген менә «арт урамнан»

«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм
Җырланмаган, –
Киләчәктә
Бер җырланыр җырлар турында.

* * *

Туасы таңнарның кояшына
Мактау җырлап, елны башлыйбыз,
Без елларга табан атлыйбыз!
Ел артыннан туган елга табан
Күчәр безнең көчле нәселләр.
Эх!
Тугыз еллык бәйрәм бәйрәммени, –
Алда көтә безне гасырлар!..

*

Мин дә әле менә ул үстерәм.
Үлеп-нитеп калсам, ул калыр.
Октябрьнең илле еллыгында,
Меңнәр белән басып бер аякка,
Шул мәйданга килеп тукталыр!
Тугыз еллык бәйрәм көне бүген,
Егермесе аның тиз килер.
Безнең тавыш еллар күкрәгенә
Һаман шулай күкрәп иштелер!

## *1927*

### БҮГЕНГЕ МАТУРЛЫК

– Бүгенге көндә нинди матурлык бар? – диләр.
*«Сөйләүчеләр» авызы*

Дөнья матур,
Шуның өчен дә шул
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан;
Ә җил, сыбызгыны, ни өчендер
Ияргән дә килә артымнан...
Тфү!
Кышкы җилләр тиде теңкәгә!..
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Җил иркендә калды урамнар;
Ә җил, морҗа сандугачы,
Эче пошкан саен
Алып килер салкын бураннар...
Буран алып килер,
Карлар ташыр,
Аннан тотыныр карлар өяргә.
Да,
Бу дөньяның салкын кышында да
Кызык табыла «безнең җүләргә»...

*

«Барабыз»га утрып, теләгән җиргә
Кошлар кебек очып барабыз,
Кояш – безгә иптәш,
Җил – дус кеше,
Ә җир инде – безнең анабыз...
Рәхмәт, әнкәй, сиңа:
Ярый әле мине тапкансың,
Җырлар җырлый-җырлый,
«Иркәм!» диеп,
Төннәр йокламыйча баккансың...
Синең авыр кара тормышыңда
Ярдәмчең булмадым булуын,
Ләкин
Авыр көрәш, бөек еллар өчен
Кирәк булган минем тууым! –
Кан исләре исеп килгән саен,
Мәгърур бер уй уйный йөрәктә:
Солдат булырмын, дим, бәлки, тиздән
Ил чигендә булып көрәштә...

*

Дөнья матур,
Шушы дөньяның мин –
Ирке чикләнмәгән юлчысы,
Давыллы елларның, зур көрәшнең
Матурлыгын җырлар җырчысы...
Кичәге матурлык бүген үлсә,

Иртән туа аның яңасы;
Безнең тупас куллар – киләчәктә
Туар матурлыкның анасы...
Бүгенге матурлык тупас, ертык
Көрәш киеме белән ябынган;
Бүгенгенең данлы матурлыгын
Безнең йөрәк эзли давылдан...
Кан исләре исеп килгән саен,
Мәгърур бер уй уйный йөрәктә:
Солдат булырбыз без, бәлки, тиздән
Ил чигендә булып көрәштә!

## МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ

Яшьлек,
Гомрең кыска синең,
Шундый кыска булып тоела,
Кичен чәчәк аткан була,
Ә таңында инде коела...
Мәхәббәт
Ул – үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гомрен бирә
Аның хисе белән янарга...
Янган яшьлек,
Үткән мәхәббәтләр –
Алар мәңге миндә терелмәс,
Күзләрем дә хәзер беркемгә дә
Гыйшык уты эзләп тегәлмәс.
Инде...
Тәүбә иттем ул эшләрдән,
Азгын күңел күпкә басылды,
Ирке чикләнмәгән йөрәгемә
Башлык итеп куйдым гакылны.
Гакыл башлык булган көннән алып
Көн-төн елый мескен йөрәгем;
Һәр көн ызгыш, һәр көн йөрәгемә
Гакыл-башлык бирә кирәген...
Их син, яшьлек,
Их син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чәчәк аткан булдың,
Ә таңында...
Ә таңында инде коелдың...
Язгы сандугачлы яшьлек таңым
Үтте инде...
Онтылдылар бик күп исемнәр,
Инде яшьләр хәзер яратсыннар,
Инде яшьләр хәзер сөйсеннәр...
Ә мин...
Ә мин үзем бөтенләйгә
Тәүбә иттем андый эшләрдән,
Читтән генә хәзер көлеп йөрим
«Гыйшык!»
Диеп йөргән кешеләрдән...
Шулай да әле, кызлар,
Алла хакы өчен,
Миннән бераз читтә йөрегез,
Йә тәүбәне шунда боздырырсыз,
Гыйшык итеп куеп берегез!..
Юк шул,
Гыйшкым хәзер иясенә
Кире алынмаска бирелгән,
«Аның» рәсмен беркем бервакытта
Ала алмас минем күңелдән...
Шуның өчен тыныч күңел белән
Туктап менә шушы урында,
Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка
Булган көчле гыйшкы турында...

### I. Зөбәйдәнең рәсме

Кайчак шулай бер-бер иптәшеңдә
Утрып сөйләшер сүз тапмыйсың,
Өстәленнән альбом кебеген алып,
Рәсемнәрен мактый башлыйсың...
Шулай ялкау гына сөйләнгәндә,
Күзләр бер рәсемгә туктала,
Кара болыт кебек тузган чәчләр
Хыялыңа кереп чормала...
– Бу кем? – дисең,
Ә ул, көлеп кенә:
– Бу, – ди, – хәзер бала анасы,
Матур иде, яшьли иргә чыкты,
Хәзер инде алты баласы... –
Ди ул,
Ә син алданганың
Белдермәскә теләп тынасың.
Ә бераздан:
– Алай икән... –
Дигән булып,
Альбом битен ябып куясың.
Матурлык ул шулай:
Кызда булса,
Җыерчыклы йөзгә әйләнә,
Ирдә булса,
Аның матурлыгы
Сакал-мыек белән бәйләнә...
Мәхәббәт тә –
Нәфис матур чәчәк,
Ләкин
Үзе гаҗәп гомерсез,
Кайчак загс белән соңы бетә,
Ә кайчакта...
Яхшук күңелсез...
Зөбәйдәнең рәсме –
Альбомымның
Күзгә бәрелеп торган урнында,
Альбомымны карап чыккан кешеләр
Һаман сорый аның турында:
– Бу кем? – диләр,
Ә мин җавап бирәм:
– Матур кыз, – дим, –
Булган комсомолка,
Бөтен кешене үзенә карата,
Ә син, егет,
Бераз кичектең шул –
Ул бер наборщикны ярата...

**II. Зөбәйдәнең гыйшкы**

Сандугачлы таңнар,
Зур урманнар
Аның гыйшкын бизи алмады,
Язгы зәңгәр күкнең йолдызлары
Матурланып күктә янмады...

Аның гыйшкы көзен чәчәк атты
Эштә,
Собраниедә,
Урамда.
Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны,
Шундый якын бу җыр күңелгә,
Җырланган җыр кебек, яшьлек таңым
Шаулап үтте...
Шаулап үтте инде гомергә...
Их!
– Зөбәйдә, бар бүген собраниегә,
Анда аның бүген докладың;
Ул елмаер сиңа тагын да,
Затып килер кайткан чагыңда...
– Зөбәйдә, бар бүген театрга,
Бәлки, анда аны күрерсең,
Аның белән залда йөрерсең...
– Зөбәйдә, син барма театрга,
Йөрмә, бәгърем, аның артыннан...
Саклана күр егет халкыннан...

Ашкынулы көннәр шулай үткән,
Минутлардан эзләр калмаган;
Яшьлек үзенең җылы кочагында
Зөбәйдәне һаман алдаган...
Ә беркөнне...
Аны наборщигы
Кунак итеп үзенә китергән,
Алар бергә утырганнар...
Соңыннан
Бүлмә уты сүнгән,
Алар икәү
Төнге караңгыда калганнар...
Төн караңгы булган...
Төн буенча
Ап-ак карлар җиргә яуганнар...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ул төнне ай, күктә эш тапмыйча,
Эче пошып сүгенеп йөрегән,
Ул төнне Әүхәди, юлга чыгып,
Кире кайткан куркып бүредән...
Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,
Тәмле йокысыннан тормаган,
Шәкүр карак аның абзарыннан
Күк айгырын кереп урлаган...
Ләкин
Шушы төнне Зөбәйдәнең

Кайдалыгын беркем белмәгән,
Карт анасы ярты төнгә кадәр
Ни өчендер аны эзләгән...
Тик
Мәхмүт торган йортта
Бер студент
Ябылмыйча калган ишектән
Зөбәйдәнең
«Мәхмүт, бәгърем, җибәр!» дигән
Ярты елау таушын ишеткән...

Айлар үткән...
Тәңкә карлар ява,
Ап-ак карлар;
Ә Зөбәйдә эшкә бармады,
Керфекләре җиргә карый анның,
Наборщигы аны алдады...

### III. Зөбәйдәнең хаты

«...Алдарсың дип сине белмәдем;
Вәгъдә бирдең,
Өзелеп көттем сине...
Ә син?..
Нигә инде шулай килмәдең?
Тагын язам,
Сиңа бер сүзем бар,
Бик кирәкле... кичкә кил әйдә.
Килерсеңме?
Көтәм.
Ком. сәламе белән: Зөбәйдә...»

Ләкин ул килмәде.
Аңа нәрсә,
Эшлисе эш күптән эшләнгән,
Алма кебек матур Зөбәйдәбез
Үзе сөйгән, үзе...
Көчләнгән...

### IV. Хатынсыз ай

Ә ай күктә һаман сүгнеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк,
Ай – ялгыз ул,
Төн үткәрсен соң ул кем белән...
Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төндә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли...
Ә ай көлә,
Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә,

Өйләналмый калган,
Шуның өчен
Кайгы нуры күренә йөзендә...
Зөбәйдәнең әние күлмәк тегә,
Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен;
Зөбәйдәнең сеңле уйнап йөри,
Абау матур!
Күзем тимәсен...

### V. Зөбәйдә һәм ай

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды,
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен
Канлы яшьләр белән тутырды...
– Их син, яшьлек,
Их син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чәчәк аткан булдың,
Ә таңында...
Ә таңында инде коелдың...
Зөбәйдә...
Ул тиздән ана булыр,
Доктор шулай дигән аңарга...
– Йөрәк,
Ян син, ян син, йөрәк, –
Кан бирелгән сиңа янарга!..
Ә син кайда, ата булыр кеше?
Шулмы булды синең сөюең,
Шулмы инде синең
Ирекле сөю,
Яңа тормыш диеп йөрүең?..
Кичтә янган утлар таңда сүнсә,
Кичен тагын алар кабына...
Зөбәйдәбез бүген бала көтә,
Үзе наборщигын сагына...
Менә баласына күлмәк тегә,
Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен...
Зөбәйдә!
Әйт, кемне болай,
Кемне болай сагнып көтәсең?

### VI. Ачулы җил

Урам буйлап җил бер исрек белән
Гүләйт итеп кайтып килә иде...
Ә Ибәй карт,
Юньсез,

Көрәк тотып,
Йорт алдында карлар өя иде.
– Бу ни хәл бу? – диде җил күрде дә,
Нәрсә дисең инде кешеләргә,
Ачу килә
Шундый эшне күреп,
Кулым күтәрелми эшләргә! –
Мин тау өеп китәм,
Ә кешеләр
Чыгалар да шуны көриләр;
Мин матурлыйм,
Алар чыгып таптап йөриләр...
«Тфү!» –
Диде,
Үзе зур урамнан
Эре-эре кырга атлады;
Ачу итеп кырдан карлар ташып,
Бөтен урамнарны каплады...
Таң булуга, урам көрәүчеләр
Җилнең бабаларын сүктеләр...
Ә шул төнне безнең Зөбәйдәне
Больницага алып киттеләр.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кайда син, әй, ата булыр кеше,
Шулмы инде синең сөюең?
Шулмы инде синең Зөбәйдәгә:
– Комсомолкам, бәгърем! – диюең?

### VII. Мәхәббәтнең соңы

Кан эчендә яткан Зөбәйдәне
Ак мендәргә китреп салганнар:
Күз төпләре күм-күк,
Иреннәре
Кара күмер булып янганнар...
Ул селкенми ята,
Аны әллә нәрсә
Басып торган кебек сизелә...
«Тукта, елау таушы килә,
Бала елый...
Кемнең баласы?
Ник ул елый?.. Ә ник мендәреннән
Башын күтәралмый анасы?..
Тукта...
Нигә авыр болай?
Әллә нәрсә...
Күз аллары шундый караңгы...»
Ул кузгалды,
Кинәт авыр гына:
«Күрсәтегез, – диде, – баламны!»
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ана –
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга!
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда...

Бала елый,
Матур йорт эчендә
Яшь бер бала елый, –
Кемнең баласы?
Ник ул елый?
Ә ник күрер өчен
Килми аның сөйгән атасы?..
Тышта соңгы карлар ява,
Алар инде
Кышкы карлар кебек туңмыйлар.
Тышта язгы җилләр исә,
Алар инде салкын булмыйлар...
Карлар эрер,
Җылы тиргә батып,
Кар астыннан чыгар май ае;
Ә урамда, язның килерен белми,
Елап утыра песи малае...
– Елама юкка,
Дөнья – матур нәрсә,
Әйдә, миндә кунак булырсың,
Дуслыгымны аңлап алдашмасаң,
Урлашмасаң, миндә торырсың...
Анаң, тәүфыйксызны, ташлап киткән,
Атаң, явыз, сине белми дә.
Кардәшләрең дә юк,
Шәһәр шул бу,
Белмисеңдер монда кемне дә.
Шулай, дустым!
Сезнең песи халкы
Балаларын ташлап китәләр;
Песи халкы гына түгел,
Этләр, аюлар да,
Кешеләр дә шулай итәләр...
Ярый әле сезнең песи малайлары,
Ни булса да, тере туалар,
Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.
Әйдә киттек!
Минем яшь чагымда
Песиләрдән дуслар күп иде,
Син дә шулай кунак булырсың,
Язга кадәр миндә торырсың.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Бала елый,
Матур йорт эчендә
Яшь бер бала елый...
Кемнең баласы?
Ник ул елый?
Ә ник күрер өчен
Килми аның сөйгән атасы?..
– Атасы аның, бәлки, мәңге килмәс,
Улын, бәлки, мәңге күралмас...
Улы үсәр, җитез, матур булыр...
А, юк!
Ата күңле күрми түзалмас!
Тукта!
Ишек ачлып, берәү әкрен генә
Зөбәйдәгә таба атлады;
Күз яшьләре җиңде аны,
Кинәт борылды да
Йөзен кулы белән каплады:
– Зөбәйдә, син кичер мине! – диде,
Үзе Зөбәйдәнең
Күкрәгенә килеп ташланды...

Алар килештеләр...
Ә биш көннән
Загс белән тормыш башланды...

Ә ай күктә һаман сүгнеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк, улы да юк,
Төн үткәрсен соң ул кем белән?..
Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төнлә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли.
Ә ай көлә,
Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә;
Өйләналмый калган, шуның өчен
Кайгы нуры күрнә йөзендә...

## МӘСКӘҮ – ЛОНДОН СӨЙЛӘШӘ

*(Демьян Бедныйдан)*

Лондон

Нинди хәбәрләр бар анда сездә,
Карлар эреп, җирләр киптеме?
Бессарабия шулай кулыгыздан
Бөтенләйгә инде киттеме?

Мәскәү

Бездә, мистер, эшләр әйбәт хәзер,
Матурланып килә һавалар!
Ә соң сездә?
Шанхай тирәсеннән
Ни дип әле сезгә язалар?..

## КАМАЛИ КАРТ БЕЛӘН УЛЫ ӘХМӘТ

Әхмәт әле – яшь бала,
Дөнья бик кызык аңа;
Атасы нәрсә эшләсә,
Шуңардан үрнәк ала.

Атасына ярагачтын,
Ник Әхмәткә тартмаска,
Йомыркага бер пачканы
Нигә алып кайтмаска!

Әхмәт алып кайтты да,
Саламлыкка ятты да,
Чукмар кадәр тәмәкене
Авызына капты да –

Бер-ике кат тартып алып,
Кире җиргә ташлады...
Күп үтмәде – бөтен авыл
Кызып яна башлады.

Шундый хәлләр булмасын дип,
Алдан чара күрегез;
Ясле ачып, балагызны
Шул яслегә бирегез!

## ИБРАЙ АГАЙ ҺӘМ АНЫҢ УЛЫ ЗӨБӘЙ

Зөбәй әле – яшь бала,
Дөнья бик матур аңа;
Атасы нәрсә эшләсә,
Шуңардан үрнәк ала.

Көн дә, миңа газет бир, дип
Тавышлана, талаша, –
Үзе укый белмәсә дә,
Газет укып маташа.

Иптәшләрен җыеп килеп,
Рәсем ясап уйныйлар;
Газет-журнал, китап битен
Буямыйча куймыйлар.

Яз килүгә, әниләре
Яслегә аны бирделәр,
Үзләре, тынычланып,
Кырда эшләп йөрделәр.

* * *

Милли армиянең баш командиры
Чан Кай-ши революциягә хыянәт итте.

*Хәбәрләрдән*

Ояты юк сатлык юлбасарның,
Бүген менә йөзе ачылды.
Бәясез мал – түбән, пычрак хайван
Кытай байларына сатылды.
Ләкин... килер бер көн, ирексез Кытай йорты
Совет иле булып әйләнер;
Кара бандит, сатлык Чан Кай-шилар
Үлем дарларына бәйләнер.

## ҮПКӘЛИМ

Октябрьгә менә ун ел тула,
Бер сайлаудан үзем калмадым,
Ләкин
Күңел өчен генә дә бер
Нарком булып үтә алмадым.
Нишлисең бит,
        Күңел – шайтан, диләр,
Кайчак шулай күпкә киткәли.
Татарстан!
Синең ирекле җырчың
Бүген менә сиңа үпкәли...
Ни булса да инде дөресен әйтим,
Теләгемне аңламадыгыз,
Сайлау булды,
Көттем...
Инде бу юлы да
Нарком итеп сайламадыгыз!..
Ни була иде инде тик бер көнгә
Совнаркомны миңа бирсәгез
Яки уйнап кына шунда
Күңел өчен:
– Нарком Такташ! –
Диеп йөрсәгез.
Инде калдым тагын атсыз гына
Казан урамында чабарга,
Нарком аты үтеп киткән саен
(Басмасын дип),
Читтән генә куркып карарга...

## КАЗАН УРАМЫ КҮРЕНЕШЛӘРЕННӘН...

*(«Барабыз»чы чанасы, арба өстенә менеп атланган да сөйләнеп бара)*

[...] рәтсез кешеләр ташып,
Өстерәлдем бик күп юлларда.
Кабыргалар сынып бетә язды,
Эләгеп куеп яман кулларга.
Әйдә, җаным, арба, авырсынма,
Авыр кала сиңа калуын.
Ләкин
Ни булса да инде туктатмыек
Бу дөньяның алга баруын...
Безнең гомер алмаш-тилмәш килә,
Мине куеп, сине җигәләр.
Кыска гына итеп әйткән чакта,
Җилкәбездә рәхәт чигәләр.

*

Кеше дигән нәрсә – кызык хайван,
Утыра да йөри өстеңә.
Ә бит
Кирәгеңне бирер иде,

Менеп төшсәң үзе өстенә.
Әле кышын шундый бер хәл булды
(«Барабызчы» булып йөргәндә),
Сукунныйга барып кайтыр өчен
Бәйләнә бит берәү килгән дә.
Үзе үгез кадәр,
Менә калса,
Бер кабыргаң калмас урнында.
Карыйм, сәүдәләшә.
Мыштым гына
Уйлап-уйлап шунда тордым да,
Тукта! димен, утырып баксын әле,
Күргәзием моңа кемлекне.
Ул утырды.
Киттек.
Бахбай, хайван,
Таудан төшкән чакта сөрлекте.
Ә мин, шул вакыттан файдаланып,
Тау астына таба юнәлдем.
Теге «ә» дияргә өлгермәде,
Шундый, малай, атып җибәрдем...
Торалмыйча ятты...

*

Шулай, дустым,
Рәтсез кешеләр ташып,
Өстерәлдем бик күп юлларда...
Кабыргалар сынып бетә язды,
Эләгеп куеп яман кулларга.

**ҖЫРЫМ СИҢА БУЛСЫН**

Анаң мескен сине, тудырганда,
Яхшы ният белән тудырган,
Ләкин
Үкенгәндер үзе соңыннан...
Әйтче, кызый!
Болай киенергә
Нинди шайтан сине өйрәтте?
Инде
Тездән узган күлмәк итәкләрен
Ертык ясау нигә кирәкте?
Сез, хатыннар, үзегез «иптәш» дисез,
Үзегез
Иптәшлектән качасыз;
Кызлыгыгыз күрнеп торсын өчен,
Күлмәгегезне
Тезегездән ашып ачасыз.
Алай булгач, инде бер башлагач,
Ярты юлда туктап калмагыз,
Кызык булыр безгә карар өчен,
Күлмәк дигәнен дә салсагыз!
Их сез,

«Иптәш» кешеләр!
Ә соң ничек булыр
Теге – сезнең
«Ирләр көчли» дигән сүзегез?
Көлеп әйтмим,
Болай киенеп,
Сез көчлисез безне үзегез!
– Җырым сиңа булсын,
Яшьлегемне
Үзем теләп бирәм кулыңа;
Ләкин тыңла мине:
Иптәш тә бул миңа,
Ана да бул минем улыма!
Ак каеннар,
Матур булыр өчен,
Яз килүгә яфрак яралар;
Ә хатыннар, белмим, ни өчендер
Каеннарга каршы баралар...
Яз җиттеме –
бетте,
Теләсәң нишлә,
Алар үзләренчә башлыйлар:
Кояш көләргә дә өлгералмый –
Баштанаяк чишенеп ташлыйлар.
Бүгеннән соң «кыска күлмәк» дигән сүзне
Авызыңнан җилләр урласын...
Җырым сиңа булсын,
Яшьлек хисләремне сиңа бирәм,
Якты уйлар булсын юлдашың...

## ЛОРД ЧЕМБЕРЛЕНГА СССР КРЕСТЬЯНЫ ҺАДИ ТАКТАШТАН ҖАВАП НОТАСЫ

Син, Чемберлен агай, карап торам:
Безнең ишене ишкә куймыйсың;
Аркосны да кереп карап чыктың,
Үзең болай
Куркытканмын диеп уйлыйсың.
Карап-карап сиңа торамын да
Тагын карап алам үзеңә:
Килеш-килбәтең дә әйбәт бугай,
Монокль дә килешә күзеңә,
Ләкин...
Менә «ләкин» сүзе белән
Күп вакытта башны җуялар,
Матур гына мактап киләләр дә
Иң ахырда
«Ләкин»
Сүзен кыстырып куялар.
Синең дә әле менә ноталарны
Һәр кояшлы көнне алабыз;
Ләкин...
«Ләкин» дибез дә шул,
Башны гына селкеп калабыз.
Әйтче, зинһар, кайдан шулкадәрле
Төрле хатлар кулга эләсең?
Коминтерн дигән нәрсәсе дә

Тыныч бирми үзеңә, күрәсең.
Мин нотамны сиңа «җәнаб гали»,
«Фәлән-төгән»... диеп башламыйм, –
Мужик булып язам...
Йөрәктә дә
Англиягә ачу сакламыйм.
Шулай булгач, инде, дус кешеләрчә,
Турыдан-туры эшкә күчиек:
Нота бик күп яздың,
Инде
Ультиматум дигәнеңне кайчан көтиек?
Их син, шайтан борын,
Кызып киттең соңгы көннәрдә;
Йокың качкан бугай,
Шулайдыр шул,
Бөркү була кайбер төннәрдә.
Үзем теләп унбер тәңкә бирер
«Чемберленга җавап» фондына,
Нота язам янган йөрәк белән
Англиянең мәгърур лордына.
«Сиңа җавап фонды» миллионнарның
Берәр тиененнән җыелыр,
Сиңа каршы булган аэропланнар
Гади алюминнан коелыр.
Ләкин...
Шул тиеннәр биргән миллионнарны,
Сугыш ачсаң,
            сугыш сафында
Очратырсың әле тагын да!
Гаскәрләрең көчле,
Тик шулай да
Ул гаскәрләр безне җиңалмас!
Сөңгеләрең үткен,
Ләкин бел син:
Алар безгә каршы юнәлмәс!

**ОНЫТЫЛГАН ТӘБРИК**

Ике меңне тутыргансың, «Кызыл Татарстан»,
Ә мин
Бүген генә аны ишеттем;
Дөнья куып, бәгърем, йөри-йөри,
Тәбрикләргә сине кичектем!..
Сәлам булсын сиңа!
Ак битләрең
Тыгыз юллар белән каралсын;
Һәрбер битең тарих булып калсын,
Исемең эшче илдә дан алсын!

Айга күптән инде миллион тулган,
Ә ул үзе аны оныткан...
Бүген саташкан ай, кыш дип белеп,
Төн уздырган күктә толыптан.
Ай кебек син ялгыз читтә калма,
Битләреңә
Миллионнарның бәйлә йөрәген,
Миллион күзләр синең биттә йөрсен –
Шушы минем сиңа теләгем!

## ЛӘЙЛӘ

Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак карга киенгән;
Ләйлә чанасын өстерәп
Чыгып китте өеннән.

Йомшак ап-ак кар өстендә,
Эх, уйнавы күңелле...
Чү! Урамнан кемнәр килә,
Пионерлар түгелме?

Ал байракларын күтәреп,
Менә алар җитәләр;
Пионерлар, комсомоллар
Бергә җырлап үтәләр.

Берсе әнә Чемберленның
Рәсмен күтәреп үтә,
Чемберлены, абау кызык,
Йодырыгын селкетә.

Ләйлә, курчакларга карап,
Бик кычкырып бер көлде...
Урам буйлап кичкә кадәр
Чанасын тартып йөрде.

Биш ел үтәр, Ләйлә, син дә
Үсеп буйга җитәрсең.
Октябрьнең унбиш елын
Пионерда итәрсең.

## ТАГЫН КАЗЛАР ТУРЫНДА

Ленинград портыннан Германиягә
15 мең тере каз җибәрелде.

*ТАСС*

Тәүфыйксызлык белән гомер узды,
Рәтле кеше булып булмады;
Татарстан «мактап» җырчы асрады,
Ләкин
Уңмады.
Яфрак ярып, матур бөдрәләндем,
Тик елмаеп гөлли алмадым...
Мин сезне дә,
Үземне дә бик нык алдадым...
Соңгы җырым булсын!
(Тәүбә-тәүбә!)
Инде башка җырчы табыгыз,
Ә мин тәүфыйксызны тотыгыз да
Чемберленның үзенә озатыгыз!
Чөнки
Гомер буе рәтләп эшләмәдем,
«Казлар җырлап, гомер уздырдым»,
Зәңгәр яшьлегемне –
яшьлегемне
«Әрәм иттем –
Җилгә туздырдым»...
............
............
Ә бит минем кебек әйбәт кешеләр
Бик күп шулай гүләйт иттеләр:
Әз-мәз генә биллиард уйнадылар,
Бик күп трест башына җиттеләр...
Булган эшләр булды,
Ярый инде,
Ул турыда башка җырымда;
Бүген менә җырлыйм Европага
Озатылган казлар турында.

«Бәбкә ак казларның канатларын
Көзге җилләр исеп каера;
Адәмне генә түгел, казларны да
Еллар үз иленнән аера»...
Их!
Еллар сезне, дуслар, мәңгелеккә
Совет илләреннән аера...
Яшь чагында бабай казларыгыз
Дошман күрде мине күрүен,
Кайда эләксәм, шунда сезнең нәсел
Кирәгемне бирде бирүен,
Ләкин...
Еллар үтте,
Бар да онтылдылар.
Еллар алар шулай үтәләр...
Бүген менә сезне, гүя дусларымны,
Чит илләргә алып китәләр.
Сау булыгыз!
Сезне усал илгә,

Буржуйларга алып баралар...
Ләкин кайгырмагыз, –
Игелеген күрер ирекле илдә
Сездән калган бәбкә-балалар!..
Сезне сату белән, чит илләрдән
Тракторлар алып кайтырбыз,
Сезнең туып үскән ирекле илне
Тары, ясмыкларга баетырбыз!
Сездән калган бәбкә-балалар да
Майларына түзми биерләр,
– Рәхмәт төшсен безнең бабайларга,
Пи-би-би-бип,
Совет яклы булган, – диерләр.
Сау булыгыз, яшьлек иптәшләрем,
Сезне инде
Буржуйларга алып баралар;
Ләкин кайгырмагыз, –
Игелеген күрер ирекле илдә
Сездән калган бәбкә-балалар!..

## СИГНАЛЧЫ КЫЗЫЛ ГАСКӘР ҖЫРЫ

Республика чиге тыныч түгел,
Кузгалыгыз,
Дошман безгә каршы ут ача...
Тратта... та... та... та... та... та...
Планетаның төрле җирендәге,
Коминтерн куйган посттагы
Часовойлар!
Сезгә!
Ишетегез!
Ленин – большевиклар штабы
Сигнал бирә:
Совет чикләрендә
Ач шакаллар йөри төнката,
Дошман безгә каршы көчен җыйный,
Тратта... та... та... та... та... та...
Фашистларның кара штаблары
Үлем сөремен җиргә әзерли.
Коминтерн куйган часовойлар,
Сез бу атакага әзерме? –
Һәр минутта,
Һәрбер кара төндә,
Постларыгызда уяу торыгыз!
Безгә каршы чыккан крейсерларның
Борыннарын кире борыгыз!
Капиталга үлем алып килгән
Көн билгесе булып таң ата;
Тиздән көрәш,
Тиздән атака...
Тратта... та... та... та... та... та...

**БЕЗ СЫНЫЙБЫЗ КӨЧЕБЕЗНЕ**

Кызыл көрәшчеләр, сәлам белән
Мин хатымны сезгә башлыймын;
Зур бурычлар тора алгы көндә,
Шул турыда язып ташлыймын.

Совет иле – җирдә бердәнбер ил;
Башка җирдә
Теге зур корсак кешеләр торалар,
Алар көне-төне безнең илне
Җимерү өчен план коралар.

«Коминтерн-фәлән язган» диеп,
Әллә кайдан хатлар табалар,
Колак ишетмәгән, күз күрмәгән
Ялганнарны безгә тагалар.

Буржуйларга безне бетерү кирәк,
Сугыш кирәк буржуй халкына,
Базар кирәк,
Безнең ирекле илне
Алу кирәк тырнак астына.

Ансы булмас!
Без сугышны үзебез теләмибез,
Була икән,
Каршы тору юлын белербез,
Фронтларга көчле – җимрелмәслек
Корыч колонналар бирербез.

Ләкин дошман көчсез түгел,
Бүрек белән
Егып булмас аның көчләрен;
Күзне йомып аткан ядрә белән
Коеп булмас аның тешләрен.

Дөрес,
Буржуйларда булган танклар
Бездә дә бар барын; шулай да
Эшкә салкын карап, өйрәнмәсәк,
Эшләр барып чыкмас уңайга.
Без сугышны үзебез теләмибез,
Без тынычлык җирдә телибез;
Без, беренче, җирдә
Бөек, тигез
Социализм илен төзибез.

Шушы илне тыныч саклау өчен,
Авырлыкка-нигә карамый,
Өйрәнергә кирәк.

– Әй, без болай да
Җиңәрбез! – дип тору ярамый.

Сез, дусларым, менә маневрда
Көчегезне инде сынагыз,
Без үзебез сездән,
Бурычларын
Үтәрләр, дип көтеп торабыз.

Авыр булыр,
Төннәр йокламагыз,
Ләкин сынатмагыз, карагыз!
Сезгә уңыш теләп, иптәшләрчә
Сәлам яза
Такташ агагыз.

## ӨЙРӘНЕГЕЗ

Исәннәрме, кызыл көрәшчеләр,
Без үзебез
Сау-сәламәт монда калабыз,
Сезгә менә тагын хатлар яза
Күпне күргән Такташ бабагыз.
Инде карт кешенең биргән киңәшләрен
Өстән генә укып үтмәгез, –
Күңлегезгә алып бикләгез!
Маневрга менә чыгу белән,
Һавалар да бозылып киттеләр,
Болытлар да,
«Бераз кирәкләрен бирик» диеп,
Әллә кайдан килеп җиттеләр.
«Кайнар ашсыз, яңгыр эчендә» дип,
Борныгызны салып йөрмәгез,
Өстегезгә төшкән бурычларны
Егетләрчә барын эшләгез.
Авырлыкка хәзер өйрәнегез,
Чын сугышлар булган чагында,
Якты уйлар юлдаш булсын сезгә,
Авыррак булыр тагын да.
Мин, карт кеше, шуны телимен,
Карт булсам да, әле җаным түзми,
Сезнең эшне карап йөримен.
Кайбер иптәш кешеләр маневрга
Өстән генә көлеп карыйлар,
Яшеренергә кирәк чакта
Яшеренмиләр,
Уен итеп кенә саныйлар.
Дөрес,
Маневрлар уен кебек,
Ләкин алар –
Зур җиңүгә бару юллары,
Көчне сынау бара,
Көчегезне
Күрсәтегез, совет уллары!
Сугыш серен инде, балакайлар,
Кара, беркемгә дә ачмагыз;
Күзегезне саклап тоткан кебек,
Ул серне дә шулай саклагыз.
Һәрбер эштә, һәрбер хәрәкәттә
Командирдан үрнәк алыгыз;
Ул ни кушса, шуны эшләгез сез,
Кая кушса, шунда барыгыз!

## ҮЗЛӘРЕ КЕШЕ КЕБЕКЛӘР, КАРАСАҢ – КӨЗГЕ ЧЕБЕШЛӘР

Колак булдымы инде – хәбәр була,
Тыңла гына,
Бер-ике сүз мин дә сөйлим колагыңа:
Маневрлар әле яңа гына
Кызуланып бара башлады,
Ә Хәмитов безнең ...нче бүлектә
Аксап-туксап йөри башлады.
«Ихи-хи-хи, нәрсә инде,
Аяклар да, өс тә юештә...
Йөре шунда бушка борның салып,
Рәтләп йокламаган килешкә.
Тизрәк үтсен инде маневрлар,
Җанкәшне дә килә күрәсем...
Маневрлар безнең ишеләргә
Кызык булмас, ахры, күрәсең».
Хәмитовтай кешеләр аз туалар,
Ә тусалар – малай булалар;
Көзге чебеш кебек, бичаралар,
Мич башына куйсаң – туңалар.
Әле ансы дисез,
Теләсәгез,
Аннан әйбәтләрен табабыз;
Юкка гына сезнең арагызда
Төн йокламый йөрми агагыз!
Аның берсе «Н» ротасында,
Шайтан төкереп куйган теленә.
Кем эләксә – шуңа, анаңны, ди, –
Чыдайт нельзя, ничек сүгенә!
Билгеле инде, мондый «егетләр»дән
Көрәшчеләр үрнәк алмыйлар;
Алар – меңнән берләр,
Көрәшчеләр
Андыйларга таглып бармыйлар.
Маневрлар инде башландылар,
Көчләр ике якка бүленде;
Күргәз, егет, ничек киләчәктә
Сакларсың син ирекле илеңне.
Илебез ирекле,
Илебез кыйммәт безгә,
Без саклый да аны алырбыз;
Маневрлар аша зур көрәшкә
Корыч колонналар бирербез.
Бүген сүзне шунда туктатабыз,
Иртән тагын сөйләп үтәрбез,
Ә биш көннән, көчне ныгытып,
Авылларга кайтып китәрбез.

## АТЛЫ СУГЫШЧЫГА

Батыр егет, атың җилкәсендә
Көннәр буе инде киләсең;
Тиргә баткан атың, арып беткән,
Сакла үзен, салкын тимәсен!..
Үз вактында аны ашаттыңмы,
Эчерттеңме кирәк чагында;
Оныттыңмы әллә, батыр егет,
Ашатырга аны тагын да?
Ял иткәчтен, тагын бергәләшеп
Җырлар җырлый-җырлый китәрсез;
Туры атың синең исән булса,
Тагын бик күп җирләр үтәрсез.
Кызыл көрәшче, син ат өстендә,
Очкын коштай синең туры атың, –
Көрәш кырларында җан юлдашың,
Хыянәтсез дустың, канатың...

## БҮЛЕНЕРГӘ ЯРАМЫЙ

Саулармы сез, дуслар,
Күптән сөйләшкән юк,
«Сугышта» да булып алдыгыз,
«Гөнаһларны» беркем күрмәде, дип
Уйламагыз, –
Арагызда йөрде картыгыз.
Ульянский, Пенза егетләре
Болай
Батыр сугыштылар үзләре,
Ләкин картыгызның сизгер йөрәгенә
Ятышмады кайбер сүзләре:
  «Ну пензәкләр батыр! Ульянецлар,
Көчегезне бүген сынагыз,
Күрсәтегез безнең әзерлекне,
Казан полыгын шәпләп кыйнагыз!»
Болар – көлеп әйткән сүзләр,
Ләкин, дуслар,
Көлке булуына карамый,
Казан, Пенза, фәлән диеп,
Бүленергә һичбер ярамый.
Кызыл гаскәр
  Ул бер җиңелмәслек
Корыч штыклардан коелган,
Аның көче
Ирекле Совет илен
Дошманнардан саклау өчен җыелган!
Маневрлар шулай бүленә икән,
Бу өйрәнү өчен ителә,
Сез дә,
Сугыш белемен ныклап алыр өчен,
Бүлендегез менә икегә.
Шулай итеп, дуслар, маневрга
Тик өйрәнү итеп карагыз,

*Сезне яратучы бабагыз.*

**АЕРЫЛУ ҖЫРЫ**

Маневрлар үтеп китте,
Китәр вакыт та җитте...
Винтовкалар монда кала,
Алмаш состав тарала.

Аерылабыз озаккамы,
Әллә тагын тизгәме?
Казангамы, Сембергәме,
Әллә башка илгәме?

Кайда гына барсак та,
Кайчан приказ алсак та,
Без килербез, дошман җиңмәс,
Без батырлар бар чакта...

## ИПТӘШЛӘР

Беребезгә бербез нинди охшаганбыз –
Икебез дә соры шинельле,
Икебез дә шундый күңелле...
Син көләсең, миңа карыйсың да,
Ә мин, тиле,
Кочакларга әзер үзеңне;
Танышлар да түгел үзебез,
Ләкин синнән
Ала алмый карыйм күземне.

Нинди охшаганбыз.
Ничек охшаганбыз...
Бертуганнар дисәң,
Мин Тамбовтан, ә син –
Казан артыннан;
Мин – бер мишәр улы, кыргый үскән,
Ә син –
Күрше чуваш халкыннан...

Нинди охшаганбыз бер-беребезгә, –
Икебез дә соры шинельле,
Киемнәр дә бер үк, теләкләр дә,
Бер үк хисләр чолгый күңелне.
Аерылганда миннән,
Туганыңнан
Аерылган күк моңсу калырсың;
Илне саклау өчен чакру килсә,
Беләм,
Мин беренче барсам,
Син миннән дә элек барырсың.
Терсборлар беткәч, өйгә кайтсам,
Мин әнкәйне рәнҗеп үбәрмен:
– Ялганладың, әнкәй, улым өч кенә, дип,
Мин гаскәрдә
Миллионнарны күрдем, диярмен.

**ЧИСТА БУЛ**

Дус егетләр, иптәш кешеләр,
Тагын шуны белегез:
Маневрда йөргән чакта,
Чиста килеш йөрегез!

*

Безнең Абдул аякларын
Гомере буе юмыйдыр,
Ә соңыннан көн буена
Аксап-туксап йөридер.
Их Абдулла, булыр микән
Акылланыр чакларың?
Бүген тагын котелогың
Юмый читкә ташладың!..
Алма, кыяр сатып алсаң,
Юмый-нитми ашыйсың,
Иртә белән:
– Дезинтер, – дип,
Җирдә ауный башлыйсың.
Юлга чыксаң, ялкауланып,
Кайнаган су алмыйсың,
Кайнамаган сулар эчеп,
Көнаралаш аурыйсың.

*

Их Абдулла, булыр микән
Акылланыр көннәрең?
Ял иткәндә ял итмисең,
Азып үтә төннәрең.
Иртә белән юлга чыккач,
Йоклый-йоклый барасың;
Бозау кебек ава-түнә,
Һаман артта каласың...
Тәмәке тартканны күрсәң,
«Сорок» сорап аласың,
Очын да өзеп ташламый,
Авызыңа кабасың...
Их Абдулла, булыр микән
Акылланыр чакларың?
Бөтен полкта синнән начар
Армеецны тапмадым.

*

Йөргән чакта, сулышыңны
Аузың белән аласың,
Шуның өчен дүрт чакрым да
Бара алмый арасың...
Атнада бер битең юсаң,
Анда да белдертәсең,

Кеше сөлгесенә, алып,
Йөзләреңне сөртәсең...

*

Хатын-кызлар очрап куйса,
Кемлегенә карамый,
Дусланасың... үбешәсең...
Безобразие!.. Ярамый!

Их Абдулла, болай йөрсәң,
Күп аурулар алырсың;
Исән башың һәлак булыр,
Калека булып калырсың...

## ЕРТЫК БҮРЕК

*(Үзгәртеп)*

Дөнья матур,
Шуның өчен дә шул
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан.
Ә җил, сыбызгыны,
Ни өчендер
Ияргән дә килә артымнан.
Тфү!
Күзге җилләр тиде теңкәгә.
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Җил иркендә калды урамнар...
Ә җил – морҗа сандугачы,
Эче пошкан саен
Алып килер салкын бураннар...

Кышны ямьсез диләр,
Ялганлыйлар,
Матур була шәпләп киенгәч;
Ә мин бу ел кышын үләрмен үк,
Сезнең өчен
Бик күңелсез калыр, мин үлгәч...
Беренче кар, белмим, кайчан явар,
Тик
Үләрмен мин ул көнне.
Бүген әле, тиздән кыш килә, дип,
Ямап куйдым ертык бүркемне...
Беләм,
Ертык бүрек кыштан саклый алмас,
Үләрмен мин, бу ел кыш килгәч;
Дөнья матур,
Ләкин...
Сезнең өчен
Ни кызыгы калыр, мин үлгәч?

## МИЛИЦИОНЕР

Урам шундый матур...
Эх син, милиционер!
Ап-ак карлар ява башыңа.
Мылтыгыңны тотып, әкрен генә
Кар каплаган урам ташына
Басып йөрисең син...
Тәңкә карлар,
Төнге аксу карлар,
Маңгаеңа кунып үбәләр...
Еллар,
Матур еллар, шаулый-шаулый,
Урамнардан ашыгып үтәләр.
Мин дә урамнардан йөрим.
Болай
Эч пошканнан
Карап йөрим шәһәр кешеләрен,
Марҗалары этләр тагып йөри, –
Ә беләсең, иптәш милиционер,
Яратмыйм мин шәһәр этләрен...
Ничек уйлыйсың син,
Ул этләрнең барсын, барсын да,
Таяк алып тотып, кычкырттырып,
Кыйнап йөрсәм синең каршыңда...
Ябып куярсың шул,
Ансын беләм, –
Син урамда тәртип саклыйсың,
Кыйнаучыны түгел,
Һәрбер кыйналганны яклыйсың...

Газетка да берәр милиционер кую кирәк иде.
Югыйсә
Безне артыграк сыйлыйлар,
Тәнкыйтьчеләр дигән сукбайлар бар,
Көнаралаш тотып кыйныйлар...

*1928*

## БОЛАЙ... ГАДИ ҖЫР ГЫНА

Гомер әрәм китте,
Юк эш эшләп, чәчләр агарды;
Үлем микроблары хәзер
күкрәгемдә, –
Алдап булмас, ахры, аларны.

*Авырулар җыры*

Үпкә дә юк,
Артык ачу да юк,
Болай гына борын салынган;
«Барабыз»да кайтып киләм әле
Аслып үлгән берәү яныннан...
Ах, «барабыз»,
Кай җирдән син?
Атың начар, малай, синең дә,
Син дә, ахры, асылып үләрсең;
«Гомре утта янсын...» диярсең.

Карлар яусын йөргән юлларыңа,
Авыр юлда атың армасын...
Кичер минем усал сүзем өчен,
Ходай өчен хәтрең калмасын.
Кешеләр менә
Өйләнәләр,
Матур киенәләр,
Кызлар сөяләр,
Чәй эчәләр...
Ә беркөнне, безгә ачу итеп,
Тоталар да аслып үләләр...
Ачу килә.
Мин этләрне беләм:
Алар менә
Собраниегә,
Театрга барып йөрмиләр,
Сөяк кимреп гомер уздыралар,
Ә шулай да аслып үлмиләр...
Ах, «барабыз»,
Мин үлмәскә булып йөрим әле,
Кызыктыра бабай булуы,
Кызык булыр әле малайларның
Эшләүләрен карап торуы.
Ашкынып җырланган теләкләрнең
Чәчәкләрен килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...

Ах,
Үләсе килмәс, үләсе...

Бәхетлемен, ахры,
Җир үзенең
Сөйдерә алды бөтен ваклыгын;
Һәр почмагы миңа урын җәйде,
Күргәзмичә үзенең ятлыгын.
Кармак салсам суга, балыклары
Ятсынмыйча килеп каптылар;
Марҗалары, бер дә авырсынмый,
Чалбар-фәлән алсам, саттылар...
Урамнарда йөрсәм, милицияләр
Ачуланып тотып япмыйлар;
Данлы дуслар – кызыл каракошлар –
Чемберленнан мине саклыйлар.
Их!
Кан эчендә туган зур илемнең
Киләчәген килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...
Ах,
Үләсе килмәс, үләсе...
Әле карлар ява,
Әле
Карлы кышның
Ак канаты җирне каплаган,
Әле
Килер язның, матур язның
Шомыртлары чәчәк атмаган...
Күкрәгемне киереп, кышкы көннең
Туялмыйча сулыйм һавасын...
Их, «барабыз»,
Әйдә, ку атыңны,
Әллә нигә авыр барасың.
..................
Синең атың кебек җирән атта
«Аны» озатып бардым киткәндә,
Аерыласы килми сарылды ул,
Соңгы кабат мине үпкәндә...
Хатын-кызлар безне үпкән чакта,
Сагынсын дип, ахры, үбәләр...
Еллар...
Бөек еллар шаулый-шаулый
Сагындырыр өчен үтәләр...

Ах син, илем,
Ничек үләргә соң,
Сагныр кешеләр синдә булганда;
Ничек үлим,

Берләр меңнәр өчен,
Меңнәр берләр өчен торганда!..

## МӘЧЕЛӘР КҮЗ ЯШЕ

Кайвакыт урлап ашасаң син бәлешләр, сумсалар,
Һәм сине, ник урладың? дип орсалар йә суксалар, –
Шәфкатемнән мин җылап йөгрә идем әнкәмә,
Ялварып: «Әнкәй, песигә сукма һәм, зинһар, тимә!»

*Г.Тукай*

Син үлеп киткәннән алып
Күп заманнар үттеләр...
Күп песиләрнең кешеләр
Башларына җиттеләр...
Ындыр артында сугылмаган
Кибәннәр булмагач,
Бар кебек тычкан, күселәр дә
Таралып беттеләр...
Тычкан аулап көн итү беткәч,
Песиләрнең күбе,
Нишләсеннәр, аздылар,
Бурлык юлына киттеләр...
Гомер итү ай-һай авыр,
Күп песинең койрыгын
Тоткан җирендә кистеләр...
Инде хәзер өстебездәге
Җылы туннарны да,
«Мехтрестныкы» дип,
Халыкка игълан иттеләр.
Мич башы йә мич арасына
Качып кына шулай,
«Мәрсия»ңне без укып
Яшьләр түгәбез, әй Тукай!
Яшь түгәбез кан катыш,
Тукай, сине без уйлагач...
Нишлисең соң, песиләрдән
Наркомыбыз булмагач.

*

Әй песиләр, җаннарым,
Сезнең өчен мин дә янам.
СССР песиләрен
Барын да шефлыкка алам.
Алла кушса, без җыйнаулашып
Әле хур булмабыз...
Әйдәгез, сөтләр, катыкларны
Курыкмый урлагыз!

**ГАБДУЛЛА АГАЙ ӘКИЯТЕ**

«Күңле булсын,
Рәхмәт әйтсен диеп,
Туфли алып кайттым хатынга.
Бер атна да үтми,
Карыйм, Миңҗамалың
Сүз кузгата пудра хакында...
Ансын алып кайттым,
Шәһәр бит дим,
Кеше хуры булып йөрмәсен;
Дөнья хәле, күңле калыр дидем,
Үлеп-нитеп китәр, белмәссең.
Күңел йомшак чакка туры килде,
Ни кушса да, сүзен тыңладым;
Ялтырап торган батис күлмәк алдым,
Бәя-фәлән диеп тормадым...
Көннәр үтте,
Беркөн май числосы,
Чыктым собраниедән –
Артык арылды,
Бакча буйлап кайтып киләм шулай,
Күзгә ике кеше чагылды.
Карыйм,
Сөбханалла,
Берсе – минем хатын,
Туфли кигән, пудра ягынган, –
Ана үрдәк кебек басып килә,
Егет тә бит үзенә табылган...
Шуннан, берәр гөнаһ-фәлән булмасын дип,
Артларыннан алга атладым.
Йөри торгач, болар утырдылар,
Егет үбеп алды,
Ах, сволочь!
Күлмәгемә сыймый башладым...
....................
Ул көнне зур гөнаһ булмый калды,
Аерылдылар,
Мин дә киттем хатын артыннан...
Кайткач:
– Кайда булдың, фәлән-төгән, – диеп
Сораштырып карыйм хатыннан, –
Алдый...»
......................
......................
......................
......................
Габдулла агай, кайткач, Миңҗамалын
Ярган, ахры, үзе яруын,
Ансын әйтми,
Тик сөйли ул

Ничек итеп үчен алуын.
«Иртән тору белән, күлмәкләрен
Кыстырдым да култык астына,
Чыгып саттым,
Аннан бик әйбәт бер
Китап алып кайттым хатыныма!..»

## АКТИВ – ПАССИВ

### Актив

Әһе... әһе... Әти, әти, димен!
Комсомолга мине алмыйлар,
Барган саен:
– Синең гаризаңны
Карамадык, –
Диеп алдыйлар...
Ярый... Зур булганнар...
Мин дә үсәрмен.
Башкаларны әнә алалар,
Ә мин барган саен,
Мәсхәрәләп:
– Син – буржуй! – дип,
Читкә кагалар...
Әһе... әһе...

### Пассив

Комсомолга миңа иртәрәк шул,
Өлгерермен әле керергә...
Биш-алты ел кирәк кәҗә куып,
Беспартийный булып йөрергә.
Автомобиль белән йөретсәләр,
Керсәң дә шәп булыр булуын.
Нишләргә соң?
Әллә...
Иртәрәк шул,
Шәбрәк булыр керми торуым.
Керсәң курка төшәм.
Эшләтерләр,
Син комсомол, фәлән... диярләр,
Имәргә дә вакыт табалмассың,
Дөнья кадәр эшләр өярләр...
Уйныйсы да килә...
Иртәрәк шул,
Өлгерермен әле керергә, –
Биш-алты ел кирәк кәҗә куып,
Беспартийный булып йөрергә.

## ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Кем кабренә чәчәк ыргытсам да,
Әрәм китмәс төсле чәчәгем;
Мин җирдәге һәрбер сукбай белән
Дус абыйдай тату яшәдем.

Поезд ыргый таныш урманнардан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар,
Уйлар һәр очраган ак каенның
Ботагына асылып калалар...
Юл буенда яшь бер каен кызы
Тынып йоклый баскан көенә.
Исрек усак, җәеп канатларын,
Аны үбәр өчен иелә...
Тик урманның төнге тынычлыгын
Җимреп килгән поезд таушына
Ул, сискәнеп, берни булмагандай,
Үз урнына табан аушына...
Юл буенда йомылып йоклап яткан
Урман чәчәкләре сискәнеп
Уяналар...
Поезд килгән якка
Керфекләрен ачып карыйлар,
Ул үтүгә, тагын йомалар –
Урман тынлыгына чумалар...

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен;
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...
Поезд ыргый, ә мин тәрәзәдән
Күрмәмме дип бер-бер танышны,
Һәрбер станциядән күзем алмый,
Карап барам үтеп барышлый...
Кем соң кирәк миңа?
Станциядә
Арлы-бирле йөргән халыклар –
Ертык бүрке, тузган чабатасы белән
Миңа якын, миңа танышлар...
Мин гомрем буе шул кешеләрнең
Йөрәк тавышларын тыңладым,
Каныма манчып язган һәр җырымны
Алар теле белән җырладым.
Алар арасында, матурланып,
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем;
Давыллы елларда, киң кырларда
Алар белән бергә яшәдем...

Алар башка хәзер;
Алар, тар сукмактан чыгып,
Зур юлларга табан баралар.
Алар көче белән җирдән күтәрелә
Яңа авыл, яңа калалар...

Поезд ыргый,
Ә мин тәрәзәдән
Озатып калам һәрбер танышны,
Һәрберсенә җылы хисләр белән
Елмаямын үтеп барышлый...

## ТӘҮФЫЙКЛЫ ПЕСИ

Әби

Минем песи гаҗәп хыянәтсез,
Мулла кебек тәүфыйк иясе:
Каймак куясыңмы... ни куйсаң да,
Һич кенә юк инде тиясе.

*

Чүлмәгемне шунда калдырыйм да
Печән бирим малкайларыма...

Песи

Ә мин, әби җаным, син килгәнче
Менеп төшим чүлмәк янына.
Песи өчен нәрсә, еракмыни
Өстәл белән бүкән арасы.
Азапланып, бер дә мәнәсе юк,
Тик бер генә сикреп аласы.

*

Каймак – тәмле әйбер, каймак өчен
Җанын җуя бик күп песиләр...
Тик уңайсыз шунсы: каймакларын
Тар чүлмәккә сала кешеләр.

*

Менә хәзер әйбәт булып китте.

Эт

Йортны саклау, малай, җиңел түгел,
Караклар шул куркып тормыйлар;
Күзеңне дә йомып өлгермисең,
Хәзер бер нәрсәңне урлыйлар!

Кешеләре әле кешеләре,
Мәчеләре тынгы бирмиләр,
Алар сыйланалар, йонлы колакларны,
Ә хуҗалар мине тиргиләр.

*

Чүлмәк харап булды.

Эт

Анда нәрсә?
Берәр карак, ахры, кергәндер...
Юк, качалмас, шайтан алган нәрсә, –
Мине йоклый диеп белгәндер.

*

Каракларның, малай, эзе дә юк,
Кай арада качып киткәннәр?!
Абау, йөзе кара булгырлары,

Сөт чүлмәген харап иткәннәр.

Бу – мәчеләр эше, һичбер шик юк,
Үләт кенә төшсен аларга.

*

Тәмле әйбердер, ахры, – белер өчен
Кирәк, малай, кабып карарга...

*

Әйе, кирәк...
Тәмле, бигрәк тәмле,
Песиләр шул тора беләләр...
Йонлы борыннарны, эшләмичә,
Каймак ашап рәхәт күрәләр...

*

Акбай кәефләнде:
– Ну, каймагы әйбәт икән, –
Диеп мактады.
Ә ишектән әби, борынын сузып,
Мыштым гына өйгә атлады...

Әби

Әһә... менә кем икән ул явыз карак,
Сөт-каймакның башына җитүче,
Менә кем икән ул йортымдагы
Чүлмәкләрне харап итүче!
Менә сиңа, менә, йөзең кара,
Менә сиңа, муенның сынгыры!
Югал күз алдымнан, оятсыз нәрсә,
Кит хәзер үк, үләт кыргыры!..

*

Ә песием минем, җан кисәгем,
Мулла кебек тәүфыйк иясе:
Каймак куясыңмы... ни куйсаң да,
Һич кенә юк инде тиясе.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

## КАВИ ӘКИЯТЕ

«Кайдан уйлап чыгарганнар
Уку дигән,
Мәктәп дигән шайтан сабагын,
Йөрисе дә килми,
Укыйсы да...
Үзем болай тырышкан да булып карадым.
Керми башка...
Бүген бармыйм инде,
Укытучылар сүксә сүгәрләр;
Уку кирәк диеп йөри икән,
Йөрсен миннән башка юләрләр...
Ә мин бераз дөнья күреп кайтыйм,

Әйбәт булып китәр күңелгә;
Мәктәп качмас әле, кыш бик озын,
Өлгерермен анда йөрергә...»

Кави, зурлар кебек, таяк алып,
Теге очка табан атлады.
Йөри-йөри арып-талып бетте,
Тик юаныр әйбер тапмады...

Ачыгып кайтып барган чакта гына,
Көтмәгәндә кызык табылды:
Койма буйлап шулай бара иде,
Күзенә бер эт кызы чагылды.
«Әһә... ләкте, малай, тукта!
Моны кызык итеп алыем.»
Кызык итәр өчен, койма аркылы
Атлап чыкты Кави абыең.
Акбай эшне күптән сизеп тора,
Тик йоклаган була, чукынган...
Кави – корсагына төрткән иде,
Торып, эләктерде ботыннан.
Әй кычкыра теге, әй кычкыра,
Әй сызгыртып елый башлады;
Акбае да усал булып чыкты:
Бот йомшагын өзеп ташлады.
Үзе әле, Кави китү белән,
«Аф-аф» дигән булды, сүгенде,
Тик соңыннан гына, тынычлангач:
«Юк эш эшләдем!» – дип үкенде,
Ә Мөхәммәт-Кави, дөнья җимреп,
Боты канга баткан көенә,
Урам буйлап, авызын җәймә итеп,
Елый-елый кайтты өенә.
Өйгә кайткач, аны анасы да
Назламады, күңлен күрмәде;
Назлау кая,
Элек тотып ярды,
Ә соңыннан әпәй бирмәде...

* * *

Айга күптән инде мең яшь тулган,
Ә ай аны үзе оныткан;
Кичә саташкан ай, кыш дип белеп,
Төн уздырган күктә толыптан...

Ай кебек, без озак яшәмәбез,
Көчләр сүнәр,
Куллар талырлар,
Картаербыз,
Соңгы көрәшләргә
Яшьләр генә, ахры, барырлар.
Яшьләр белән мин дә барырмын дип,
Алдыйм болай үзем алдавын,
Ләкин
Бил авырткан чакка туры килер,
Ихтимал шул бара алмавым...
Их, яшьлекнең үтәр алсу таңы,
Мин туктатмыйм синең агымны;
Үтәр өчен килгәч, карышып тормыйм,
Җырлап озатам яшьлек чагымны...
Әле картлыкның да үз вактында
Матурлыгын таба белербез;
Октябрятлар безне эштән куса,
«Тавык комиссиясе» төзеп,
Тавыкларның
Тормышларын рәтләп йөрербез.
Тавыклар да ун ел безнең белән
Бер аякка басып бардылар:
Салам ояларга
«Совет өчен»
Ап-ак йомыркалар салдылар...
Ах, җир,
            ах, җир!
Синең матурлыгың
Шундый тигез итеп таралган:
Һәр дуңгызың, һәрбер песи кызың
Чәчәк кебек матур яралган...
Һәр этәчкә бүркем салып үтәм,
Совет саулык бирсен аңарга;
Һәрбер эткә, үзе тели икән,
Рөхсәт итәм борным яларга...
Һәрбер сыер мине бозавы итеп
Ап-ак сөте белән имезгән;
Һәрбер сарык, тунын салып биреп,
Кышкы суыкларда кигезгән...
Ә ай ялгыз,
Айда бернәрсә юк,
Әтәч тә юк анда, песи дә;
Катык та юк анда, ипи дә юк
Безнең ише ярлы кешегә...

## *1929*

### МОКАМАЙ

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге онта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары –
Андагыдай шаулый торганнар...

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез кара:
Сары чәчлесе ул мин идем;
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син идең...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син меналмадың...
Калдың,
Югалдың...
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез дә кара борынлы,
Зурлар кебек, кулны артка куеп
Йөри идек таптап болынны...
Һәрбер нәрсә безгә яңа иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...
Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме тал чыбыгы ашадык;
Әкияттәге ике бала кебек,
Күпме «җәфа чигеп» яшәдек...
Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыңны
Һәлакәткә алып барыр дип...
Хат язсам да, хәзер соңга калдым,
Укымассың минем хатымны,
Ләкин минем бурчым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яман атыңны!
Син гомереңне усал исем белән,

Канлы пычак белән чикләдең...
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен, җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син меналмадың...
Калдың,
Югалдың...
Үткәннәрем – авыр әкият минем.
Ул әкиятне әгәр сөйләгәндә,
Чаглып китсә синең күләгәң,
Юк, юк,
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең.
Тик син ачлык тырнагыннан,
Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...
Ә бит,
Бергә чабаталар үреп йөргән чакта,
Син остарак миннән үрәйдең,
Минем матур итеп үралмауны
Булдыксызлыгымнан күрәйдең...
Ник соң бу болай булды әле,
Ничек һәлакәтең күрмәдең,
Ник, Мокамай, соң син тормышыңны
Чабатаңдай матур үрмәдең?!
Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең;
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Ә бит безнең гомер матур урманнарда
Май аедай матур башланды;
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез ике якка ташланды...
Синең тормыш авыр әкият булды,
Ул әкиятнең соңгы битләрен
Син зур исем, мәңге онтылмаслык
Эшләр белән бизәп китмәдең...
Син адаштың,
Ләкин син яхшы идең,
Синең яхшы иде күңелең,
Тик белмәдең тормыш баткагыннан
Ялгыз чыгу мөмкин түгелен...
Син белмәдең,
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр;
Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен,
Күмәк тормыш җирдә төзиләр...
Үткәнемне әкият итеп сөйләгәндә,
Чаглып китсә синең күләгәң,
Юк, Мокамай, һичбер вакытта да

Сине усал итеп сөйләмәм...
Син ярлы идең, ләкин эш сөя идең,
Синең яхшы иде күңелең,
Син белмәдең сыйнфый бөлгенлектән
Алай чыгу мөмкин түгелен...

## СЕРЛЕ КҮЗЛЕК

*(Ике шагыйрь сөйләшә)*

– Берәү беркөн әллә каян шунда
Серле күзлек табып кигән, ди,
Карап торган ачык авызларга:
«Маркс күзлеге бу!» – дигән, ди.
Шуннан
Кызыл доцент исме аңа биргәннәр, ди,
Хәзер
Шул күзлеген бер дә салмый, ди;
Ә шулай да
«Капитал»ның «К», «А» хәрефләрен
Бергә кушып укый алмый, ди.
Белмим,
Әллә гайбәт,
Әллә чындыр инде...
Ләкин шул хәлфәнең үзен бар диләр.
Әле профессор да булыр диләр,
Валлай менә,
Әллә усал телләр алдыйлар...
Сөйлә әле син дә берәр нәрсә,
Әллә нәрсә борның салгансың.
Үзең сөйләмисең,
Үзең сызгырасың,
Әллә инде артык аргансың...
– Нәрсә ялганларга,
Андый кешеләр
Күпләп тирәбездә әйләнә,
Аларның шул койрык шәрифләре
«Теге якка» барып бәйләнә...
Шуның өчен менә бик күпләре
«Кызыл» күренергә телиләр;
Артык кызарырга маташалар, –
«Серле күзлек» киеп йөриләр...

**АЛСУ**

Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Карда шуа-шуа, Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
Җилгә каршы җылы сулышлары,
Туңып, бөдрә чәчен ак ясый...
Юл буена аны тирги-тирги,
Сүгнә-сүгнә кайта Газзәсе:
«Алсу, тукта инде, акыллым,
Абау,
Тагын карга батырдың!..»
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
«Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!»
Үзе – килсә, карга батыра.

Салкын карга басып, Алсу килә:
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Урам шаулый-шаулый төн уздыра,
Кемнең монда кемдә эше бар;
Һәрбер җылы тунлы кешеләрнең
Җылы бүрке, торыр төше бар...
Тик чаттагы бабай – «барабыз»ның
Бик үк әйбәт түгел тормышы,
Һәр көн таңнан алып кичкә кадәр
Салкын урам – торган урнысы.
«Җанкисәгем, бабай, «барабыз»!
Атың белән сатып алабыз,
Студентта акча бик күп була,
Әй,
Ун тиенгә илтсәң, барабыз!..»

Алсу, бүлмәсенә керү белән,
Өске киемен алып ташлады;
Ватык көзгесенә карый-карый,
Карлы чәчен сүтә башлады...
«Газзә, кара, ничек минем чәчләр
Бер-берсенә ябшып туңганнар...»
«Карлы чәчләр сиңа килешә, Алсу,
Үз чәчеңнән матур булганнар...»
Алсу күзен алмый үзен карый:
Үзе матур,
Үзе сөйкемле,

Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Аңа бүген әллә нәрсә булган:
Бер җырлыйсы килә, бер көлә,
Бер онтылып, кинәт керфекләре
Бер ноктага килеп төртелә...
«Ташла әле, Газзә, зачетыңны,
Их, үбәсем килә үзеңне,
Ну, үбәсем килә үзеңне...
Тыңла инде бер кат сүземне?..»
Газзә, ирексездән эшен ташлап,
Сүгнә-сүгнә килә янына:
«Тфү, каһәр суккан!
Ачуың килмәгәе,
Тоз саласың инде каныма!
Син шул, кызый, үзең зачетыңны
Бик соң әзерләргә башлыйсың.
Үзең бездән алда биреп ташлыйсың,
Ә без...»
Ул Алсуга ачу белән карый,
Тик ачуы бик тиз басыла.
Алсу бала кебек елмая да
Иңнәренә килеп асыла...
Газзә түзми, аның сүзен көтә,
Үзе уйлый зачет бирәсен...
Алсу көлә-көлә күзенә карый,
Соң ул аңа нәрсә сөйләсен?!
Сөйләсенме матур яшьлегенең
Зур елларга туры килүен,
Сөйләсенме җирне, бүгенгене –
Бар нәрсәне өзелеп сөюен...
Һәр кояшлы иртә аның өчен
Яңа уйлар алып китерсә,
Бүгенгенең һәрбер матурлыгы
Үзе белән аны исертә...

Шуның өчен бүген ул төн белән
Бер хат язды карты исменә
(Карты кемдер...),
Кәкре юллар ясап,
Сызып-сызып алды тиз генә.
Хатның соңгы юлы:
«...Бик сагынсаң,
Хатым бассын күңлең ярсуын,
Бик бәхетле синең Алсуың...»
Хаты белән бергә яңа төшкән
Рәсмен салды үзенең картына,
Кулына соңгы кабат рәсмен алып,
Шул сүзләрне язды артына:
«Бу – Алсуың синең,
Күрәсеңме,

Нинди матур булып утырган!
Кара, башкаларга мине алмаштырма,
Кадрем белеп яшә, чукынган!..»

Коридордан басып, Алсу килә:
Үзе матур,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Ул дәрескә бүген бик соң килде,
Әллә кайда йөреп кичеккән.
Үзе соңга калган,
Үзе әле
Көлә-көлә керә ишектән...
Үзе дәрес тыңлый,
Үзе бер дә
Тыңламаган кебек итенә,
Үзе профессорның дәрсен яза,
Үзе аның борнын кәкре итеп
Төшреп куя дәфтәр читенә...
Үзе зачетларын әзерләргә
Барыннан да соңрак тотына,
Үзе зачетларын башкалардан
Алдан бирә, алдан котыла...

Һәрбер нәрсә аңа, күп көч куймый,
Әллә ничек җиңел бирелә;
Янар яшьлегенең алсу таңы
Үтмәс төсле булып күренә.
Ул үзенә үзе хуҗа бүген,
Үзе акыллы, үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

## МУЛЛА ЧЕМБЕРЛЕН

Инглизләр, әфган муллаларын сатып алып, Әфганстанның берничә өлкәсен аерып, үз кулларына кертергә маташалар.

*Телеграф хәбәре*

«Азгын хан кулында һәлак була
Ислам кебек туры, хак бер дин,
Коткарырга кирәк, җәмәгать! – дип,
Вәгазь сөйли мулла Чемберлен! –
Бөтен көчне куеп маташыгыз,
Дин-шәригать җирдән бетмәсен;
Ичмасам, – ди, – аерып алу кирәк
Җәләлабад дигән өлкәсен!
Ул өлкәне генә булса да сез
Динсезлектән саклап калыгыз,
Менә юллык сезгә, изге сәфәр,
Әфган илләренә барыгыз».

## ТАНЫШ ТҮГЕЛ ЕЛМАЮЧЫ

Кем син?
Белмим.
Әллә күптән инде
Онтылган бер иске танышмы,
Әллә таныш түгел, оялмыйча
Елмаясың үтеп барышлый?..
Үзең матур елмаясың,
Ә беләсең,
Шулай булганда да кирәкми, –
Елмайдың да менә үзең белән
Ияртеп китә яздың йөрәкне...
Соңгы вакытларда болай да әле
Әллә нәрсә миндә сизелә:
– Быел боздырырлар, ахры, тәүбәмне, – дип,
Ышанмыйча йөрим үземә...
Тукта,
Нигә иргә чыкмыйсың син? –
Менә ничек үз кадреңне үзең белмисең...
Китап тоткан булып,
Укыган булып,
Әллә нәрсә шунда йөрисең...
Матур кызлар алар иргә чыга,
Барбер рәтләп укый алмыйлар;
Артларыннан йөзләп егет йөри,
Кайсы кая үзен алдыйлар...
Матур кызлар театрга йөри,
Алар
Артистларны,
Шагыйрьләрне күреп беләләр;
Тик алама шунсы кызыйларның, –
Зачетларын начар бирәләр...
Хәзергәчә уку йортларыннан,
Сора менә,
Кемнәр күбрәк сөрелеп чыкканнар?
– Матур кызлар.
– Нигә?
– Шаяралар,
Укымыйлар, каһәр сукканнар...

*

Матурлардан рәтле хатыннар да,
Яхшы аналар да чыгалмый, –
Күзге, каһәр суккан, комачаулый,
Ә күзгесез алар торалмый...
Берәр җиргә эшкә керсәләр дә,
Әллә нәрсә эшләп бетәләр;
Йә үзен үк завны,
Йә замзавны,
Йә месткомын гыйшык итәләр...
Иргә чыксалар да котылып булмый,
Башка бәла булып калалар:
Ефәк оек, ефәк күлмәк диеп,
Ир дигәннең җанын алалар...

*

Син кем?
Белмим.
Әллә күптән инде
Онтылган бер иске танышмы,
Әллә, мине танып, болай гына
Елмаясың үтеп барышлый?..
Елмаюын елмай, ләкин кара:
«Теге» кеше ялгыш күрмәсен,
Шундый бирер...
Гомрең буе көлеп йөрмәссең...

## БЕСПАРТИЙНЫЙ

Партиялеләр булмаса, партиясезләр булмас иде.

*Акыллылар сүзе*

### Алмыйлар

Партиягә кермә инде, диләр,
Пионерга дисәм, алмыйлар,
Комсомолга яшең үткән, диләр,
Менә ничек мине алдыйлар...
Алмасалар, әйдә алмасыннар,
Өлгерербез әле керергә,
Дөнья болай да бик иркен,
Кирәк бераз
Беспартийный булып йөрергә...

### Юану

Килер бер көн:
Җирдә сыйныфлар да,
Партияләр дә бетеп китәрләр, –
Коммунизм булыр!
Кешеләр, беспартийный булып,
Тыныч кына гомер итәрләр...
Без шул анда кадәр мыштым гына
Беспартийный булып барырбыз.
Коммунизм булгач,
«Зур стажлы партиясезләр»
Исмен алырбыз...

### Үпкә

Ачуым да килә,
Үпкәлим дә,
Әллә нишли минем күңелем,
Мин тәүфыйклы,
Честный беспартийный булып
Картаерга җирдә теләдем.
Булмый калды,
Нәрсә...
Алдашмыйча көн-төн эшләдем,
«Уңлык», «суллык» белән авырмадым,
Акча туздырмадым, эчмәдем...
Хатын белән тату торган булдым,
Чит хатыннар белән йөрмәдем.
Лото уйнамадым,
Яхшы партиец күк эшләп йөрдем,
Болай булыр диеп белмәдем...

### Ачу

Нәрсә ялганларга –
                    җәберлиләр,
Беспартийный дисәң, көләләр;
Кешемени алар, дигән булып,
Исәнләшми йөри бирәләр...
Әле менә тагын шул көннәрдә
Партиядә чистка башлыйлар,

Җыен рәтсез, җыен башсызларны
Беспартийный кеше ясыйлар...
Ә без түзеп торыйк, имеш, шул эшләргә,
Тыныч килеш кенә калыйк,
Җыен шалапайны,
Рәхим итегез, көткән идек, диеп,
Кочак җәеп каршы алыйк...
Бик кирәкле кишер яфраклары,
Шайтан алган кыек аяклар,
Сезнең дә әле безнең арабызда
Дөнья кадәр әрәмтамаклар...

**Протест**

Менә нәрсә, обком агайлары,
Күңелегезгә авыр алмагыз,
Җәбер була безгә,
Бераз гына
Безнең хәлләрне дә аңлагыз!
Башка исем шунда бирәсезме,
Теләсәгез генә нишләгез,
Ләкин,
Зинһар, диеп әйтәм, ул халыкны
Безнең исем белән йөртмәгез!..

* * *

Руфик!
Син ташлап кит Кара диңгез ярын,
Нәләт төшсен,
Һичбер вакытта да сагынма.
Мин адашып сездән калдым, аның
Ярларында йөргән чагында.
Сагынырсыңмы мине?
Белмим.
А, юк!
Тик син генә сагынып еларсың,
Тик син генә яшьле күзең белән:
– Папа кайда? – диеп сорарсың.
Син ташлап кит Кара диңгез ярын,
Һичбер вакытта да сагынма, –
Зур югалту, авыр уйлар белән
Атаң йөрде аның ярында.

## ЙОМШАК БАШЛАР

Сыйнфый сизгерлеге аяк табанында йөргән
Кайбер йомшак башлы түрәләр
Кулак зур корсаклы, коточкыч бер
Хайван була диеп беләләр...
Авылларга барып чыккан чакта,
Очратырга аны телиләр,
Шундый билгеләре булган кулакларны
Авыл буйлап эзләп йөриләр...
Пилмән ашап, корсак шәрифенә
Катарр булган нечкә кулакны
Күрмәмешкә салынып үтәләр:
«Ул – средняк», – диеп китәләр...
Шундый нечкәләрдән берәрсе
Налог эше белән килсәләр,
Йомшак башлы андый кешеләрне
Элек
Баштанаяк карап үтәләр:
Нечкә булса үзе, ике күзе
Коточыргыч дәһшәт булмаса,
Йөзе елмаюлы булып, бит тирәсе
Таудай булып өелеп тормаса,
Налогын да аның киметәләр,
Хокукын да кире бирәләр...
Кулак өчен гаҗәп кул кеше инде
Шундый йомры башлы түрәләр...
Алар: «Авылларда сыйнфый көрәш
Юк», – дип аңлатырга телиләр.
«Сыйнфый көрәш – туплар, пулеметлар белән генә
Була ала», – диеп йөриләр...
Кулак шырпысыннан авылларда
Һәлак булган колхоз йортларын,
Игеннәрне
Теге йомры башлы түрәләр
Хулиганнар эше диеп күрәләр...
Алар авыл активлары үтрелүдән
Сыйнфый көрәш эзен тапмыйлар:
«Бу – бер уголовный эш», – дип, суд залында
Кулак агайларны яклыйлар...
Кулакларның икмәк яшрүләрен
Бәрәңге күмә дип карыйлар;

Кулак белән гүляйт итүләрне
Зарарсыз әйбер дип саныйлар...
Кулак үзен яклаучыны
«Уң» яктан да таба, «сул»дан да,
Үсә алыр иде, эш башында
Шундый яклаучылар торганда...

## УТАЛГАН ЧҮПЛӘР

Һәр заманның үзенең чире була,
Һәрбер чирнең була докторы;
Һәр дәвернең була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры!)...
[. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .]
Һәр хәзрәтнең була фидиясе,
Һәрбер җинаятьнең – статьясы,
Һәрбер судның була судьясы,
Һәр бакчаның чүбе булган кебек,
Йолкып ташлый торган кул була;
Килеп кергән ишек күп вакытта
Сөрелеп чыгу өчен юл була...
Чистка булса – каһарманы була,
Сугыш булса – була корбаны;
Партия эчендә дә табылгалый
Контр булып йөри торганы.
Менә сезгә Туран каһарманы,
Партбилетлы партия дошманы,
Милли буржуйларның СССРда
Калдырып киткән пычрак штаны...
Бусы, ак погонлы «ватан гаскәрләре»
Шанлы килеш качып барганда,
Погоннарын ертып, кар базында
Мыштым гына качып калган да,
Еллар үткәч, явыз ният белән
Әллә нинди юллар аркылы,
Алдап-йолдап, безнең арабызга
Килеп кергән, шайтан алгыры.
Бусы, хәзрәтлеген яшреп, тамак өчен
Бик зур шәргый хәйлә ясаган.
Партиягә кереп урын алып,
«Сәвит садакасын» ашаган...

Заманабыз – чистка заманыдыр,
Геройларны тудыру заманы;
Һәр кояшлы иртә үзе белән
Алып килә безгә яңаны.
Менә сезгә урыс хәзрәте бу,
Мулла Иван була,
Карагыз!
Ярты потлы көмеш тәресен яшреп,
«Партионный» булган папагыз!

Ә бусына карап:
– Кем бу, мондый
Әйбәт егет була, – дисезме?
Бу бит безнең теге алпыт улы
«Кулакетдин» була шикелле...
Шул, шул...

Бусын танымассыз.
Бу электән
Сәүдәгәрлек итеп йөрегән,
Хәзер партиягә кергән.

Бусы менә
Көнен-төнен эчкән, җебегән...

Бу егетнең менә, партстажы
Үскән саен, борны үскән, ди;
Үсә-үсә хәтта борны тиеп,
Хан мәчетен җимреп киткән, ди.

*

Чистка комиссиясе бу чүпләрне
Йолкып ташлый торган кул булды,
Алдап-йолдап кергән ишекләре
Сөрелеп чыгу өчен юл булды.

## АВЫЗЛАРЫ, БОРЫННАРЫ ҖИМЕРЕЛГӘН СҮЗЛӘРНЕ ЯКЛАП

Кабыргасыз, йомшак урыс теле,
Ничек борсаң, шулай борыла
(Башка чарасы юк), –
Безнең агай-эне
Эләккән һәр урыс сүзенең
Кабыргасын тотып сындыра!
Сүз юк:
Урыс телен белү – кирәк нәрсә.
Ләкин
Кирәклеген аның бутыйлар...
Татарларга, татар була торып,
Урысчалап доклад укыйлар.
Ответработниклар!
Бәлки,
Урыс теле шәп тел икәнлекне
Күрсәтүдер сезнең уегыз,—
Яхшы эш ул,
Тик шулай да, зинһар, куегыз!
«Ответ» дигән сүзнең «в»сын ашап,
«Әтбит» дигән булып йөрисез;
«Моя» белән «мой»ның муенын борып,
Үтерергә, ахры, телисез.
«Совсем» сүзен «чәпчим» чәпчеттегез,
Урыс аңламаслык иттегез;
Бу ни хәл бу, «әтбит работниклар»,
Бу нинди юл белән киттегез?!
Татар газетына урысчалап
Мәкаләләр язып бирәсез.
(Секретарьга кушып яздыруны
Сизмиләр дип, ахры, beләсез...)

*

Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса,
Татар теле ул бит татар белән
Аңлашырга ярый лабаса...

## СИН – ДОШМАНЫМ МИНЕМ

«Партияле» һәм партиясез солтангалиевчеләргә

Очраганда, хәзер синең белән
Исәнләшмәм, –
Үпкәләүдән түгел бу минем,
Һич юк...
Газетада исмең күрдем синең,
Үткән көрәш юлың карадым,
Укып чыктым Үзәк Комиссиянең
Синең хакта булган карарын.
Ә беләсең,
Шул ук газетада
Бер хәбәр бар,
Кыска гына итеп язылган:
Бер авылда яшь бер комсомолның
Канлы тәне кырдан табылган...
Укыгансыңдыр...
Ул эшне мин синең кулың белән
Эшләнгән эш диеп карадым,
Һәр көн булып торган шундый корбаннарны
Синең корбаннардан санадым.
Чөнки
Син, хамелеон, төсең алмаштырып,
Безнең арабызда калгансың;
Кулакларны яклап, һәр эшеңдә
Җимрү юлын алып баргансың.
Без көрәштә булган һәр уңышны
Йөрәк каны биреп алганда,
Мең авырлык белән, ял итмичә,
Соңгы җиңүләргә барганда, –
Син кулыңны биреп, оялмыйча,
Солтангалиевтәй этләргә,
Көрәшкәнсең,
Һәрбер адымыңда
Таяк тыгып безнең эшләргә.
Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен,
Йөрәгемдә бер хис тапмадым;
Бел!
Бүгеннән соң
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөри башладым.

## УРАМ-АВЫЗ СӨЙЛИ

Иптәш, иптәшкәйләр,
Яшь егетләр, зурлар, бабайлар,
Эшче, хезмәткәрләр вә башкалар,
Кыскасы шул, абзый, агайлар, –
Йокламагыз!
Һәр көн иртә белән
Киоскыга чыгып карагыз
Һәм көтегез,
Шушы өч-дүрт көндә
Чыгып куяр «Чаян» бабагыз!
Үкенечкә-нигә калмас өчен,
Аузыгызны ачып калмагыз,
Бу номеры артык аз басыла, –
Җитми калса, разбой салмагыз!
Без үзебез, «зинһар, алыгыз» дип,
Алай артык ялнып йөрмибез,
«Чаян»ны без
Ялнып кына сатып була торган
Начар журнал дип тә белмибез...
Инде үзегез ялынып сорасагыз,
Без адресын әйтә алабыз:
Беләсегез килсә, бу шигырьнең
Соңгы юлын укып карагыз!

## ҖАВАП

Урамнардан күпме эзләсәм дә,
Такташ баскан эзләр табылмас;
Шашкын йөрәкләрнең шат җырчысын
Минем кебек беркем сагынмас...
Ник язмый ул?

*Әюп Гәрәй хатыннан*

Һәрбер фронт безгә зур көрәштә
Яңа җиңү алып килгәндә,
Һәрбер җиңү алып килгән шатлык
Зур ашкыну безгә биргәндә,
Әллә күңлем артык ашкынудан,
Яшем яшькә җитми ардыммы,
Бүгенгенең бөек борылышында
Ыргытылып читтә калдыммы?..

Бүгенгенең чиксез ашкынуы
Авызлыклап тормыш агымын,
Алгы көрәшләрне күздә тотып,
Кызулатты корыч адымын.
Терәк булып безнең теләкләргә,
Урам саен
Бетоннардан йортлар коела,
Һәр йорт балаң булып,

Һәрбер фасад
Җырың кебек якын тоела...
Хыял – безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер теләк – якын киләчәк,
Һәрбер совхоз,
Һәрбер гигант колхоз
Яшәү көче безгә бирәчәк!..
Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә, –
Башларыннан инде бөтен дөнья,
Республика кыры күренә...
Ә мин, җырлый алмый бүгенгене,
Шулай ярты юлда ардыммы,
Зур елларның бөек борылышында
Ыргытылып читтә калдыммы?..
А, юк!
Бу тик болай,
Бу – тик әле
Алга бару өчен тукталу;
Күтәренке тавыш алган чакта,
Бераз гына туктап тын алу...
Мин биш елда үземә бурыч итеп куям
Пушкиннарны узып китәргә, –
Республикам миңа әмер итә
Тулы килеш шуны үтәргә!..

## АК ЧӘЧӘКЛӘР

*(Идиллия)*

*Ул,*
Эретеп туңган тәрәзәне,
Мыштым гына карый урамга, –
Ак чәчәкләр ява урамда...

*Берәү,*
Борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан, –
Җил ияреп китте артыннан...

*Алар,*
Чана тартып, җырлый-җырлый,
Тау шуарга икәү уздылар, –
Ә бераздан кире сыздылар...

*

Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Кар астында йоклар урамнар,
Төне матур булса, төн үтүгә,

Таңнар алып килер бураннар...
Дөнья матур,
Шуның өчен дә бит
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан;
Ә җил мыштым гына, эндәшмичә,
Ияреп килә минем артымнан...
Белмим, нигә, әллә гыйшкы төшкән,
Кайда барсам – шунда бара ул;
Өйгә кергәндә, җиргә ятып,
Чыкканымны саклап кала ул...
Шуның өчен дә мин чыкмый гына
Тәрәзәдән карыйм урамга –
Ак чәчәкләр ява урамда...
Ак чәчәкләр ява, дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

## *1930*

* * *

Батырларның батыр булганлыгы
Сугыш кырларында беленә,
Уңган кешеләрнең уңганлыгы
Эшкә килгән чакта күренә.
Бик күпләрнең, әйтик, кемлекләрен
Еллар буе белми барасың,
Кинәт, бер вакыйга уртасында күреп,
Аның кемлегенә хәйран каласың.

## ЯҢА ЛОРДЛАР, ПЕРВЫЙ СОРТЛАР

Лондон 4 (ТАСС). Яңа ел мөнәсәбәте белән. Макдональдның тәкъдим итүе буенча эшчеләр партиясе члennарыннан Артур Понсонби һәм майор Зийг Аманга лордлар дәрәҗәсе бирелгән.

Яңа лордлар белән Англияне
«Чын күңелдән» тәбрик итәбез...
Эшче лордлар булгач,
Инде эшчеләрдән
Король сайлануын көтәбез!

*

Англиядә эшче хөкүмәте
Булганы юк,
Ләкин тиздән киләчәк!
Фахиш уенчылар – фарс артистларын
Англиядән себереп түгәчәк!

Лондон 4 (ТАСС). Берләшкән текстиль промышленность хуҗалары Англиянең эчке эшләр министры Клайнега, забастовкачыларны басу өчен полиция җибәреп, тизлек белән ярдәм итүе өчен рәхмәт әйтәләр.

Гаҗәпләнер әйбер юк бу эштә.
Хуҗалары
Юкка гына рәхмәт әйтмәгән,
Клайне үзенең алган бурычын
Йөз процент яхшы үтәгән.
Компартиянең үсеп җитүе өчен,
Бу фактлар шиксез кирәкле, –
Алар ачыграк итеп эшчеләргә
Аңлаталар безнең теләкне.

## «ЧАЯН»НЫҢ ХАЙВАНАТ БАКЧАСЫ

Быел кышын яшь бер песи кызы
Туберкулез белән авырган.
Кырымга дип чыгып киткән булган,
Туңып үлгән, чыккач авылдан.

*

Тавык яланаяк кырда йөргән,
Аягына суык тигән, ди,
Әтәч аңар:
«Тиздән, насыйп булса,
Туфля алып бирәм», – дигән, ди.

*

Ак ана каз, кереп оясына,
Чеби чыгарырга тотынган,
«Актив» Гали, килеп, колхозга дип
Өстерәп алып чыккан ботыннан.

**Акбай**

Әтәчләрне көчләп колхоз иткәч,
Мин калмамдыр, диеп йөргән, ди,
Керә алмагач,
Кулак белән мине тиңлиләр, дип,
Хурлыгыннан асылып үлгән, ди...

*

Ана бия быел, мин колхозга
Керәм, диеп өмет иткән, ди,
Бер хуҗадан күчеп бер хуҗага,
Кералмыйча алҗып беткән, ди.
Әхмүш агай, сыеры бозаулагач,
Яшь бозавын суймак тели, ди,
Ә сыеры аның, серен белеп,
Бозауламый һаман йөри, ди.

**Кәҗә**

Сакалым зур, мин – ил карты, диеп,
Иртүк собраниегә барган, ди,
Доклад озын булгач, өенә кайтмый,
Сельсоветта йоклап калган, ди.

## СУККИН СЫН

Бүген гүя миңа бик кирәкле
Кеше кебек, ашыга-ашыга,
Галошларың салмый, ни дип инде
Килеп кердең, атаң башына?!
Беренче,
Үзең белән салкын алып кердең;
Икенче,
Уйларымны бүлдең;
Өченче,
Ник килдең?
Син сөйләгән тормыш авырлыгын
Сизми йөрим диеп белдеңме,
Шуны сөйләп, бераз минем янга
Сүгнеп чыгар өчен кердеңме?..
Син авырлык күрми-нитми генә
Атаң башын төзмәк телимсең!..
Аз-маз гына кулың эшкә тисә,
Шайтан кебек сүгнеп йөрисең.
Әгәр
Папиросың юкка сүгнеп йөрсәң,
Менә папирос! –
Авызың тыгылсын!
Бу килүең ләкин соңгы булсын,
Башың сынсын,
Килмә артык миңа, суккин сын!

## КУТЕПОВ КАЙДА?

Парижда акгвардеец генерал Кутепов югалган.

*Газеталардан*

Бәлки, салоннарда эчеп утырыр өчен,
Кесәсендә акча беткәндер,
Шуның өчен, арзан кабак эзләп,
Берәр җиргә чыгып киткәндер?!

Париж толчокларын карап чыгыгыз,
Берәр җирдә чалбар сатмыймы
Яки качып кына ялган документлар,
Червонецлар ясап ятмыймы?..

Ә Советка аның кирәге юк.
Тыңла, Париж! –
Безнең теләк сезнең ялага:
Төкерәбез сезнең Кутеповтай,
Керенскийдай шайтан-шабага!

## ЧИГЕНҮ

Парикмахер җаным,
Матурла син мине,
Теләсәң ничек итеп матурла, –
Тик бер генә кабат сөйләсеннәр
Минем матурлыгым хакында...

Якла бүген мине,
Матурларга
Осталыгың булса, аяма, –
Шагыйрь, бәлки, бүген беренче кат
Мәхәббәттә булган көрәшендә
Синең осталыкка таяна...

Тыңла,
Быел язын мин бер кызны сөйдем,
Ә беләсең
(Мин шул бераз тиле икәнмен),
Гомеремдә, бәлки, беренче кат
Шундый каты итеп сөйгәнмен...

Бер хисемне аңар аямадым,
Үзем теләп бирдем барсын да.
Яшьлегемнең соңгы чәчәкләрен
Таптый яздым аяк астында...
..................
Сөю –
Әгәр авыру уен булса,
Ташла, парикмахер!
Сакалым да
Ярты юлда калсын кырылмый,
Төкерәм!
Бер кызына җирнең алмаштырмыйм,
Алмаштырмыйм сыйнфым, –
жырымны!..

Ах, Володя бәгърем,
Бик ялгыштың.
Бай мәхәббәт гомерең көймәсен
Ташка бәрдең.
Ничек күз яшь катыш
Әрнеп, сиңа ачу килмәсен!..
Мәхәббәт ул үлем юлы түгел,
Аны тудыра яшәү ялкыны;
Киләчәккә безнең каныбыздан
Тормыш үтә аның аркылы...
Юк, Володя!
Сөю үлем түгел,
Ул – тик бары
Җенеслекнең канда уйнавы,
Ул – нәселнең канда хәрәкәте,

Канның омтылышы... дулавы!..

Гаилә дә уен өчен түгел,
Ир-хатынның берсе-берсенә
Ярдәме өчен,
Җәмгатькә бирү хезмәтләрен
Юлга кую өчен төзелә.

Көрәшләрдә көчле була торып,
Мәхәббәттә булган уенда
Җиңелү оят,
Сау бул, һәлакәтем,
Минем йөрәк давыл кулында...

– Айлы төннәреңне кайда гына уздырсаң да,
Озын чәчләреңне
Кем теләге белән генә туздырсаң да
Барыбер миңа, синең өчен
Үләр хәл юк, матур булсаң да...

Ташла, парикмахер!
Матурланмыйм,
Матурлыгым минем җитәрлек;
Мин сәламәт,
көчле,
Шул килеш тә
Бик күпләрне гашыйк итәрлек!

## ГАЙБӘТ ТЕЛЕ

Безгә дошман кешеләр шатлык белән
Пычрак бер сүз йөри күтәреп:
«Планнары бетми үтәлеп!..»
Алар һәр очраган җирләрендә
Теш ыржайтып бездән көләләр:
«Болар нәрсә төзи беләләр?»
«Прорыв бара бөтен фронтта!»
«Промфинплан китәр курортка!»
«Ә бишьеллык инде гробка!»

Һәрбер безгә дошман кеше теле
Пычрак бер сүз йөри күтәреп:
«Планнары бетми үтәлеп!..»

Бүген газет буйлап, күзем йөртеп,
Процент цифрларын санадым,
Уңышларны үлчәп карадым.
Күп заводлар безнең күптән инде
Планнарын тутырып ташлады,
Алгы өчен эшли башлады!
Кызыл байрак алып җиңеп чыккан
Эшче полклар һаман арталар
(Артып тора кызыл такталар).
Планнарын үти алмый калган
Заводлар да бездә күренә,
Алар гына менә, оялмыйча,
Гайбәт бирә дошман теленә.
Дошман теле
«Иха-
        ха-ха...»
                килә.
Пычрак бер сүз йөри күтәреп:
«Планнары!..
Ха-ха-ха!..
Планнары бетми үтәлеп!..»
Өзеклек ул җиңелү түгел,
Ләкин
Ул туктата җиңү үсешен –
Һәрбер эшче менә бу нәрсәне
Хурлык диеп белсен үзе өчен!..

## УДАР АРТЫННАН УДАР

Франция матбугаты Пуанкареның авырый башлаганлыгын хәбәр итә. Профессорлар аңа апоплексия удары (баш миендәге кан тамырларының ярылуы аркасында минең эштән туктавы) бәрүен күрсәтәләр.

*Телеграм хәбәре*

Көтмәгәндә килеп төшкән удар
Һәлак иткән француз түрәсен.
«Промпартия»нең[2] башын сындыруы
Авырырлык туры килгән, күрәсең...
Тик бу удар әле бик кечкенә.
Франция өчен якын киләчәк
Шундый каты удар бирәчәк:
Империализмның башы әйләнер,
Күз алларын аның ут алыр,
Паралич сугыр фахиш ми савытын,
Бөтен кан йөреше тукталыр.

**ТУН ТРАГЕДИЯСЕ**

*(Казандагы мех фабрикаларына багышлыйм)*

Быел мин тун алып кидем,
Шаккаттылар,
«Дошманнар»дан
Бик күп көнләүчеләр булганнар...
Ләкин,
Юкка гына,
Уңмадым мин туннан, туганнар...

Кем теккәндер, рәхмәт төшкән нәрсә,
Шундый «әйбәт» теккән иңнәрен, –
Бүген эштән кайтып килгән чакта,
Төшеп кала язды җиңнәрем!..
Җеп очларын рәтләп төенләргә
Әллә вакыты шунда булмаган,
Әллә...
Прогулдан соң ярым исрек баштан
Брак итеп теккән, уңмаган!..

Һәрбер минут, һәрбер секунд өчен
Көрәш бара Совет илендә,
Ә мин һәр көн утрып туным ямыйм,
Өч-дүрт сәгать уза кимендә...

Этләр –
Бәхетлеләр...
Ул халыкның
Өсләренә кигән туннары
Ертылмый да...
Буявы да китми,
Ялтырап кына тора йоннары...
Мин дә кызыгып шундый бер тун алдым
(Эт тиресеннән),
Ә иртәсен ямый-ямый яңа тунымны,
Инә белән чәнчеп, канга батырып,
Җәрәхәтләп беттем кулымны!
Нишлим,
Тун тегәргә дөнья өйрәтмәде.
– Шигырь язып гомер итәрмен! –
Дигән идем...
Инде болай булгач,
Тун тегүче булып китәрмен!..
Нишлисең бит...
Тун алсаң да –
Туның брак булса,
Туфли алып – туфли сүтелсә,
Чуен, чүлмәк алып, чүлмәгеңнең
Кул тимичә чите кителсә,
Башка чараң да юк...
Их, егетләр!
Илдә сыйфат өчен
Көрәш бара
(Оят язарга),
Ә сез, эшегезне рәтләп эшләмичә,
Брак чыгаргансыз базарга!..

Һәрбер минут, һәрбер секунд өчен
Көрәш бара Совет илендә,
Ә мин
Һәр көн утырып сезнең тунны ямыйм,
Өч-дүрт сәгать уза кимендә...

## «ЧАЯН» УКЛАРЫ

### Укытучыны укытырга кирәк

Алабугада зурларны яңалифчә укытучы Җ., мәктәбен бикләп, өч балалы хатыны булуга карамастан, атналар буе чит хатыннар белән гүләйт итеп йөри.

*Алфавит*

Булдыксыз эт карап торып
Саесканнан күзен чукыта,
Мондый укытучының арт сабагын
Яхшы ОНО үзе укыта.

### Безнең теләк

Спас крестьян йортында һич тәртип юк. Өстәлләрендә көн буе пычрак балык кисәкләре аунап ята. Идәннәре пычрак, һавасы сасы.

*Контроль*

Килгән-киткән кешеләр байтак инде
Иснәделәр йортның сасысын.
Инде бездән теләк:
Зав үзе дә
РКИның исен татысын.

### Урмандагы аюга ышанып, туннарын мичкә ягучылар

Элекке Кайбыч районы Чутай авылы «Арслан» колхозы председателе собраниедә начар нәселле сарыкларның бөтенесен суеп ашарга тәкъдим керткән. Ә колхозда әле бер нәселле сарык та юк.

*132*

«Арслан» колхозының предколхозы,
Яхшы эшкә, малай, тотынган.
Бик beләсе килә Сабитовның
Үзе икән кайсы токымнан?
Начар сарыкларны яхшыларга
Алмаштыру кирәк, билгеле.
Ләкин алмаштырмый торып суеп ашау
Головотяплык була түгелме?

### Карга язган карарлар

Әхмәт авыл советы кешеләре 1 нче октябрьдә, 250 сум заем акчасы җыеп, Чаллыга баралар. Чаллыда районлашу барганга, акчаны кая бирергә белми кайтып китәләр.

Ә райисполкомның 100 сум җыелу белән китереп тапшырырга дигән карары бар.

Гаҗәпләнер әйбер юк бу эштә,
Без беләбез, андый абзыйлар,
Карар эшкә ашсын диеп, чын күңелдән
Бер чакта да карар язмыйлар.
Карарны алар карар өчен яза,
Карарларын карлар күмәләр...
Карарларын карга язып, алар

Жалуния ашап гомер итәләр.

### Сабын һәм головотяплар

Вахитов заводының механик цехында завкомның «Вентилятор – друг труда, пусть работает всегда!» плакаты бар. Ләкин завком шул цехта 6 ел вентилятор куймый йөртә.

Головотяплык үзе коньяк түгел,
Ә кешене шундый исертә;
Завкомчының җиңсез күлмәген дә
Чалбар итеп үзенә киертә.
Головотяплык тулган завком башын
Сабын белән юу файдасыз,
Бер җыелышта парлап чыгармыйча,
Вентилятор куйдыра алмассыз.

### Рапорт

(*Казандагы Тукай мәктәбенең культ-эстафета вакытында эшләгән эшләреннән рапорты*)

Кайчан төзәтербез,
Анысы сезгә кирәк түгел,
Ике һәйбәт пичне җимердек,
Хәзер менә бүлмә булмавыннан
Кечке сменага җигелдек.
Балаларга кайнар аш бирү
Куелып китте шундый эз белән,
Бөтен дәрес буе укучылар,
Сугыша-сугыша,
Ашар өчен кашык эзлиләр.

### Фаҗигале хәл

Лаеш районында бик күп авылларда, избиркомга сайлаганда, җәмәгать эшеннән бушрак һәм эше азрак кешеләрне сайларга тырышканнар.

Ялкау:
Их,
Юкка гына ялкауланып йөрдем,
Күрәм, малай, башым жуярлар...
Болай булса, инде Советка да
Эшсез диеп сайлап куярлар.

### Тавыклар газраиле

Кама Тамагында район милиция башлыгы Исаев, халыктан тавыклар җыеп, милиция бәйрәме уздырырга булган.

Дөрес,
Исаев ул яхшы ният белән
Тавыкларны җыймак теләгән...
Ләкин
Кабрең ерак булсын тавык җыеп,
Тавык ашап йөргән түрәдән...

### Даешь кызлы квартир!

Саба районында Хисамиев дигән бер милиционер бар, аны авыл халкы «Хыялый» дип йөртә. Ул, авылга килү белән, авыл советыннан:

– Даешь кызлы квартир! – дип, аяк тибеп, кызлы квартирга урнаштыруны сорап йөри. Күп кенә авыл советлары аның теләген үтиләр. Ул, хәтта бер эше дә булмаса да, шул эш белән авылдан авылга кызлы квартир эзләп, гастроль ясап йөри.

*Ахмак*

Бу хәбәрне безгә язган иптәш
«Ахмак» диеп
Куйган булса да үзенең имзасын,
Саба районының милициясе
Бу турыда әз-мәз уйласын!
Кызлы квартир эзләп, айгырланып,
Шарлатанлык итеп йөрүче,
Милиционерлыкны җавапсызлык,
Хулиганлык диеп белүче
Хисамиев кебек кешеләрне

Милиционер итеп йөртмәсен!
Хисамиев өчен кызлы квартир түгел,
Рәшәткәле квартир эзләсен!

## Көрәк оны

Беренче Май районы Сашмар авылы крестком председателе Ш., авыл советы председателе Х., крестком секретаре М., Сашмар авылының Коопхлеб приемщигы З.лар, тегермән һәм яргыч хуҗалары белән көрәк оны исәбенә эчеп, гүләйт итеп йөриләр...

Көрәк оны, агым су шикелле,
Тегермәннән агып торсын да,
Ни әйтмешли, авылың авыл булып,
Нәчәлникле авыл булсын да,
Нәчәлникләр, имеш, эчмәсеннәр...
– Әйдә, гүләй, Зиннур, сал тагын да, –
Уничтожай совет сырасын...
Соңы ни буласын
Җен уйласын!..

«Чаян»: Похмиләсе начар булмасын!

## Салкында мәхәббәт

Актаныш районы Чишмә авылы укытучысы К. белән шул ук район укытучысы Б., икәүләп бер-беренә гыйшык тотышулары сәбәпле, гомуми-мәҗбүри укыту эшенә күп кенә зарар китерәләр. Авылларның арасы 9–10 чакрым булуга карамастан, авыл советыннан олау алып күрешергә йөрешәләр.

*Сәнәк*

Почта белән килгән зур бер конверт
Яңа хәбәр безгә китерде:
Актанышта ике гыйшык бар, ди,
Таһир белән Зөһрә шикелле.
Совет атын җигеп,
Эш калдырып,
Гыйшык утын эчтә яндырып,
Бураннарда алар йөриләр, ди,
Таһир-Зөһрә кебек каңгырып.

## Кайдан белсен

Әгерҗе колхоз союзы үзенең карамагында күпме колхоз барын белми.

*Газетадан*

Имеш,
Һәр туган көн яңа колхозларның
Арта бару санын китерсен дә,
Колхозсоюз кебек миңгерәү оешма
Кайдан аны белеп бетерсен?!
Эшләүчесе аның шул булса да,
Бик тар аның акыл күләме;
Колхоз – колхоз инде,
Менә үзендәге
Головотяплар санын беләме?

## Культармеец

Әлмәт районы Кичүчат авылында Әхмәтҗан дигән культармеец һәркөн бишвакыт намаз укый, намаздан чыгу белән, белемсезләрне укытырга йөри.

*Гәрәев*

Дөнья малын куып йөри-йөри,
Ахирәте әрәм китмәсен!
Мондый «культармеец»ның артына тибеп,
Күтәртергә кирәк үкчәсен!

## Язга каршы

Кулак

Бу елгы яз
Большевиклар язы икән,
Кирәк түгел, чёрту, килмәсен!
Кар эремәсен!

Сулар катсыннар!
Кыш айлары җиргә кире кайтсын,
Тукталсыннар сулар, ташкыннар!

Кояш

Мин коммунист түгел,
Ә шулай да
  Карлар эреп, бозлар китәрләр,
  Сулар агар,
  Колхоз кырларында
  Игеннәр дә күкрәп үсәрләр!

**Совет председателеме, мулламы, әллә бер колгамы?**

Норлат районы Мулла Иле авыл советы председателе белән секретаре, партия әгъзалары, бу ел мулла белән бер сафта торып гает укыдылар.

*245*

Мулла Иле авылы булсын да,
Коммунистлар динле булмасын...
Мулла Иленең һәрбер коммунисты
Алмашырлык авыл мулласын!
Авыл секретаре кирәк булса,
Шәп коммунист мөәззин булала.
Персидәтел-мулла,
Кирәк чакта
«Әлхәм» укып имам торала...
Коммунистлык белән муллалыкның
Аермасын монда тапмассың...
Тик бу егетләрнең тәпиләре
Контролькага килеп капмасын!

**Өч джимми**

Язу машиналар фабригының дирекциясе, ударник эшчеләрне бүләкләү өчен, «Спартак» заводыннан өч пар итек, өч пар джимми алалар. Фабрикның директоры, фабком председателе, завхоз бу әйберләрне тигез итеп үзара бүлеп куялар...

Эшче станокта удар эшли,
Ә
Түрәләргә менә килгәндә,
Алар ударниклык күргәзәләр:
Акча алганда,
Әйбер бүлгәндә...
Өч пар итек, өч пар джимми
Моңа яхшы мисал түгелме?..

**Ике тегермән**

Салагыш районы «Кызыл Октябрь» колхозының ике су тегермәне тик ята. Тик ятуларына ел тулды инде. Әйләнеп караучы юк.

*Гаптул*

Колхоз тегермәне әйләнмәгән,
Он тартмыйча яткан урында
Кулак тегермәне бертуктаусыз
Гайбәт тарта колхоз турында...

## *1931*

### СЪЕЗД АЧЫЛДЫ

*(Татарстан Советларының IX съезды ачылганда)*

Алкыш уртасында
Моратхуҗин
Килеп баса съезд алдына.
Караңгы зал кинәт яктырып китә,
Прожекторга утлар кабына,
Киноаппаратлар эшли башлый,
Оператор чаба, ашыга...
Кул чабалар, алкыш уртасында
Тугызынчы съезд ачыла!

*

Моратхуҗин
Үзенең тәбригендә
Матур сүзгә артык бирелми,
Уңыш цифрларын залга сибә.
Залда
Җиңү күренә,
Җиңелү күренми!
Җиңү съездына керер өчен,
Мандат бирелмәгән аңарга!
Менә Бондюг
Алкыш уртасында
Уңышларын чыга санарга!
Ул үзенең сүзен зур съездның
Алкышлавы белән бетерә,
Аның урынын алып,
Мех фабригы,
Ленин заводлары
Җиңү речен дәвам иттеләр!..
Алардан соң йөз мең хуҗалыклы
Колхоз вәкилләре сүз ала,
Зал алкышка күмелеп дулкынлана,
Зал аякка баса, кузгала.

*

Радио эфир аша Җир шарына
Социализм иленең җиңүен
Хәбәр итә!
Татарстан бүген радио аша
Тыңлый үзенең йөрәк тибүен!

*

– Пионерлар бик күп эшләгәннәр:
Утильсырье бик күп җыйганнар,
Бик күп өй куяны үстергәннәр,
Кырда меңләп йомран буганнар...
Алар бүген шуны шатлык белән
Залга чыгып хәбәр итәләр,
Аталары белән бергә көрәшергә
Вәгъдә биреп чыгып китәләр!..
Әйе,

Пионерлар бик күп эшләгәннәр:
Бик күп йомыркалар җыйганнар,
Орлык чистартканнар...
Көлке түгел болар, туганнар!
Бездә,
Җиде яшьтән алып җитмешкәчә,
Картлар, яшьләр, нәни балалар
Тик бер теләк белән яналар:
Авырлыкка-нигә карамастан,
Бишьеллыкны дүрттә үтәргә!
Бишьеллыкның соңгы өч елында
Колхозларга күчеп бетәргә!

Җиңү съездының көн тәртибе
Шушы зур нигезгә салынган.
Без бу теләкләрнең юлын сызып
Таралабыз съезд залыннан!

**МИН ДЕЗЕРТИР БУГАЙ, КОМАНДИР!**

*(N нчы укчы татар полкына багышлыйм)*

Чакыруыңны көтми,
Мин үземне
Мобилизовать иттем, командир!
Бүген сезнең белән бер аякка
Басып йөрер өчен рөхсәт бир!
Күптән инде шулай бер аякка
Йөрегән юк, –
Бүген беләсең...
Тфү!
Тагын ялгыш атлап куйдым,
Оныта башлаганмын, күрәсең...
Постын ташлап качкан суккин сынны
Тотып алып килгән шикелле,
Йөрәгем бүген мине
Сезнең янга
Арестовать итеп китерде...
Мин дезертир бугай...
Командир!
Җырчы исемен тагып йөрсәм дә,
Сезгә җыр кирәген белсәм дә,
Бүгенгәчә,
Алдыбызда торган бурычларның
Онтылмаска тиеш җирләрен
Окопларда җырлап искә алырга
Җырга салып язып бирмәдем!..
Безнең халык шулай, –
Күп сөйлибез,
Пролет-шагыйрь исеме даулыйбыз,
Ә үзебез, эшкә килгән чакта,
Әллә кая китә алмыйбыз!
Бүген иртүк торып,
Мин үземне
Мобилизовать иттем, командир!
Сезнең белән бергә,
Бер аякка
Басып барыр өчен рөхсәт бир!
Дөрес,
Киемнәрем минем шинель кебек
Матур булып өскә ятмыйлар,
Аяклар да әнә!
Күз алдында
Адым саен ялгыш атлыйлар!
Кулга мылтык алсам
Әле,
Пулялар да
Кеше хуры итеп бетәрләр,
Кирәк җиргә барып эләкмичә,
«Сөт эзләргә» очып китәрләр...
Ә бит
Көрәш якын,
Канлы Европада
Зур әзерлек моңа сизелә,
Шуның өчен бүген арагызга
Урын эзләп килдем үземә!
Әле
Сугыш башланмаган,

Әле
Тыныч тора сезнең сафыгыз;
Ә шулай да
Мине бүгеннән үк
Доброволец итеп алыгыз!

## НАРКОМПРОС ҖЫРЛАРЫ

«Кызыл Татарстан» газетасы каршында үткәрелгән культбригадлар киңәшмәсендә сөйләнгән докладлардан Татарстан Наркомпросының урыннардагы уку-укыту эшләре белән юлбашлык итүе артык начар булуы аңлашылды.

Ленинград округы
Наданлыкны бетерде.
Татарстан Наркомпросы
Наданлыкны бетерү планын
Яңа төзеп өлгертте.

*

Гыйлем кешеләр утыргач та
Наркомпрос эчендә,
Баш китәрлек наданлыклар
Булмас диеп уйламагыз
Наркомпрос эшендә.

*

Алмагачтан төшкән алма
Ерак китми үзеннән.
ОНОлары, РОНОлары
Эшсезлектә калмый бара
Наркомпрос эзеннән...

Кулланмалар җибәрмичә,
Интектереп бетәләр,
Урыннарда РОНОлары
Рано или поздно шунда
Бер килер дип көтәләр.

*

Инструкторлары бар;
Кәгазь ябынып йоклыйлар;
Кыш суык дип, яз яңгыр дип,
Урыннарга тикшерергә
Еллар буе чыкмыйлар...

*

Ышанып торсаң мондый әйбәт
Инструкторларга,
Наданлыкны бетерербез
Ике мең дә биш йөз утыз
Йә кырыгынчы елларга...

## КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР

### Хатның адресы

Бу хат киләчәкнең билгесез бер
Кешесенә атап язылган.
Исеме безнең чорга мәгълүм түгел,
Фамилиясе баба ягыннан
Нигъмәтуллин булыр,

Хатны алырга тиеш булган бу кешенең
Исемен,
Адресын
Белмим.
Шуның өчен хатны ачык язам,
Аны һәркем укый алачак.
Хатым, бәлки, кулдан кулга күчеп,
Ул кешене эзләп табачак.

**Беренче хат**

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын...
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исмем сезгә җитмәс – онтылыр...
Ләкин
Теләкләрем минем сезнең чорда,
Сезнең кырда чәчәк атачак,
Җансыз гәүдәм шушы теләкләргә
Азык булып җирдә ятачак...
Миннән соң туачак җырчыларның
Даны күмәр минем атымны,
Ләкин
Еллар, сезгә зур бер легенданы
Саклап алып барган шикелле,
Алып барыр шушы хатымны...

Сез бу хатны минем укыганда,
Авыр еллар үткән булырлар;
Җирдә коммунизм булган булыр,
Безнең дәвер халкы онтылыр...
Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз, –
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз.
Без үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Көрәшендә
Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз;
Без яңа җир,
Яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз...
Без беләбез сезнең киләчәкне,
Без беләбез сезнең киләсен,
Без беләбез алгы көрәшләрнең
Безгә җиңү алып бирәсен!
Бу хат сезгә барып ирешкәнче,
Сезгә мирас булып калачак,
Җир өстендә

Безнең колонналар
Соңгы крепостьны алачак!..
Бу фронттан бер хат:
Бу хат минем
Күкрәк хисләремнең җылысын
Саклый алып сезгә илтсә дә,
Сәламнәрем барып җитсә дә,
Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исмем сезгә җитмәс – онтылыр...

Кемлегемне,
Нәрсә эшләвемне
Язмыйм сезгә;
Дөресен әйтәм,
Мин гомремдә
Бик күп анкеталар тутырдым,
Һәрбер анкетамны тутырганда,
Теләгәнчә алдап утырдым...
Бу шаянлык өчен гаепле мин
Төрле чиновниклар алдында,
Ләкин,
Анкеталарда бик күп алдасам да,
Җырларымда – һичбер вакытта...
Мин сыйныфның бөек көрәшенә
Артык айнык килеш карадым;
Һәрбер юлым, һәрбер хисем өчен
Мин үземне мәсьүл санадым!
Ә бит
Һәр дәвернең үзенең чире була
(Һәрбер чирнең була докторы),
Һәр заманның була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры)!
Кичерегез,
«Сволочь» дип безнең заман халкы
Начар кешеләрне йөрттеләр,
Еллар оныттырыр...
Ләкин
Алар безнең
Теңкәбезгә тиеп беттеләр...
(Хатларымда шушы кешеләрнең
Кайберләрен язып үтәрмен,
Аңлатмалар биреп китәрмен...)
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Мин бу хатны сезгә зур атака
Башланасы еллар алдыннан
Хисләремнең тиле дулавына
Карышалмый язып калдырам...
Без беләбез сезнең киләчәкне,

Без беләбез сезнең киләсен,
Без беләбез соңгы көрәшләрнең
Безгә җиңү алып бирәсен!

**Икенче хат**

Сезгә хат язарга утыру белән,
Кинәт хат язуны
Артык зур эш диеп санадым;
Сезгә язар өчен, зур фикерләр,
Проблемалар эзләп карадым...
Ә беләсез, нинди уйга килдем:
Сезнең заман халкын
Минем «философлык»,
«Даһи җырчы» булу белән дә
Шаккатырып булмас
(Аннан
Даһилык та
Сирәк йөри минем тирәмдә...).
Бер чакны без шулай Горький белән
Бер мәҗлестә бергә утырдык,
Әллә ничек аның сул ягына
Туры килде минем урындык...
Горький – безнең чорның зур әдибе.
Аның даны
Бөтен планетага таралган,
Ә мин үземне бер бик кечкенә
Кеше итеп сиздем аңардан...
Башта аның белән сөйләр өчен,
Зур гакыллы сүзләр эзләдем,
Тирләп беттем...
Ә соңыннан инде түзмәдем,
Башта булган гади уйлар белән
Башлап алып киттем сүземне,
Ә бераздан яхшы ук акыллы бер
Кеше итеп сиздем үземне!..
Сезгә хат язарга утыргач та,
Үземне мин
Шундый ук бер хәлдә санадым,
Сезгә язар өчен, айлар буе
Проблемалар эзләп карадым.

Ә соңыннан
Минем проблемалар сезнең өчен
Кызык булмас диеп уйладым.
Шуның өчен мин бу кыска хатта
Зур фикерләр алга куймадым...

Дөрес,
Без сыйныфлы тормыш ярларыннан

Сыйныфсызлык ягына күчәбез,
Һәрбер проблеманы үзебезнең
Файдабызга карата чишәбез.
Бездән алда булган җәмгыятьнең
Тормыш шартларына яраган
Һәр карашны, һәрбер проблеманы
Без төзәбез баштан, яңадан.

Бездә
Сыйнфый көрәш хәзер фронтлардан
Бөтен почмакларга күченә;
Һәр гаилә ике каршылыкның
Берләшүен ала эченә...
Күптән түгел мин бер алтмыш яшьлек
Мохтар картны юлда очраттым,
Махра борып, икәү сөйли торгач,
Колхоз хәбәрләрен сораштым...
Ул авылда тыршып колхоз төзегән,
Оештырган ярлы, ялчыны,
Шул эш өчен аны кочагыннан
Мәхрүм иткән сөйгән карчыгы...
«Бар, колхозың белән йокла», – дигән,
Өч-дүрт айлар
«Җылы куенын» карчык ачмаган,
Мохтар бабай ялгыз йокласа да,
Колхозын ул ташлап качмаган...
Бездә һәр гаилә хәзер каршылыклы,
Бик күп кешеләр икегә бүленә.
Мохтар бабай сөйли:
«Мин, – ди, – менә
Дошман булып йөрим үземә...
Элек чакта мин бер кеше идем,
Хәзер, малай, миндә ике «мин»:
Берсе менә аның коммун яклы,
Икенчесе каршы, суккин сын!»
Мин аңардан:
«Ничек алай?» – дигәч,
Ул бер кызык мисал китерде:
«Пример, без колхозга кергәч, ат-сыерлар
Һәммәбезнең күмәк ителде...
Әйтик,
Аны шулай эшләү кирәклекне
Гакыл белән мәгъкуль күрәсең,
Ә эчеңнән һаман:
«Бу бит әле
Минем ат», – дип йөри бирәсең...
Туры килгән чакта «үз атыңа»
Азыкны да мулрак бирәсең.
Пример,
Бервакытны шулай сабан өсте,

Кырда бергә сабан сөрәбез...
Минем атым юаш булганлыктан,
Бер малайга җигеп бирәбез.
Малай алда йөри, мин артыннан,
Үзем йөрим, үзем сагалыйм,
Минем атны суга-нитә калса,
Тотып яңакларга чамалыйм...
Малай, дөрестән дә, сугып куйды,
Белмәмешкә башта салыштым,
Тагын суккан иде,
Түзалмадым,
Якасына барып ябыштым...

Ә бер чакны минем атым үлде,
Карчык елый, карчык үкерә,
Атсыз нишләрбез, ди, чәчен йолкый,
Үрле-кырлы, малай, сикерә...
Мин үзем дә башны аска салдым,
Нишләрмен, дим хәзер эчемнән, –
Атның бергәлек ат булганлыгын
Тәки чыгарганмын исемнән...
Колхозчылар килеп кергәч кенә
Исемә төште ялгыз түгелем, –
Шатлыгымнан коммун була яздым,
Шундый күтәрелде күңелем!..
Әгәр шунда, пример, ялгыз булсам,
Нишләр идем ялгыз берүзем?
Менә бит ул күмәк хуҗалыкның
Файдалыгы кайда, иккүзем!..»

Бездә һәр гаилә хәзер каршылыклы,
Бик күп кешеләр икегә бүленә;
Мохтар бабай кебек, күпләр әле
Үзе дошман бүген үзенә...
Чөнки канга сеңеп калган иске гадәт,
Иске караш, иске йолалар
Яңа кешенең туып үсүенә
Киртә булып чыгып торалар...

Сез бу хатны минем укыганда,
Бик күп еллар үткән булырлар;
Җирдә коммунизм булган булыр,
Безнең дәвер халкы онтылыр...
Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз;
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз...
Без үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Көрәшендә

Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз;
Без яңа җир, яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз!..

Безнең гомер бөек планетаның
Шау-шулы бер чорына очрады;
Планетада бүген зур дау бара,
Ыгы-зыгы
Килеп тора бөтен почмагы.
Мин бу дауның үткән тарихына,
Бездән алда булган чорына
Туктап тормыйм,
Бары бүгенгене
Сюжет итеп алам җырыма.
Ә бүгенге –
Сыйнфый катлауларның
Соңгы каты көрәш заманы;
Без, искене җимреп, планетада
Тигез тормыш,
Матур,
Яңаны
Төзү уе белән янабыз.
Һәм без шуның өчен илебездә
Зур тазарту алып барабыз!

Моннан элек сезгә язган хатым
Әле юлда бара,
Аңарда
Мин вәгъдә сезгә биргән идем
Бүгенгенең
Кайбер күрнешләрен язарга...
Әйе,
Безнең чорыбыз кызык,
Чуар бер чор,
Безнең илебез дә әле катлаулы:
Һәр мактаулы
Эшче күршесеннән
Табып була мәшһүр ялкауны!

Әле
Хлестаковлар бездә, портфель тотып,
  Инженерлык итеп йөрсәләр,
  Учреждение саен алар өчен
  Городничийлар табыла дистәләп...
  Әле һәр ялагай безгә иртә саен
  Ялкауланмый бирсә сәламен,
  Һәр бюрократ әле безнең эшкә
  Китереп тыга кәгазь-каләмен!..
  Безнең илдә әле дошман сыйныф

Нәслен саклап калу юлында
Көрәш алып бара,
Корткыч кулын сузса һәр урынга,
Һәр кулакның обрез кулында...
Ярлы-ялчы колхоз эше белән
Җыелыш ясап торса төннәрен,
Таң атуга, тәрәз төпләреннән
Табып була кулак эзләрен...
Бүгенге ул – сыйнфый катлауларның
Соңгы каты көрәш заманы,
Без, искене җимреп,
Планетада
Тигез тормыш,
Матур,
Яңаны
Төзү уе белән янабыз!
Һәм без планетаны сыйныфлардан
Тазартуга табан барабыз!

Без унөч ел бөек илебезне
Дошман сыйныфлардан сакладык,
Без гигантлар төзедек
Һәм без инде
Социализм чорына атладык!
Хәзер
Бөлгенлеккә төшкән буржуа иле
Теләсә генә ничек итсә дә,
Безгә блокадалар ясау түгел,
Борны белән чәнчелеп китсә дә,
Без җиңәрбез!
Бөек планетаны
Үзебезнең кулга алырбыз,
Ерак илләр күкрәгенә
Тик бер байрак –
Безнең байрак белән барырбыз!
Хыял – безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер теләк – якын киләчәк!
Һәрбер колхоз, һәрбер гигант совхоз
Яшәү көче безгә бирәчәк!
Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә, –
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә...

## Өченче хат

Кем дип башлыйм,
Кем дип исмең куйыйм,
Кем дип атап сиңа эндәшим?

Кем син?
Белмим!
Менә шуңа күрә
Мин просто сиңа:
«Иптәш!» –
Дим.
Сыйныфларның соңгы бәрлешүе
Якынлашып килгән көннәрдән,
Мин беренче кеше булып бугай
Сезнең чорга хәбәр җибәрәм...
Тавышым ерак еллар күкрәгендә
Яңгырый алсын!
Хатым сиңа җылы хисләремне
Алып барсын.
Ерак үткәннәрдән хәбәр алу,
Белмим, сиңа кызык булырмы?
Тик
Бер вакыйга бүген миндә сиңа
Хат җибәрү фикрен тудырды.
Хатым көтелмәгән нәрсә булса,
Гаҗәп түгел,
Мин бу хатымда
Сиңа көтелмәгән нәрсә язам.
Ул да –
Синең бабаң хакында...
Сезнең чорда, шиксез, социаль чыгыш
Зур бер нәрсә итеп каралмас.
Кемнең кемнән тууы, атасының
Кем булуы гаеп саналмас...
Безнең чорда әле бу нәрсәләр
Зур бер әйбер булып санала
(Матур кызның йөзенә караудан да
Элек анкетасы карала).
Чөнки
Безнең илдә әле дошман сыйныф
Нәслен саклап калу юлында
Көрәш алып бара...
Корткыч кулын суза һәр урынга,
Һәр кулакның обрез кулында...
Менә шушы бөек, инәлүсез,
Канлы көрәш барган чагында,
Сезнең чорның кайбер кешеләренең
Бабалары дошман ягында...
Бөтен Җир шарында
Алар белән безнең соңгы бәрелеш көне
Ерактамы, әллә якынмы,
Ни булса да, шулар турысында
Сиңа язам мин бу хатымны!
Бит,
Без дошманны сыйныф итеп җимерсәк тә,

Аның нәселе җирдә калачак,
Һәм ул нәсел, үзенең сыйнфый йөзен
Җуеп, киләчәккә барачак...
Бүген, мин заводтан кайтып килгән чакта,
Кызыл гаскәр белән уралган
Йөзләп кулак
Салмак адым белән
Узып китте зур бер урамнан...
Аларның да җирдә нәсле калыр!
Менә шул юлларны язып утырганда,
Күршем утыра минем янымда,
Безгә яшрен нәфрәт хисе белән
Агу ага аның канында...
Ә бит
Нәсле җирдә калыр аның да...
Учреждение саен «агай-эне»,
Почмак саен прогул ясаучы,
Колхоз саен ялкау табып була, –
Эшләмичә ятып ашаучы...
Аларның да җирдә нәсле калыр;
Безнең чорның бик күп шарлатаны
Сезнең чорга бабай саналыр...
Әйе,
Безнең сыйныф якты тормыш өчен
Көрәш алып барган чагында,
Сезнең чорның кайбер кешеләренең
Бабалары дошман ягында...
Кем соң синең бабаң?
Бу көрәштән
Ул читтәме,
Безнең сафтамы?
Әллә ул да шулай безгә каршы,
Безгә дошман булган яктамы?
Кем соң синең бабаң?

Аны мин тик бары бер-ике кат
Күреп калдым
Бик кыска бер вакыт эчендә;
Хәзер инде менә күз алдыма
Китералмыйм аның төсен дә...
Аның чәче кара иде бугай...
Йөзе...
Хәтерләмим, чыккан исемнән...
Ул сәхнәдә ялгыз
Басып тора,
Тирләр агып тора битеннән...
Аңа кадәр бик күп заводлардан
Трибунага чыгып, эшчеләр
Үзләрендә булган уңышларны,
Өзекләрне санап төштеләр...

Зал тын,
Залда сыйныф утыра.
Синең бабаң сыйныф каршында.
Ул сөйләргә чыкты,
Ул заводын
Яклап чыкты сыйнфы алдында...

Ул эшләгән завод бүгенгәчә
Иң алдынгы завод саналды,
Кызыл байрак алды,
Бөтен җирдә
Үрнәк завод булып каралды.
Бүген директорның докладыннан
Заводының артта калуын,
План үтәлмәвен,
Цехларында –
Бөтен җирдә прорыв баруын
Зал тыңлады.

Зал тын.
Залда сыйныф утыра.
Синең бабаң сыйныф каршында.
Ул сөйләргә чыкты,
Ул заводын
Яклап чыкты сыйнфы алдында.
Кинәт
Ул ашыгып кулын күтәрде дә
Зал өстенә күзен төбәде,
Көне-төне тырышып эшләгәнен
Ул әйтергә залга теләде...
Ул бүгенге бөек көрәш куйган
Бурычларны яхшы белгәнен,
Шушы бурычларны үтәү өчен,
Бөтен иҗат көчен биргәнен
Ул әйтергә залга теләде...
Ул бүгенге бөек төзелешкә
Айнык бер күз белән каравын,
Заводында барган прорыв өчен
Үзен мәсьүл итеп санавын
Ул әйтергә залга теләде...
Ул үзенең һәрбер эшче өстенә
Төшкән бурычларны аңлавын,
Заводының артта калуын да
Бертөрле дә аклый алмавын
Ул әйтергә залга теләде...
Тик ул әйтә алмады...
Кулы,
Буш һавада үзенә тотыныр өчен,
Әйбер табалмаган шикелле,
Салмак кына түбән салынып төште,

Башы җиргә табан иелде...
Мин аңарда чиксез яну күрдем
Бүгенгенең бөек эше өчен,
Мин аңарда күрдем бүгенгенең
Туып килгән яңа кешесен!..

Зал тын гына аңа карап торды,
Зал аңардан күзен алмады.
Ул бер сүз дә залга әйтмәсә дә,
Зал йөрәген аның аңлады.
Шуннан...
Авыр гына кузгалды да
Әкрен генә читкә атлады,
Ә
Залга чыгу белән, читкә утырып,
Йөзен кулы белән каплады...

Беренче кат
Бабаңны мин менә шунда күрдем,
Бик кыска бер вакыт эчендә;
Хәзер инде менә күз алдыма
Китералмыйм аның төсен дә...
Шуннан соң мин аны, теләсәм дә,
Очраталмый йөрдем ничектер...
Тик мин бүген генә аның хакында
Бик шатлыклы хәбәр ишеттем:
Ул яңадан үзенең заводында
Байрак өчен көрәш башлаган,
Иптәшләре белән бергәләшеп,
Ярыш лозунгысы ташлаган!

Тавышым ерак еллар күкрәгендә
Яңгырый алсын!
Хатым сиңа җылы хисләремне
Алып барсын!

## МЫЛТЫК ҖЫРЫ

Биләр районының К. Морза авылында колхоз идарәсе, 160 килограмм колхоз икмәге биреп, частниктан бер ау мылтыгы алган.

*Килгән хәбәрләрдән*

Ун пот биреп, мылтык алдык,
Үрдәк атарга бардык.
Ярамаган мылтык алып,
Икмәкне суга салдык.
Ай-ли, вай-ли,
Икмәкне суга салдык.
Көннәр буе йөрсәк тә,
Тотмадык бер үрдәк тә.
Ай-ли, вай-ли,
Тотмадык бер үрдәк тә...
Тотмасак та кайгырмыйбыз,
Үзебез хуҗа икмәккә...
Ай-ли, вай-ли,
Үзебез хуҗа икмәккә...
Теләсәк – «уңга», теләсәк – «сулга»,
Теләсә кая барабыз.
Ай-ли, вай-ли,
Теләсә нишли алабыз!

«Чаян»

Ауга чыккан чагыгызда
Саклык белән йөрегез!
Ай-ли, вай-ли,
Тик каранып йөрегез!
Артыгыздан үткен күзләр
Тикшереп йөри, белегез!
Ай-ли, вай-ли,
Кыска булыр гомрегез!

# ЯЗЫЛУ ВАКЫТЫ БИЛГЕСЕЗ ШИГЫРЬЛӘР, ПАРЧАЛАР

* * *

Күрәсеңме,
Әнә күрәсеңме,
Сукачылар нишли кырыңда –
Җырла менә шулар турында.
Сукачылар,
А-у-у-у... сукачылар...
Алар белән тулы яланнар,
Язгы төнне җырлап каршылыйлар,
Ягып куеп утлы таганнар...

*

Калма, Такташ,
Әйдә киттек, җаным,
Инде сине моннан мәңгелеккә
Алып киткән бунтарь йөрәгең!
Сау булыгыз, авылым!
Минем күңелем
Хәзер инде шәһәр кулында,
Ләкин мин онытмам сине,
Антлар бирәм
Менә шушы баскан урында.
Озакламас, минем иптәшләрем
Сезгә сәлам белән килерләр,
Тимер айгыр китреп бирерләр!

* * *

Кечәге матурлык бүген үлсә,
Бездә туа аның яңасы.
Безнең тупас куллар – киләчәктә
Туар матурлыкның анасы.
Бүгенгене мактап җырлаучылар!
Укымыйлар диеп тормагыз, –
Туып килә торган давыл елларының
Кисәкләрен алып җырлагыз!
Бүген тыңламыйлар икән безнең җырны,
Иртән тагын җырлап үтәрбез,
Берсекөнгә матурлыгы белән җырыбызның
Без тыңларга мәҗбүр итәрбез!

* * *

Җир турында матур бер җыр бар, ди,
Тик җил генә аны белә, ди;
Кәефе килгән чакта шуны җырлап,
Җирне үртәп, һаман көлә, ди.
Җир кайчандыр айны үбәм дипме,
Әллә ни өчендер куып йөргән, ди;
Кояш, аны күреп тотып алып,
Кирәгенме шунда биргән, ди...

## АЛЬБОМГА

Һавалардан төшкән метеорлар
Сүнәр тагын, кабат яна алмас...
Шат йөрәгем сиңа бирер идем,
Синең йөрәк каршы ала алмас.

* * *

Туфан йоклый.
Бытие хәрәкәттә.
Ә ул йоклый,
Зур хисләрен эштән туктатып,
Колачларын җәеп йоклый шагыйрь...
Кузгатмагыз,
Әйдә йокласын!
Ул бүгенге төнен билгесез бер
Кыз артыннан йөреп югалткан,
Хис җепләрен кызга сүтә-сүтә,
Караңгыда
Табалмаслык итеп чуалткан
Да,
Йокылары калган,
Хәзер йоклый.
Аның бишьеллыгы
Ел ярымда үтәп өлгергән,
Кәгазь, көрәктәй каләме бар,
Шигырь стройлары тезелгән...

* * *

Һәр өйрәнчек тәнкыйть язучылар
Һ.Такташны мишень итәләр,
Өйрәнчек яшь хирурглар кебек,
Минем әсәрләрдә «опыт» ясап,
Үтмәс пычак белән кисәләр...
Неужели үтерүдән курыкмыйлар?!

* * *

Кулың бир дә күземә туры кара,
Син шул алай итә алмыйсың.
Һәрбер хәрәкәтең таныш миңа,
Һәр сүзеңдә мине алдыйсың...
Мин ышанган булам сиңа,
Син тилегә мине саныйсың.

* * *

Син һәрвакыт, миңа очраганда,
Әкрен генә көлеп үтәсең;
Кешеләр күрсә, әллә нәрсә уйлар,
Алай итмә, оятлы итәсең!

* * *

Кырым матур, диләр.
Барганым юк,
Юлы ераграк барырга.
«Барабыз»да гына җитеп булмас.
Болай...
Билет кирәк алырга.
Син, Галимҗан абый, үпкәләмә,
Такташ сине артык сагына,
Тик баралмый гына янында...
Кырым күге сиңа саулык бирсен!

* * *

Казан кар астында күмелеп ята,
Карлар күмгән йортлар арасын...

Һәр чатында чиркәү басып тора,
Гөмбәзләре күккә сузылган.

Тротуарлар тулы кеше белән,
Бар да ашыга, бар да чабалар...

Карлы урамнарны ярып үтә
Юрга атлар, җиңел чаналар.

* * *

А, партия!
Синең иртәгеңә бару өчен
Авырлыклар аша үтү кирәксә,
Безнең бүген күргән авырлыклар
Җиңүең өчен файда биралса, –
Шатлыгым да, янар яшьлегем дә,
Җырларым да сиңа булсыннар...

# УРТАК ИҖАТ

**ҖИРДӘН СӨРӘБЕЗ!**

Мең өч йөз еллар шәрекъ күген
Каплап торган тәрәт чүпрәген
Яндырабыз бүген! Кемнәр каршы?
Мөәзиннәр, ишан, муллалар.
Тагын кемнәр? Сана!
Кулак, нэпман, мещан чурбаннар!
Әй сез, ботка каракдары!
Бәлеш бүкәннәре!
Яңа хәбәр сезгә – тыңлагыз!
Гасырларча миллиард йөрәкләрне
Чертеп килгән диннәр төрмәсен
Яндырабыз! Тупка тотабыз!
Елыйсызмы?
Әй сез, мәчет бандитлары!
Чебен телләр,
Кабер корты – йонлы колаклар!
Әй сез, чиркәү күселәре!
Базар бакалары! Кулаклар!
Бүген сезгә үзегез мактап йөргән
Җәннәтләргә билет бирәбез!
Юнәлегез!
Марш Аллагызга!
Җир өстеннән сезне сөрәбез!

## ХӘЛИФӘЛЕК ТРАГЕДИЯСЕ

ПРОЛОГ

Истанбул дигән, ай, шәһәрнең
Кич ахшамсыз капкасы ябылмый;
Зур сарайлар, тәхет, хәлифәлек,
Сатып алыйм дисәң, табылмый.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Штаттан тыш калган Габделмәҗит
Истанбулдан
              китте, ну... и... вот!
Димәк, солтан хәзер безработный...
Нишләргә соң?
Корсак утыз пот,
Алтмыш кәләш
Мәмәй сорыйлар:
«Ефәк пәләй, – диләр, –
Давай», – диләр.
Бирмим дисәң инде – кыйныйлар.
Нужда, брат!
Солтан аптырады,
Фәсен салып уйлап торды да,
Күсе койрыгыдай мыекларын
Туда-сюда тартып борды да
Швейцариягә табан юнәлде.
Тәти хатыннары койрык булып,
Кайсы җиңеннән,
Кайсы чабудан
Эләктергәч, малай, хәлифәбез
Үрле-кырлы сикерә ачудан.
Бу баштарак әле,
Соңга табан...
Соңга табанмы? –
Эшләр читенләште тагын да:
Ипи бетте.
Солтан чагында
   Кигән киемнәр дә,
   Чалбарлар да
   Тетелделәр.

   ...Шулай, тузан иләп,
   Бер шәһәргә барып керделәр.
   Гомер буе мондый әкәмәттән
   Мәхрүм торган урам этләре
   Ду-у килделәр:
   Бөек хәлифәне
   Бик тиз генә чорнап алдылар;
   Кайсы солдат,
   Кайсы вәзир ролен алып,

Өрә-өрә саклап бардылар.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Өченче көн инде хәлифәнең
Корсагында бүре концерты.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хатыннары дисәң? –
Сорама да;
Шундый хәлләр, Бохар шәкерте!
Бер бармаса эшләр бармый икән;
Хатын дигәннәрең беркөнне
Йорт эчендә гауга салдылар.
Шуннан
Нәрсә булды?
...Ансын солтан белә
(Печтик кенә тәпәп алдылар).
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Яңа хәбәр:
Солтан хатыннардан колак какты.
Мескен...
Нишләсен?
Ялгыз калгач, башка эш юк инде,
Утырды да
Үксеп елады.
Аннан,
Болай диеп, трубкасын кабып җырлады:
«Ислам шәригатен боздылар,
Нәмәхрәмнәр белән сыздылар.
Әллүки...»

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Корсак, знать-не знаю, ди,
Икмәк сорый.
Анысын инде кайдан табарга?
Чалбар төпләрем дә аузын ачкан,
Хатын да юк аны ямарга.
..................

Чалбар, чалбар!
Син дә ертылгансың,
Нигә инде болай итәргә? –
Беләсең бит хәлне...
Әл-л-лү-ки!
Хәзер инде кая китәргә?
Хезмәт биржасына? –
Эшли белмим.
Ни булса да әйдә – черт с ним!
Тыныч тормышымны боздылар,

Хатыннарны урлап сыздылар,
Әллүки...

Хезмәт биржасының сотруднигы
Хәлифәгә карап торды да:
– Әһә, үзе килде,
Син – клоун?
Солтан:
– Мин хәлифә!
– Нәрсә?
– Хә-ли-фә!!!
– Атаң башы!
Артык сорап тормый,
Озаттылар аны циркка.
. . . . . . . . . . . . . . . . .
Ул шул көннән
«Көлке шаһы» булып
Әле дә хезмәт итә циркта.

ЭПИЛОГ

Дини идарәләр хәзердә дә
Һәр җомгада әһле исламнан
Үтенәләр
«Бөек» хәлифәне
Искә төшереп дога кылуын,
Ә хәлифә – мәшһүр Габделмәҗит?
Европада солтан... клоун!
...................

# Әсәрләрнең вариантлары, тәмамланмаган кисәкләр

*** * ***

Без кояшлы язның чәчәкләрен
Үзебезчә җырлый белербез.
Безгә кирәк булган матурлыкны
Үз кулыбыз белән төзербез.
Шайтангамы сезнең кырпу бүрек,
Кыска чалбар, читек-кәвешләр,
«Йомшак мендәр», «рәхәт, тыныч төннәр»,
«Яхшы заманнар»ны көтүләр...
Күптән инде җиргә күмелде,
Сезнең кояш сүнде,
Шуның өчен син дә үл инде!

## МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ

**Кышкы чәчәкләр**

*(Үләчәк кешеләр турында)*

Мәхәббәт –
Иске тема,
Ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта.
Үлмим әле,
Тәңкә карлар ява,
Үлмим әле,
Кышны кирәк күреп үләргә;
Бу дөньяның салкын кышында да
Кызык табыла әле җүләргә.
Дөнья матур,
Әйтче, кем үләр соң,
Җилләр кардан юрган сырганда.
Әбиләре әле, каһәрләрне,
Мич башына качып торганда...
Үлмәс өчен, менә Зөбәйдә дә
Таң булдисә китә эшенә.
Мәхәббәт ул – үзе иске тема,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта;
Зөбәйдә дә менә, куркып кына,
Яшь бер наборщикны ярата.
Куркып торма аннан, нәрсә булган,
Бабайлардан калган эш лә ул,
Ләкин кара, каты бул!
...................
Шулай булгач,
Үлмим әле.
Әле
Нәрсә диеп шунда үләргә;
Язлар килсен инде, язлар килгәч,
Җыр табылыр безнең җүләргә.

*

Ак чәчәкләр ява,
Үлмим әле,
Җир күкрәге – минем бишегем;
Үләр өченмени бәреп чыктым,
Ачып чыктым дөнья ишеген!

* * *

Тәңкә карлар ява,
Үлмим әле,
Кышны кирәк күреп үләргә.
Бу дөньяның салкын кышында да
Кызык табыла бездәй җүләргә...

*

Дөнья матур,
Әйтми кем үләр соң,
Җилләр кардан юрган сырганда,
Әбиләрең әле, каһәрләрең,

«Үлмим!» диеп елап торганда.

Зөбәйдә дә менә, үлмәс өчен,
Һәр көн эшкә килә кичегеп.
Ул да җирне сөя, ул да яшәп килә
Маңлай көче белән киченеп.
Мәхәббәт ул – үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта;
Зөбәйдә дә менә, куркып кына,
Яшь бер наборщикны ярата.
Ярат әйдә, аннан нәрсә булган,
Бабайлардан калган эш лә ул;
Ләкин кара, кызый,
Каты бул...
Мәхәббәт ул – нәфис матур чәчәк,
Тик ул үзе гаҗәп гомерсез:
Кайчак загс белән ахры бетә,
Ә кайчакта бик үк күңелсез.

* * *

Җылама, сеңелем!
Түкмә күз яшеңне,
Син, Зөбәйдә, бала табарсың.
Димәк, син үлемсезсең мәңге,
Киләчәкнең йөрәк каннарында агарсың.
Җылама, сеңелем,
Синең каның аша
Җирнең нәсле күчә тәнеңнән.
Бәлки, бөек кешеләр киләчәктә
Килеп туар синең каныңнан...

## ҮПКӘЛИМ

### Нарком булып сайланмадым

Мин – бер кеше.
Ә шулай да
Нарком сайлау өчен хакым бар;
Әле үземә нарком булырга да
Ирек бирә безнең законнар...
Тик...
Октябрьгә менә 10 ел тула;
Бер сайлаудан үзем калмадым,
Ә шулай да
Әле бер мәртәбә
Нарком булып үтә алмадым...
Беләм,
Нарком булу өчен гакыл кирәк,
Ә бит
Сатып алып булмый гакылны;
Мин дә тиле түгел түгелен дә,
Шайтан алсын усал хатынны!
«Бераз кызып китсәң,
Тиле, – ди, – син».
Нәрсә дисең шулай дигәчтен?!

Тып-тын каласың шул, өлешеңә
Шундый усал хатын тигәчтен.

## ҖЫРЫМ СИҢА БУЛСЫН

### Аяулы ана белән бичара ир

Анасы аны, мескен, тудырганда,
Яхшы ният белән тудырган,
Кеше булыр, дигән,
Ләкин
Үкенеп үлә язган соңыннан.
Аяулы ана,
Күкрәк сөтен биреп,
Кыз үстергән,
Ләкин уңмаган.
Кызы кызлык чагын күрсәтмәгән,
Иргә чыккан – хатын булмаган...
Бичара ир
Аны көнли булган,
Ә соңыннан кулын ташлаган.
Туры килгән җирдә, тәвәккәлләп,
Үзе гүляйт итә башлаган...
...................

* * *

Анасы аны, мескен, тудырганда,
Яхшы ният белән тудырган.
Үзе
Үсәр, дигән,
Ләкин тудыруына
Үкенеп үлә язган соңыннан.
Аяулы ана,
Күкрәк сөтен биреп,
Кыз үстергән,
Үзе уңмады.
Иргә чыгып баккан – булмаган:
Һәр адымда һәрбер очраганга
Тәнен биргән, ирен алдаган;
Бер пивнойга керми калмаган...
..................
Эш бирсәләр үзенә,
Эшем күп, ди,
Анда эшлим, монда эшлим, ди;
Укып йөрим, фәлән иткән булам,
Үлә алмыйм инде, нишлим, ди.
Үзе көнен-төнен гайбәт сата;
Кеше кебек үзе карарга,
...................

Аяулы ана,
Күкрәк сөтен биреп,
Кыз үстергән, ләкин уңмаган.
Кызын пичкә тыгыйм дисәң, пичкә сыймый,
Ашыйм дисәң,
«Чучка» булмаган.

## ЕРТЫК БҮРЕК

Җир күкрәге җылы,
Яуган карлар
Урам ташларында эриләр,
Урамнарда әле безнең бәйрәм, –
Пальтосызлар
Күкрәк киереп җырлап йөриләр...

*

Абый!
Кышны ямьсез диләр,
Ялганлыйлар,
Матур була шәпләп киенсәң;
Ә мин бу ел, ахры, үләрмен,
Бик күңелсез булыр, мин үлсәм...

*

Беренче кар, белмим, кайчан явар,
Ләкин үләрмен мин ул көнне...
Бүген әле,
Тиздән кыш килә, дип
Ямап куйдым ертык бүркемне!
Ертык бүрек кыштан саклый алмый,
Түзмәм, ахры, бу ел кыш килгәч.
Дөнья матур,
Ләкин...

Сезнең өчен
Бик күңелсез калыр, мин үлгәч!..

## МИЛИЦИОНЕР

### Librairies Такташ милиционер белән

Урам шундый матур,
Ах син, милиционер!
Ап-ак карлар ява башыңа,
Мылтыгыңны тыеп, әкрен генә,
Карлар яуган урам ташына
Басып йөрисең син...

Мин дә урамнарда йөрим,
Болай эч пошканнан
Карап йөрим шәһәр кешеләрен,
Марҗалары (кайберәүләр) этләр тагып йөриләр...
Ә беләсең, иптәш милиционер,
Яратмыйм мин шәһәр этләрен!..
Ничек уйлыйсың син,
Шул этләрнең барсын-барсын да,
Таяк алып, тотып, кычкырттырып,
Кыйнап йөрсәм синең каршыңда?!

Ябып куярсың шул,

Анысын беләм,
Син урамда тәртип саклыйсың.
Кыйнаучыны түгел,
Һәрбер кыйналганны яклыйсың!..
Газетка да берәр милиционер
Кую кирәк иде,
Югыйсә
Артыграк безне сыйлыйлар.
Тәнкыйтьчеләр дигән сукбайлар («бандитлар»)
бар, –
Көнаралаш тотып кыйныйлар.
Зарланырга телим,
Таныш минем белән,
Миңа җырчылыкка паспорт бирелгән,
Җырчы – зур кеше ул,
Син дә бераз
Зурлап каршы ал баскан җиреңнән...
Ә беләсең –
Мине нишләсәм дә арестовать итмә,
Куеп тор син аны бүгенгә;
Тик бер көн генә үзем теләгәнчә
Рөхсәт ит син сүгенеп йөрергә.
..................
..................
Җаным, милиция!
Син дә урамнарның
Тыныч булуын тели торгансың,
Тәүфыйксыз кешеләрнең җир йөзеннән
Бетүен теләп йөри торгансың.
Мин дә шулай телим,
Ләкин...
Алар, дустым, безне талыйлар да
Пивнойларда
Синең белән минем исәнлеккә эчәләр,
Кичен тагын, синнән качып кына,
Безнең бүлмәләргә төшәләр...
Ә беләсең,
«Барабыз»лар синнән зарланалар,
«Проломныйга!” дисәң, бармыйлар,
«Безгә теге кеше кушмый» диләр,
Сине күрсәтәләр,
Әллә инде шунда алдыйлар...
Ни булса да, инде алай итмә,
Дус кешеләрнең күңеле сынмасын.
Этләр йөргәч инде, «барабыз»лар
Мәхрүм булып читтә тормасын!
Аннан соң бит
Безди ярлы кешеләр
«Барабыз»да гына көн күрә.
«Барабыз»лар безгә – автобус та, извозщик та,

«Барабыз»да гына без – түрә...

*

Дөнья матур,
Ах син, милиционер,
Ап-ак карлар ява башыңа,
Мылтыгыңны тотып, әкрен генә,
Карлар яуган урам ташына
Басып йөрисең син...
Тәңкә карлар,
Төнге аксу карлар,
Маңлаеңа кунып үбәләр...
Еллар... матур еллар...
Шаулый-шаулый,
Урамнардан ашыгып үтәләр...
Урамнарда үткән яшьлегемне
Җылы җырым белән җылытам...
Милиционер!
Мине сүккән, мине талап киткән кешеләрне
Гафу итәм,
Бәйрәм хөрмәтенә онытам...
Сау бул, дустым,
Безгә җир өстендә
Яшәү өчен ордер бирелгән.
Урамнардан үтсәм, очрап калсаң,
Зурлап кал син баскан җиреңнән!

* * *

Милиционер!
Син шул закон дисең,
Һәр нәрсәдә тәртип телисең...
Көн буенча рәтсез кешеләр белән
Протоколлар язып йөрисең.
Ә беләсез, мине, нишләсәм дә,
Арестовать итмә,
Куеп тор син аны бүгенгә;
Тик бер көнгә үзем теләгәнчә
Рөхсәт ит син сүгенеп йөрергә!
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ах син, милиционер, айыйм сине,
Тәүфыйксызлар күп үк күренә:
Безнең Гайнетдиннәр, Сәйфетдиннәр
Тыныч бирми бугай үзеңә.
Мин дә менә йөрим...
Болай, эч пошканнан
Карап йөрим шәһәр кешеләрен,
Маржалары этләр тагып йөри,
Ә беләсең?
Яратмыйм шул шәһәр этләрен!
Милиционер,
Ничек уйлыйсың син? –
Шул этләрнең барсын-барсын да,
Чыбык алып, тотып, кычкырттырып,
Кыйнап йөрсәм синең каршыңда?
Ябып куярсың шул,

Беләм ансын,
Син бит
Урамнарда тәртип саклыйсың.

* * *

Урамнарда йөрим болай,
Эч пошканнан...

Европада менә «барабыз»лар
Бер дә юк дип кайтып сөйлиләр.
Анда, җаным, теге
Фашист халкы
Машинада гына йөриләр.

Ә беләсең,
«Барабыз»лар синнән зарланалар,
«Проломныйга!» дисәң, бармыйлар:
«Безгә кушмый, – диләр, – теге кеше»,
Әллә инде шунда алдыйлар.
Акыл бирим бераз: алай үз кешеләрне
җәберләмә,
Үз кешеләр, әйдә, йөрсеннәр,
Аннан соң, без дә – ярлы кешеләр –
«Барабыз»да гына чабабыз.
«Барабыз»лар безгә автобус та, извозщик та,
«Барабыз» ул – безнең чанабыз.

## ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Урман кызы каен юл буенда
Тынып йоклый баскан көенә.
Исерек усак, җәеп ботакларын,
Аны үбәр өчен иелә...
Тик урманның төнге тынычлыгын
Җимереп килгән поезд таушына
Ул, сискәнеп, берни булмагандай,
Үз урнына табан авышына.
Поезд ыргый таныш урманнардан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар,
Уйлар һәр очраган ак каенның
Ботагына асылып калалар...
Мин Тамбовны артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен;
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Имән егетеннән көнләдем.
Үтеп барам хәзер,
Сагыну катыш,
Әллә кемен йөрәк юксына,
Поезд ыргый, саулык хаты язып
Калдырыйм соң кайсы дустыма?
Шушы урманнарда матурланып
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем,
Мин мондагы һәрбер мукшы белән
Дус абыйдай тату яшәдем...

Күрмәмме дип бер-бер танышны,
Елмайдым мин, үтеп барышлый;
Көлә белгән һәрбер егет белән
Җилкәсеннән сугып күрештем;
Сукасына утырып, көлә-көлә,
Махоркамны биреп бүлештем...
Алар арасында матурланып
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем;
Давыллы елларда шул кырларда
Алар белән бергә яшәдем...

* * *

Кырда һәр очраган дус агайга
Болгый-болгый кулым талдырдым,
Талган кулларымнан кепкам белән
Чәчәгемне төшреп калдырдым.

Поезд ыргый таныш кырлар аша,
Ашгып-ашгып карыйм кырларым.

Әнә әллә кемнең кашка аты
Арбасына [борылып килгән каршына],
Ул ат ничек [охшаган] Мокамайның
Бурда урлап киткән атына.
Күктә – кояш, җирдә – таныш кырлар,
Халык йоклый, ә мин вагон тәрәзеннән
Таң каршылап карыйм урманга,—
Урманнары күптән сагынылганга,
Һәр агачы якын булганга...
Алар ничек шулай
Ак каеннар була алганнар,
Ничек матур үсә алалар.
Уйлар, ташкын уйлар каеннарның
Ботагына асылып кала баралар...

* * *

Кем кабренә чәчәк ыргытсам да,
Әрәм китмәс төсле чәчәгем, –
Мин җирдәге һәрбер сукбай белән
Дус абыйдай тату яшәдем...
Һәр очраган кеше, кем булса да, –
Чит кешеме, әллә танышмы,
Исмен-ниен сорап маташмыйча,
Елмайдым мин, үтеп барышлый...
(Сүгенмәгез тагын, дуслар эзләп
Йөргән икән диеп читләрдән.
Минем мәхәббәтем берчакта да
Үтә алмады сыйнфый чикләрдән.)

Көлә белмәгән һәрбер кеше белән
Җилкәсеннән сугып күрештем;
Бик яратып киттем, зурлап аны,
Папиросым булса – бүлештем.

Шулар арасында матурланды,
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем;
Шулар белән бергә киләчәкнең
Бөеклеге өчен яшәдем.

Авыр миңа хәзер,
Шул кешеләрнең,
Белмим, кайсын йөрәк юксына,
Соңгы җырым, бәлки...
Шул җырымны
Багышлыйм соң кайсы дустыма?

Язгы яшел урман, ялан кырлар,
Анда эшләп йөргән халыклар
Бар да иптәш булган,
Инде хәзер онытылган иске танышлар.

Күктә кояш, җирдә кырлар,
Анда эшләп йөргән халыклар –
Бар да иптәш, бар да әллә ничек
Бик күптәнге якын танышлар.

Поезд ыргый таныш ялан-кырдан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар;
Уйлар һәр очраган ак каенның
Ботагына асылып калалар.

Һавалардан төшкән метеорлар
Сүнәр тагын, кабат яналмас.
Шат йөрәгем сиңа бирер идем,
Синең йөрәк каршы алалмас.

## МОКАМАЙ

Киләсе билгесез гомер белән
Тудыра ана үзенең баласын;
Тугач инде, аяк-куллар булгач,
Ава-түнә шунда барасың...

Хат язсам да хәзер соңга калдым, –
Укымассың минем хатымны,
Ләкин минем бурычым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яман атыңны...
Син үзеңне яклый алмасаң да,
Мин, Мокамай, сине яклармын;
Ил ышаныр минем җырларыма,
Ышанырлар,
Мин ант итәм – сине аклармын.

Хыялымда минем шул урманнар
Һаман кайный, һаман шаулыйлар,
Синең белән минем малай чаклар
Күз алдымнан китә алмыйлар.

Без, урманда урман кискән чакта,
Бергә урлап, юкә кисәйдек,
Чабаталар үреп, кояш байгач,
Ат узышып кайтып китәйдек.

* * *

Ул остарак иде,
Чабатасын
Миннән матуррак үрә иде,
Минем яхшы итеп үрә алмавымны
Күңел бирмәвемнән күрә иде.
Ничек соң бу болай булды әле,
Ник ул һәлакәтен күрмәде;
Ник ул тормышын соң чабатасы
Кебек матур итеп үрмәде?

Ур ярлы иде.

* * *

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп.
Беребез – сары чәчле, беребез – кара,
Сары чәчлесе ул мин идем;
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җан кисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син идең...
Каен башына асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга таба юл алдым, –
Менгән саен, җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син меналмадың,
Калдың,
Югалдың.
Хат язсам да, хәзер соңга калдым,
Укымассың минем хатымны.
Ләкин минем бурычым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яман атыңны...
Ә бит шундый киң җир,
Бик күп бәхетләр җирдә бар...
Үлмәс өчен, җирдә озаграк
Яшәр өчен, көн-төн чабалар.
Алар, һәр туасы таңның кадрен белеп,
Түземсезлек белән көтәләр.
..................
Нинди авыр миңа бу юлларны
Син үлгәчтен язып утыру.
Ә бит синең гомрең шулай бетте,
Соңгы, халык шуларны белде...
..................
Әкияттәге ике яшь баланың

Үткәннәре – әкият минем өчен,
Тик шул әкияттәге икенең...
..................
Үткәннәрем – авыр әкият хәзер,
Шул әкияттә, кайчак сөйләгәндә,
Чагылып китсә синең күләгәң...
Юк, юк! Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм.
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең,
Тик син түбән идең, түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең.
Ә бит бергә чабаталар үреп
Йөргән чакта,
Син остарак миннән үрә идең,
Минем матур итеп үралмауны
Булдыксызлыгымнан күрә идең...

## СЕРЛЕ КҮЗЛЕК

Бер җыр бар, ди,
Үзем белмим җырны,
Берәү генә аны белә,
Ләкин җырлаганда кеше ишетеп калса,
Түзалмыйча көлеп үлә, ди...
Каһарманы җырның – бер шәкерт, ди,
Ул бик тәрилкәче булган, ди,
Элек заманнарда байлар ашы,
Байлар киеме киенеп торган, ди.
Байлар беткәч, фәсен мичкә ягып,
«Серле күзлек» алып кигән, ди.
Шул Ходайның эре сере белән
Доцентлыкка кадәр менгән, ди.
Бу кешебез, ишан хәзрәтедәй,
Доцентлылык ычкындырмас өчен,
Маркс сүзен телдән салмый, ди.
Үзе «Капитал»ның ике хәрефен
Бергә кушып укый алмый, ди,
Белмим, әллә гайбәт, әллә чындыр инде,
Ләкин шул шәкертнең үзен бар диләр,
Әле күзлек сере ачылып бетмәгән, ди,
Әллә усал телләр алдыйлар...
Ялганла әле син дә берәр нәрсә,
Әллә нигә борның салгансың;
Әллә бүген артык аргансың,
Их, җегетем!
Андый «кызыл» кешеләр
Тирәбездә бик күп әйләнә,
Аларның койрык шәрифләре
Теге якка барып бәйләнә.
Шуның өчен генә алар безгә

«Кызыл» күренергә телиләр;
Алар, койрыкларын яшерер өчен, шулай
«Серле күзлек» киеп йөриләр.

**АЛСУ**

Ялганла әле син дә берәр нәрсә,
Әллә нигә борның салынган;
Үзең сөйләшмисең, үзең сызгырасың,
Әллә инде артык аргансың.
Ә кайчандыр әйбәт егет идең,
Безгә сәлам бирми китәйдең;
Борның белән күкне сукалап,
Урамнардан шаулап үтәйдең.
Шулай, җаным,
Киләсе билгесез гомер белән
Тудыра ана үзенең баласын.
Тугач инде, аяк-куллар булгач,
Җәяүләп тә кайчак барасың...

* * *

Бату, соң булса да килер диеп,
Һаман көтте, һаман җыенды,
Алсу, килеп,
Ишек кага кебек тоелды.

Идәндә аунап, тузылып яткан
Газетларны җыйды, тазартты,
Мәңге чәй күрмәгән стаканын
Күлмәк чите белән агартты,
Өстәл асты тулы чүп-чарларны
Зур газетлар җәеп каплады,
Төнге бергә кадәр ятмады.

Ник килмәде?
Белмәдеме күңлем ярсуын,
Үпкәм бик зур сиңа, Алсуым!
Бату, ташлап барысын,
Сузылып ятып,
Китап алып укып маташты,
Һәр юлында аның саташты.

* * *

Төн караңгы, әйе, төн караңгы,
Ул юк бүген менә янымда.
Бәлки, Газиз белән икәүләрдер...
Күңлен белеп булмый аның да.
Син чакырдың аны,
Ялганлама, син бүген дә аны чакырдың.
Ул килмәдеме?

Мескен,
Килмәс инде, нишләргә юк,
Ятып йокла инде ялгыз, акыллым.
....................
Һәр чакырган саен, кызлар килми,
Тидереп булмый һәрбер атуда;
Килмәде икән, әйдә, борның салма,
Күңел юат:
Кызлар табылыр диеп Батуга.

Бату – матур егет,
Әллә кайдан килеп чыкты безнең арага.
Син яшьлекнең язгы таңнарына
Әле кереп кенә барасың.
Бату, ташлап барысын, сузылып ятып,
Китап алып укып маташты,
Һәр юлында аның саташты.

Тик урамнан соңгы трамвайлар,
Биш тукталып, тагын бер атлап
Үткән чакта, Бату чишенмичә
Йоклап китте, мендәр кочаклап.

*

Коридордан басып Алсу килә;
Үзе көлә, үзе сөйкемле,
Үзе усал, үзе болай бер дә
Усал кебек түгел шикелле.

* * *

Бүген аңа әллә нәрсә булган;
Бер елыйсы килә, бер көлә,
Бер онытылып кинәт керфекләре
Бер ноктага килеп terәлә.
– Ташла, җаным Газзә, зачетыңны,
Ах, үбәсем килә үзеңне,
Бик үбәсем килә үзеңне.
Тыңла инде бер кат сүземне!
Газзә, ирексездән эшен ташлап,
Килеп утыра аның янына:
– Ник соң театрга алып бардың?
Тоз саласың инде каныма!
Син шул, кызый, үзең зачетыңны
Бик соң әзерләргә башлыйсың,
Үзең
Бездән алда биреп ташлыйсың...
Ә без...
Ул Алсуга ачу белән карый,
Тик ачуы бик тиз басыла;

Алсу, бала кебек,
Иркәләнеп аңа асыла:
– Ник соң театрга алып бардың?
Үзең әллә кая югалдың,
Алсуыңны саклый алмадың.
Гашыйк булдым, кайттым менә хәзер.

* * *

Мин бер кызны сөйдем...
Ә беләсең
(Мин шул бераз тиле икәнмен),
Гомеремдә, бәлки, беренче кат
Шундый каты итеп сөйгәнмен...
Аңламадың күңлем ярсуын,
Үпкәм бик зур сиңа, Алсуым!

Бер хисемне,
А, юк, аямадым,
Үзем теләп, аңар бирдем мин,
Бар дөньямны онтып, бу ел язын
Шул кызны сөеп йөрдем мин.
Ә соң соңы ничек бетте?
Аңламады,
Ә мин инде асылып үлмәдем...
Өзелеп сөйдем аны,
Ләкин...
Ләкин...
Тиле кыз дип аны белмәдем...
Йөрәк байлыгымны күрмәде,
Даһи икәнемне белмәде...

Күрмәде ул минем күкрәгемдә
Бөек җырлар таңы атканын,
Сизмәде ул күңлем сахрасында
Арысланнар йоклап ятканын...
Коммунизм килеп җиткәнгәчә
Тәүбә итәм кызлар сөяргә...
Ну их, к черту,
Һәрбер юбка алдында
Тиңсез башым юкка ияргә.
Йөрәгемне эткә ташлармын,
Шундый итеп тора башлармын.

**ТАНЫШ ТҮГЕЛ ЕЛМАЮЧЫ**

Әллә ничек авыр, әллә ничек
Мин атладым шушы адымны,
Елмаюың белән әллә ничек
Искәрттең син яшьлек чагымны.
Ник елмаюыңны яшермәдең,
Ник син читтән генә үтмәдең,
Ник, үпкәндә, мине сагынып көткән
Сеңлем булып кына үпмәдең?!
Син бит болай гына, елмаймыйча,
Минем яннан үтә ала идең...

* * *

Кыз вакытта бары да матур була,
Кайдан чыга усал хатыннар;
Егет чакта бары да матур була,
Кайдан чыга
Хатын кыйный торган батырлар.
...................
Елый, малай,
Шулай дигәчтен...
Теләсәң нишлә менә,
Өлешеңә
Шундый усал хатын тигәчтен.

* * *

Син кем, белмим,
Әллә күптән инде
Онытылган бер иске танышмы?
Әллә мине танып, болай гына
Елмаясың үтеп барышлый?
Ни булса да, кара, «теге» кеше
Синең елмаюны белмәсен,
Шундый бирер,
Гомерең буе көлеп йөрмәссең...

* * *

Матурлардан рәтле хатыннар да,
Аналар да,
Яхшы эшчеләр дә чыгалмый, –
Көзге, каһәр суккан, комачаулый,
Ә көзгесез алар торалмый...
Көзге тирәсендә калалар,
Ефәк оек, ефәк күлмәк сорап,
Ир дигәннең җанын алалар...
Әле сау булсыннар ямьсез кызлар,
Алар безнең белән
Бер дәрәҗәдә эшләп баралар;
Әллә кай арада вакыт табып,
Малайлар да табып алалар...

* * *

Белмим, кем син,
Әллә күптән инде
Онытылган бер иске танышмы?
Әллә таныш түгел килеш, оялмыйча,
Елмаясың үтеп барышлый.

Әллә, минем эчем пошсын диеп,
Син җырладың шушы җырыңны,
Малаең да бер дә рәтле түгел,
Алып кит шул җылак улыңны.
Елмаюын елмай,
Ләкин кара,
Гөлчәһрәкәй очрап китмәсен,
Шундый бирер,
Гомрең болай көлеп үтмәссең.

## УРАМ-АВЫЗ СӨЙЛИ

### «Чаян»ның беренче номеры чыккан көнне

«Чаян» журналына язып диеп,
Бер дә алай ялынып тормыйбыз.
Аны
Ялынып кына сатып була торган
Начар товар диеп белмибез.
Начар булса, аны укыганда,
Авыз ерып көлмәс иделәр.
Тәмен белгән кешеләр, «Чаян» беткәч,
Разбой салып йөрмәс иделәр.
Бик ялынып үзегез сорасагыз,
Язылу хакын әйтә алабыз.
Ниндилеген укып белер өчен,
Ел башыннан язылып карагыз.

* * *

Алло, Алло!
          Дуслар, барыгыз!
Урам-авыз сөйли,
Урам-авыз хәбәр тарата.
Урам-авыз сезгә яхшылык тели,
Урам-авыз сезне ярата.
Шуның өчен алдан хәбәр итә:
«Чаян» чыкты!
Бүген иртән чыгачак.
..................
Бәйрәм хөрмәтенә бер номерны
Карточкасыз алып булачак.

## ҖАВАП

Ә соң бу сорауга
Нәрсә дип җавап бирә алам?..
Һәр көн каләм алам,
Һәр алганда,
Шул сорауга килеп тукталам...

Кешелек өчен булган һәр файдалы
Хезмәт матур булып санала,
Җырың матур булса гына, бүгенгенең
Йөрәгендә урын алала.
Без –
Үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Уртасында туган миллионнарның
Йөрәк хисен җыеп йөрүче,
Туып та әле исем бирелмәгән
Хисләренә исем бирүче...

Бүгенгенең чиксез ашкынулы
Авызлыклап тормыш агымын,
Алгы көрәшләрне күздә тотып,
Кызулатты корыч адымын!..
Терәк булып безнең теләкләргә,
Урам саен
Бетоннардан йортлар коела,
Һәр йорт балаң булып, һәрбер фасад
Җырың кебек якын тоела.
Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә, –
Башларыннан инде бөтен дөнья,
Республика кыры күренә.
Бүгенгенең бөек теләкләрен
Ашкынулы җылы хис белән
Урап,
Каным белән сугарып, мин җырлар өчен
Саклап үстерәм...
Бу тукталу түгел,
Бу – тик болай

Алга бару өчен тукталу,
Күтәренке тавыш алган чакта,
Бераз гына туктап тын алу!
Мин биш елда үземә бурыч куям
Пушкиннарны узып китәргә...
Республика миңа әмер итә
Тулы килеш шуны үтәргә!..

**АК ЧӘЧӘКЛӘР**

Ак чәчәкләр ява,
Дөнья матур,
Үлмим әле,
Кышны кирәк күреп үләргә,
Җирнең кышында да, язында да
Кызык...

Туңган тәрәзәне эретеп, мин
Мыштым гына карыйм урамга,
Ак чәчәкләр ява урамда,
Инде хәзер безгә бакчаларда
Бастырып булмас тиле йөрәкне
(Җил борынга бирер кирәкне).

Туфан, борын очын кулына тотып,
Сүгенә-сүгенә кайта салкыннан,
Җил ияреп килә артыннан...

Туңган тәрәзәне эретеп, ул
Мыштым гына карый урамга,
Ак чәчәкләр ява урамда.

Берәү, борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан,
Җил ияреп китте артыннан.

Алар,
Чаналарын мактый-мактый,
Тау шуарга шаулап уздылар,
Ә бераздан аннан сыздылар.

## ТУН ТРАГЕДИЯСЕ

Этләр – бәхетлеләр... ул халыкның
Өсләренә кигән туннары
Ертылмыйча, мәңге яңа булып,
Ялтырап йөри кара йоннары.
Һәр кич утырып туным ямыйм –
Эт тиресеннән теккән тунымны,
Һәр кич утырып, сүгенеп, туным ямыйм,
Чәнчә-чәнчә бармак-кулымны.
Һәрбер минут, һәрбер секунд өчен
Көрәш бара Совет илендә,
Ә мин һәр көн утырып туным ямыйм,
Ике-өч сәгать утырам кимендә...
Кем теккәндер, рәхмәт төшкән нәрсә,
Шундый әйбәт теккән иңнәрен,
Бүген, ашыгып кайтып килгән чакта,
Төшеп кала язды җиңнәрем.
Җеп очларын рәтләп төйнәргә
Әллә вакты аның булмаган,
Әллә прогулдан соң, исрек баштан
Брак итеп теккән, уңмаган...
Казанда данлы мех фабрикасы
Әйбәт итеп мехын эшләгән:
Бер җире күк,
Берсе кара булып,
Краскасы тигез төшмәгән...
Бу ел мин тун алып кидем, –
Шаккаттылар,
Көнләүчеләр бик күп булганнар.
Юкка гына,
Уңмадым мин туннан, туганнар...

## КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР

Яз уяна...
Ирекле республикам
Кырларында үскән усаклар
Әкрен генә сулыш алалар,
Үрелеп-үрелеп яфрак яралар.
Әнә яфрак ярган урман битен
Идел суы баскан бер читен,
Яшь каеннар, билдән суга кереп,
Күтәргәннәр күлмәк читләрен.
Юк,
Республикам мәңге яшәр минем,
Дошман үтә алмас читләрен,
Кырларында яңа тормыш корып,
Гомер итәр авыл абыйлар...
Көтү көтеп йөргән нәселләрдән
Җиргә килер бөек даһилар.

* * *

Хатым сезгә күкрәк хисләремнең
Җылылыгын саклап илтсә дә,
Сәламнәрем барып җитсә дә,
Җитсә дә...
Барыбер
Сездән миңа җавап килмәс,
Җавап язып булмый үткәнгә...
Ә мин...
Мин үткәндә булып саналырмын,
Бу хат сезгә барып җиткәндә...

* * *

Мин хатта безнең планетаның
Табигатен, айлы кичләрен
Язмыйм.
Табигатьтә булган чорына
Туктап тормыйм.
Бары сюжет итеп
Бүгенгене алам җырыма.

* * *

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бу көрәшнең бөек күренешләрен
Тарихчылар язып барачак.
Бүгенге көннең дә схемасын
Тарихчылар язып барачак.
Бүгенгедән сезгә онтылмаслык
Зур бер тарих – мирас калачак.

* * *

«Кешелекне сөйгән» кайбер гуманистлар
Безне артык каты булуда,
Безгә каршы булган сыйныфларны
Илебездә бетерү-кысуда
Гаеплиләр...
А!
Без дә – гуманистлар,
Без дә бөтен кешелекнең
Бәхте, ирке өчен янабыз.
Тик без бу зур теләкләргә каты куллык,
Сыйнфый көрәш аша барабыз.

* * *

Яфрак ярып килгән урман битен
Идел суы баскан бер читен...
Яшь каеннар, билдән суга кереп,
Күтәргәннәр күлмәк читләрен.
Яз янгыны җиргә кабынып бара,
Тау битендә пыскып кар яна;
Шарлавыклар тавышын тыңлый-тыңлый,
Большевиклар язы уяна...

* * *

Моннан элек сезгә язып салган
Хатларымның килер язмышы
Бик караңгы.
Алар җиталмыйча
Югалырлар юлда, ахрысы!

* * *

Хатларымны тарих кирәкле бер
Хат дип сезгә алып барырмы?
Тавышым ерак еллар күкрәгендә –
Сезнең чорда яңгырый алырмы?

* * *

Хатларыма сездән җавап көтмим,
Берничек тә,
Бер юл да юк җавап көтәргә...
Мөмкин булмау чиген алдалап та,
Бертөрле дә
Мөмкин түгел, дуслар, үтәргә!
Әгәр мондый бер эш мөмкин булса...
Сезгә язган шушы хатымда,
Шиксез,
Оят булыр иде оятын да,
Инде,
Онтып торып оят хакында,
Мин...
Мин папирос сездән җибәрүне
Сорар идем хатым аркылы...
Ләкин...
Кичерегез!
Минем бу сораудан
Аңланмасын «уңлык» тартымы!..
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
А, юк!
Вакытлы бер туган авырлыктан
Сезгә зарланырга теләмим.
Без Ленинның бөек теләкләрен
Папироска гына сатмыйбыз;
Алда торган авырлыкны күреп,
Постыбызны ташлап качмыйбыз.
Аннан,
Йөз елдан соң яхшы булыр, дип тә,
Мәсьәләне ерак куймыйбыз;
Без үзебез әле өч-дүрт елдан
Иркен торырбыз дип уйлыйбыз.
Бу булачак...
Бөек планетаны
Үзебезнең кулга алырбыз,
Ерак еллар күкрәгенә
Тик бер байрак,
Безнең байрак белән барырбыз!
Хыял – безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер теләк – якын киләчәк!
Һәрбер совхоз,
Һәрбер гигант колхоз
Яшәү көчен безгә бирәчәк!
Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,

Һаман күккә таба үрелә, –
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә...

**Өченче хат**

*(Открытка)*

Хатның адресы:

Бу хат киләчәкнең билгесез бер
Кешесенә атап язылган;
Исме безнең чорга мәгълүм түгел,
Фамилиясе баба ягыннан
Нигъмәтуллин булыр.
Киләчәккә почта йөрмәгәнгә,
Бу хат анда таба баручы
Яшь буыннар аша җибәрелә.
Үтенәмен:
Хатны алучы
Һәрбер кеше, үзе үлгән чакта,
Баласына биреп калдырсын!
Тик
Бу хатым бирелергә тиеш булган
Ул иптәшнең исмен, адресын
Белмим.
Шуның өчен хатны ачык язам,
Аны һәрбер кеше укый алачак.
Шулай итеп, кулдан кулга күчеп,
Хатым, бәлки, аны табачак!..

* * *

Бүген бер иптәшем белән Иделгә без
Боз акканны төштек карарга;
Сезгә хат язарга уйлавымны
Юлда сөйләп бардым аңарга...
Ул берсүзсез генә тыңлап барды.
Ә Иделне карап йөргәндә,
Миңа көлеп карап:
– Әгәр язсаң,
Сәлам җибәр, – диде, – миннән дә...
Аннан,
Шунда бераз уңай туры китереп,
Хатыңдагы бер буш урынга
Мактый төшеп мине кыстырып кит.
Менә нәрсә:
Күбрәк яз син кешеләр турында...

* * *

Сез яшәгән ерак киләчәктә
Җиргә килер бөек җырчылар.
Бик бәхетсез булыр ул җырчылар,
Алар
　　Махорканың тәмен белмиләр,
　　Паровозга утырып йөрмиләр...
Бүген бер иптәшем белән паровозда
Бер заводны бардык карарга,
Сезгә хат язарга теләвемне

Юлда сөйләп бардым аңарга...
Ул берсүзсез генә тыңлап барды,
Ә заводны карап йөргәндә,
Миңа көлеп карап:
– Әгәр, язсаң,
Сәлам җибәр, диде, миннән дә.
Аннан малайларга болай дип яз,
Исән булса, диген, башыбыз,
Авырлыкны сезгә калдырмабыз.
Инде
Тыныч килеш, диген, ятыгыз...
Тик без, диген, бөек җиңүләргә,
Зур төзелешкә бик бай булсак та,
Әле бик кечкенә кайбер нәрсәләргә, диген,
Аптырау туа бездә күп чакта.
Мисал өчен: менә көннәр буе
Папироссыз, диген, йөрибез.
Посылкага салып, диген, бер йөз пачка
Җибәрүне сездән сорыйбыз.

* * *

Үткән көнгә кайтып булмагандай,
Хат та язып булмый үткәнгә.
Әйе,
Мин дә үткәннәрдә булып саналырмын,
Бу хат сезгә барып җиткәндә.

* * *

Безнең арабызда әле бик күп
Сарык тиресе япкан бүреләр.
Әле бик күп суккин сыннар безнең белән
Исәнләшкән булып йөриләр.

* * *

Бүген менә шуның берсе, кереп,
Сүгенеп чыгып китте янымнан,
Имеш, аңа тормыш авыр булган,
Нэп заманын кире сагынган.

Ә бит без яшәгән чорда безнең белән
Бик күп катлау кешеләре яшәде.
Бик күп бюрократлар, бик күп сволочьлар
Совет икмәкләрен ашады.

* * *

Без сыйныфлы тормыш ярларыннан
Сыйныфсызлык ягына күчәбез.
Һәрбер проблеманы яңабаштан
Үзебезчә уйлап чишәбез.

* * *

Безнең чорга үзенең аюларын
Урман
Саклап алып килгән шикелле,
Иске тормыш безгә үзе белән
Бик күп җәнлекләрен китерде.

Алар төрле сукмак, төрле юллар белән
Төрле нәсел, төрле халыктан,
Төрле оя, төрле тавыктан
Безнең чорга килеп керде алар
Һәр ишектән, һәрбер ярыктан.

* * *

Менә бөек эш планы:
Бишьеллыкны дүрттә үтәргә;
Бездән алда булган буржуа илен
Куып җитеп узып китәргә!

# ЭЧТӘЛЕК

Төзүчеләрдән ...................................
Киләчәккә Такташыбыз белән. *Рәдиф Гаташ* .................

**Шигырьләр һәм поэмалар**

***1916***
Газраилләр ....................................
Караңгы төннәрдә ................................

***1917***
Төркстан сахраларында .............................

***1918***
Күктән сөрелгәннәр ...............................
Үтерелгән пәйгамбәр ..............................

***1920***
Ачлык патша ...................................
Антым ......................................
Айның нурлары арасында ............................

***1921***
«Җил сөйли...» ..................................
Җир уллары трагедиясе .............................
Таң кызы .....................................
Онытылган ант ..................................

***1922***
Күләгәләр ....................................
Нәләт .......................................
Урман кызы ...................................
Эшлиләр .....................................
Бакчачылар ....................................

***1923***
Мәңгелек әкият .................................
Урамда ......................................
Гыйсъян .....................................
Сагыну ......................................
Зәңгәр күзләр ..................................
Пасха чаңнары ..................................
Тиленәр ......................................
Нота ........................................
Янар таулар ....................................
Кояш күктә шулай мәңге йөзәр .........................
Казан .......................................
Такташ үлде ...................................
Октябрь төне ...................................
***1924***
Гасырлар һәм минутлар .............................
«Бүген радио безгә хәбәр итте...» ........................
Урман .......................................
Карт артист ....................................
Давылдан соң ...................................
Еллар таңында ..................................
Сыркыды авылы .................................

***1925***
Пионерлар маршы ................................
Никахсызлар ...................................
Син дә үл инде ..................................

Әүхәди ......................................
Байрак тегәбез ..................................
Провокатор ....................................

*1926*
Нәни разбойник .................................
Әйдә, энем! ....................................
Кыр казлары ...................................
Картайдым шул .................................
«Пи-би-би-бип...» ................................
«Инде бу кырларда...» ..............................
Хәнифә Такташевага ................................
Җырланачак җырлар турында ..........................
«Туасы таңнарның кояшына...» .........................

*1927*
Бүгенге матурлык ................................
Мәхәббәт тәүбәсе ................................
Мәскәү – Лондон сөйләшә ............................
Камали карт белән улы Әхмәт ..........................
Ибрай агай һәм аның улы Зөбәй .........................
«Ояты юк сатлык юлбасарның...» ........................
Үпкәлим .....................................
Казан урамы күренешләреннән... .........................
Җырым сиңа булсын ...............................
Лорд Чемберленга СССР крестьяны Һади Такташтан җавап нотасы ......
Онытылган тәбрик ................................
Ләйлә ......................................
Тагын казлар турында ..............................
Сигналчы кызыл гаскәр җыры .........................
Без сыныйбыз көчебезне .............................
Өйрәнегез ....................................
Үзләре кеше кебекләр, карасаң – көзге чебешләр ...............
Атлы сугышчыга .................................
Бүленергә ярамый ................................
Аерылу җыры ..................................
Иптәшләр ....................................
Чиста бул .....................................
Ертык бүрек ...................................
Милиционер ...................................

*1928*
Болай... гади җыр гына ..............................
Мәчеләр күз яше .................................
Габдулла агай әкияте ...............................
Актив – пассив ..................................
Үтеп барышлый .................................
Тәүфыйклы песи .................................
Кави әкияте ....................................
«Ай кебек, без озак яшәмәбез...» ........................

*1929*
Мокамай .....................................
Серле күзлек ...................................
Алсу .......................................
Мулла Чемберлен ................................
Таныш түгел елмаючы ..............................
Беспартийный ..................................
«Руфик!..» ....................................
Йомшак башлар .................................
Уталган чүпләр ..................................
Авызлары, борыннары җимерелгән сүзләрне яклап ..............

Син – дошманым минем .............................
Урам-авыз сөйли .................................
Җавап .......................................
Ак чәчәкләр ...................................

*1930*
«Батырларның батыр булганлыгы...» .......................
Яңа лордлар, первый сортлар ...........................
«Чаян»ның хайванат бакчасы ...........................
Суккин сын ....................................
Кутепов  кайда? .................................
Чигенү ......................................
Гайбәт теле ....................................
Удар артыннан удар ...............................
Тун трагедиясе ..................................
«Чаян» уклары ..................................

*1931*
Съезд ачылды ..................................
Мин дезертир бугай, командир! ..........................
Наркомпрос җырлары ..............................
Киләчәккә хатлар ................................
Мылтык җыры ..................................

**Язылу вакыты билгесез шигырьләр, парчалар**
«Күрәсеңме...» ..................................
«Кичәге матурлык бүген үлсә...» .........................
«Җир турында матур бер җыр бар, ди...» .....................
Альбомга .....................................
«Туфан йоклый...» ................................
«Һәр өйрәнчек...» ................................
«Кулың бир дә...» .................................
«Син һәрвакыт...» ................................
«Кырым матур, диләр...» ............................
«Казан кар астында...» ..............................
«А, партия!..» ...................................
**Уртак иҗат**
Җирдән сөрәбез! .................................
Хәлифәлек трагедиясе ..............................
**Әсәрләрнең вариантлары, тәмамланмаган кисәкләр**
«Без кояшлы язның чәчәкләрен...» ........................
Мәхәббәт тәүбәсе ................................
Үпкәлим .....................................
Җырым сиңа булсын ...............................
Ертык бүрек ...................................
Милиционер ...................................
Үтеп барышлый .................................
Мокамай .....................................
Серле күзлек ...................................
Алсу ........................................
Таныш түгел елмаючы ..............................
Урам-авыз сөйли .................................
Җавап .......................................
Ак чәчәкләр ...................................
Тун трагедиясе ..................................
Киләчәккә хатлар ................................
Искәрмәләр һәм аңлатмалар .........................

Литературно-художественное издание

**Такташ** Хади
(**Такташев** Мухамметхади Хайруллович)

**СОЧИНЕНИЯ**

Издание второе, исправленное и дополненное

В трех томах

Том 1

Составление тома, подготовка текстов, примечаний и комментариев
**Садыковой** Назии Исмагиловны

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Такташ** Һади
(**Такташев** Мөхәммәтһади Хәйрулла улы)

**ӘСӘРЛӘР**

Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма

Өч томда

1 том

Томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче
**Садыйкова** Нәҗия Исмәгыйль кызы

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Г.Ф.Сибгатова, Э.Т.Кәлимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 9.02.2010.

Форматы 84х108 1/32. Шартлы басма табагы 21,42.

Тиражы 2500 д. Заказ В-1965.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**
Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.